UPRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

2018 МАРТ № 3

ISSN 0869-1398

СөЮМБИКә

АЙДАР ГАЛИМОВ

ул безнең хакта ни уйлый

БӘХЕТ ИСЕМЛЕГЕ

барысы да үзеңнән тора

ИЛНАЗ БАХ СЫЙЛЫЙ

«Җиләкле алан» торты

Гөлнара ХАФИЗОВА:

БӘХЕТ НИГЕЗЕ — ӘНИЛӘРНЕҢ ДОГАСЫ

PRESSA.RU

Минем өчен син һаман да – 17дә!..

Минем өчен син һаман да 17 дә!..

Бу фотосурәтләр еракта калган кабатланмас мизгелләргә – Яшьлеккә алып китә... ...Шундый зур галәмдә меңнәр арасыннан бер-береңне эзләп табу – үзе үк могҗиза! Аны күргәч кабынган хисләр – иң саф, иң ихлас, иң садә... Йөрәктәге сагышы да – якты, татлы, моңлы... Беренче очрашу... Аның кебек башка берәү дә юктыр! Дөнья – матур, яшәү шундый рәхәт! Очар өчен канатлар кирәкми дә!.. Ярату, йөрәккә генә сыялмыйча, җанда шигырь булып бөреләнә... Һәм мәңгегә Син – Шагыйрь, Ул Илһамчың булып кала...



ЗӨЛФӘТ

БОРЧЫЛУ

Яңа гына кар астыннан
чыккан умырзая сыман,
ачыкмын мин синең белән –
иренемдә гөлләр тоеп,
гөрләвекләр кебек көләм...

Кайчак сентябрь җиленнән
кучкылланган диңгез сыман,
йөрәккә кысып давылны,
ярларыма ятып тынам.
Синсез
кайгы да юк җанда,
шатлык та юк анда –
яшәү булып агасың син
минем кайнар канда.
Ничек яшим синсез? –
Син бит минем сулар сулу,
бу да ярату булмаса...
ул чагында нәрсә соң ул
сөю, гашыйк булу?!

1968

Рәсемдә: шагыйрьнең хатыны Фирая. 1968 ел.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2018

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Фото: Газинур Хафизов

Җитәкче-баш мөхәррир
Гөлнара Ильяс кызы САБИРОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Рәшидә һәм Гөлфия Әгъләмовалар
Фото: Юлия Сажнева

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Фәнзилә Мостафина
Ландыш Әбүдәрова
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Равил Газизов

Формат: 225x290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 21.02.2018 ел.
Заказ Е-374.
Тираж 6022.

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.


Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002



PRESSA.RU



«Курай жыры». Мадияр Хажиев эше.

Баш мөхәррир сүзе



Яз турында язасым килгән иде. Инде гыйнвар аеннан бирле язгы тамчылар күрергә хыялланган күңел, февральнең бер иртәсендә тәрәзә аша тамчы тамганын күргәч, җилкенеп-иләсләнеп тә киткән иде. Тагын... мәхәббәт турында язасым килгән иде. Башны югалттыра, җилкендерә, яшәтә һәм яшәртә торганы турында. Яз ничек мәхәббәтсез булсын инде ул?! Тик: «Ә ул миңа тагын ни өчен кирәк?» – дигән сүзләр яңагыма китереп суккандай итте. Каршымда утырган 40 яшьләр чамасындагы ир танышымның сүзләре бу. Ир эштән кайткан вакытка ашарга әзерләп тормаган икән хатыны, ниндидер эш белән йөреп, өлгерми калган. Без, хатын-кызлар, һәрнәрсәне үзебездә үлчәп карарга өйрәнгән бит. «Ә ул миңа тагын ни өчен кирәк?» – дигән сүзләр минем адреска яңгыраса? Беренче уй шул булды. Кирәк яки кирәк булмауның ашарга пешерү-пешермәвеңнән генә торуы коточкыч әйбер бит. Заманы да аңа калмаган, өйдә бер кич кайнар ризык булмаганнан гына ачка үлә торган түгел (гомумән, бу очрак күбрәк ирнең тормышка яраклаша белмәвен күрсәтә әле).

Мин аңа хатын-кызның тормыштагы мең дә бер роле турында сөйләдем. Шул рольләрен үтәп, гаиләдә, җәмгыятьтә, бизнеста, сәясәттә, иҗатта зур уңышларга ирешеп, дөньякүләм танылуга ирешә алулары турында... Ирләрен зур җиңүләргә илһамландырган алиһәләр турында... «Ел хатын-кызы» республика бәйгеләрендә җиңү яулаган «Сөембикә» журналы геройлары, тормышның үзенә биргән сынауларын җиңеп, башкаларга ярдәм итү юлына баскан көчле ихтыярлылары, «Мәрхәмәт» депутат хатын-кызлар берләшмәләре, «Ак калфак» һәм башка иҗтимагый оешмаларга берләшкән гүзәл затлар да читтә калмады. Безнең инде бик күптән ашарга пешерү һәм өй җыештыру кысаларыннан чыгуыбызны аңлату иде теләгем.

Кайда гына, кем генә булсак та, хатын-кыз булып калабыз бит без (ә моның шулай булуында ир-атларның өлеше зур булуы – аерым тема). Нинди генә дәрәҗәгә ирешсәк тә, нинди генә социаль статуста булсак та, без яратуга, ихтирамга, назга һәм соклануга мохтаҗ. 8 Март – Халыкара хатын-кызлар көне дә, тарихи әһәмиятенә карамастан, безнең заманда күбрәк Матурлык, Яз, Гүзәллек бәйрәме буларак кабул ителә бит. Бәйрәм котлы булсын, хөрмәтле туташлар һәм ханымнар, әниләр һәм әбиләр! Хөрмәтле һәм кадерле булып яшик! Күңелләрдән яз китмәсен!

Гөлнара САБИРОВА



PRESSA.RU





БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА



20

«БУ – МИНЕКЕ, МИН ҮЗЕМНЕ ТАПТЫМ!»
Ландыш Әбүдәрова

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ





6

ИРЕМ МИҢА... ӨЙЛӘНМИ
Мәдинә Авзалова

26



«ЯХШЫЛЫК ЭШЛӘРГӘ СОҢАРМАСКА ИДЕ...»
Саимә Ибраһимова

12



ЧУЛМАН КЫЗЫ
Фирая Моратова

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ






30

БАБАҢ КЕМ ДӘ, ЗАТЫҢ НИ?
Лилия Гәрәева

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ

36 **ЮЛДАШЛАР**
Гөлүсә Закирова

ЯШӘЕШ




42 **ЯШӘҮ – ҮЗЕ БАТЫРЛЫК**
Мәдинә Авзалова



46 **БОЗ ҺӘМ... УТ ИЛЕ**
Эльза Нәбиуллина

ШУЛАЙ УК:


20 **КАГЫЛМАГЫЗ МИҢА!**
Гөлнур Сафиуллина

40 **ГОМЕРЛЕК ӘРНУ**
Рәхилә Низаметдинова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ




62 **ДЕЛИКАТЕС ЯШЕЛЧӘЛӘР**

КИЛӘСЕ САННАРЫБЫЗДА:

АВЫЛНЫ ЯШӘТҮЧЕЛӘР. АКТУАЛЬ ТЕМА

«ЮК» ДИП ӘЙТЕРГӘ ӨЙРӘНӘБЕЗ. БЕЛГЕЧ КИҢӘШЕ

ХАТЫН-КЫЗ ҺӘМ ИР-АТ. ИЛШАТ ӘМИНОВ ФИКЕРЛӘРЕ

ТАРИХ. ТЫНЛЫК. ТАЛЛИН. МИН АЧКАН ДӨНЬЯ



PRESSA.RU




Фото: Ксения Богданова

ИРЕМ, МИҢА... ӨЙЛӘНМИ



Мәдинә АВЗАЛОВА

«ЯЗЫЛЫШМЫЙЧА ӨЙЛӘНҮ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ» ТУРЫНДА ДӘҮЛӘТ ДУМАСЫНА КЕРТЕЛГӘН ТӘКЪДИМ ТИРӘСЕНДӘ ЗУР БӘХӘСЛӘР КУПТЫ.

Без анның белән Абхазиягә ял итәргә баргач, диңгез буенда таныштык. Татарча сөйләшүебезне ишеттеме, кем беләндер аралашасы килдеме, шактый вакыт безне күзәтеп ятканнан соң, яныбызга килеп утырды. Казаннан икәнебезне белгәч, тагын да җанлана төште. «Үзебезнекеләр икән», – диде ул, йөзе балкып китеп. «Сезнекеләрме?» – диде ул, яр буенда этешә-төртешә бер-берсе белән уйнаган малайларга ишарәләп. Сүзебез үзеннән-үзе балаларга, гаилә мәшәкатьләренә барып тоташты. Хәер, нәрсә турында сөйләшсен инде хатын-кыз?!

– Мин дә кызым белән килдем. Су коена әле, – диде ханым. Ул да түгел, диңгездән аңа кемдер кул болгады, аннан кинәт кенә ярга таба йөзә башлады. Җитәкләшеп, безгә таба килгән егет белән кызга таныШым чыраен сытып кына: «Барыгыз, бар, хәзер киләм...» – диде.

Хатын минем аптыраулы карашымны шундук аңлап алды.

– Йөргән нәрсәсе, – диде, кабынып китеп, – өч ел яшиләр, өч ел... ни бала-чагасы, ни нәрсәсе... Минем дә оныклар сөясем килә. Тегесе һаман: «Юк, иртә әле», – дип суза килә. Беләм нигә шулай дигәнен. Йөрер, йөрер дә көннәрдән бер көнне юкка чыгар. Оятсыз ул. Әти-әни-

сенә дә әйтеп карадык. «Сакал чыккан бит инде, үзе хәл итсен», – диләр, мыскыл итәләр. Кыз аны ярата, аның сүзеннән чыкмый. Әбисеннән калган фатирда яшиләр. Безнең фатирда. Егетнең бернәрсәсе юк. Баланың бөтен гомере шул адәмне көйләп уза. «Рөстәмнең шуны ашыйсы килә, моны ашыйсы килә...» Карап торсаң, гарьләнеп үләрсең. Кайтмый калган чакларында, кыз елап шалтырата. Ә мин нигә кайтмаганын чамалыйм. Аның тагын килеп-китеп йөри торган бер хатыны бар. Кызга әйтмим, яратканын беләм. Күпмегә сузылыр бу хәлләр?

Алар ике көннән киттеләр. Без Гөлсем (исемнәр үзгәртелде. – *авт.*) белән телефон номерларын алыштык. Шуннан бирле өч ел вакыт узып китте. Өч ел эчендә алар гаиләсендә зур үзгәрешләр булган: «Разбежались...» – диде Гөлсем, бу очракта иң урынлы сүзне кулланып. «Аерылыштылар», – дип әйтә алмый ич инде. Аерылышыр өчен башта кушылырга кирәк әле. Ә аларның бер-берсен никах җепләре белән бәйләп куясылары килми. Аннары бит эшләр артык җитдигә китә. Кем белә, аерыла, мал бүлешә башласалар, нишләрләр? Ә болай... яшәп карыйк әле, бер-беребезгә туры килсәк, өйләнешергә дә булыр. Яшьләр шулай уйлый. Ләкин шуның белән алар бер-берсенә ышанмаганны расլый. Күп очракта ирләр ышанмый. Үз-үзләренә ышанмый. Хатын-кызның тизрәк кияүгә чыгасы, бала табасы килә. Бу берәүгә дә сер түгел. Кемнең инде ак күлмәк киеп, ЗАГСка барасы килмәсен?! Шуңа да, бергә яши башлауга, хатын-кызның күбесе үзенең «сожителенең» (башкача әйтәсе дә килми) кияүгә сораганын көтә. Ниләр генә кыланмый хатын-кыз иренә ярар өчен, ниләр генә эшләми. Янында бөтен теләген үтәп, «биеп» торган хатын булганда, нигә өйләнсен ул? Аңа бит болай да шәп, болай да рәхәт. Ә өйләнсә, җаваплылыкны үз өстенә алырга туры киләчәк. Ир кешене беркайчан да ирексезләп өйләндереп булмый. Ә бер уйласаң, үзеңә өйләндерү юлы бик гади бит. Нишләргә, кызлар?! Әйе, әйе, никахлашмыйча, язылышмыйча сөйгәнең белән якынаймаска, җенси мөнәсәбәткә кермәскә!

Һәр өченче ир – сөйгәне теләген искә алып, һәр дүртенче ир гореф-гадәтләрне күздә тотып өйләнә. Бары һәр унынчы ир генә – яратканга...

«Ә нәрсә булган?»

Димәк, моның ише килделе-киттеле мөнәсәбәтләр ирләргә уңай.

– Элек ничек булган ул? Әлбәттә инде, ЗАГС – бала – бәхетле гаилә... Хәзер барысы да үзгәрде, – ди бер танышым. – Күпләр шулай яши бит бүген. Нәрсә булган, нәрсәсе бар аның? Яшәп карыйлар да, бер-берсен туйдыра башласалар, хушлашып китеп баралар. Фатир бүлешеп

ФИКЕР



Альбина ШӘВӘЛИЕВА, Министрлар Кабинеты каршындагы ЗАГС Идарәсе җитәкчесе

Язылышмыйча яшәгән парларны рәсмиләштерү яки законлаштыру турында беренче генә сөйләшү түгел. Бу закон проектын Дәүләт Думасы каравына кую, чыннан да, зур бәхәсләр, җәмәгатьчелек резонансы тудырды. Мондый инициатива безнең гаилә һәм никах төшенчәләренә, гореф-гадәтләребезгә, ЗАГС органнарында теркәлгән ир белән хатынның гаилә оештыру, балалар тәрбияләү максатында кушылуын исбатлаучы Россия Федерациясенең Дәүләт гаилә сәясәте концепциясенә каршы килә.

Әлеге тәкъдимнең әхлакый, хокукый һәм социаль-икътисадый нәтиҗәләрен күз алдында тотып, шуны әйтә алабыз: бу үзгәрешләргә без тискәре карыйбыз.

ФИКЕР



Наилә ҖИҺАНШИНА, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең гаилә, хатын-кызлар һәм балалар эшләре комитеты җитәкчесе, ТР мөселман хатын-кызлар берлеге рәисе

Дин әһеле буларак, язылышмыйча яшәгән парларга карата мөнәсәбәтем бер дә әйбәт түгел. Бу бит никахсыз, әти-әнидән фатиха алмыйча, зина кылып яшәүне аңлата. Мин моны башкача әйтә дә алмыйм. Гаилә дигән рухи кыйммәтләр югала. ЗАГСка барып кына да эш бетми бит әле. ЗАГС – ул тәннәрне якынайта, ә менә никах – җаннарны... Никах – Аллаһы алдында, җәмгыять алдында җаваплылык тоту дигән сүз. Язылышмыйча гына өйләнү, имеш. Бу ни дигән сүз тагы? Җаваплылыктан качумы? Әйе, өйләнгән кеше дини яктан да, әхлакый яктан да үз өстенә зур җаваплылык ала. Әгәр дә шундый закон кабул ителә икән, кешеләр бу җаваплылыктан кача башлаячак. Ә бит тормыш кыйммәтләре гаиләдә салына. Бала гаиләдәге мөнәсәбәтләрне күреп үсә. Бүген әйбәт, иртәгә начар булса... карарбыз әле, дип яшәгән ир белән хатын сабыйга ни бирә ала? Бүген яшьләр туй да ясый, никахлаша да... Әти-әниләренә карап шулай итә. Әгәр без язылышмыйча гына яшәргә рөхсәт бирсәк, алга таба алар ирекнең тагын да зуррагына талпыныр. Тәртипсез яшәү рәвеше алып бара башлар...

PRESSA.RU

ФИКЕР



Татьяна ВОРОПАЕВА, Татарстан Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе урынбасары

Өйләнешмичә яшәүгә каршы фикеремне һәрвакыт әйтә килдем. Әйе, мин каршы. Нәрсә инде бу?! Гаилә бүген бар, иртәгә юк. Хәер, мондый мөнәсәбәтләр булганда, гаилә була да алмый. Биредә төп проблема – балалар. Алар туды исә, әни кеше баласын атасы исеменә яздырудан баш тарта башлый. Һәм ул, нигездә, баласын ялгыз тәрбияләүче ана дип исәпләнә. Болай иткәндә, дәүләт аңа азмы-күпме ярдәм күрсәтә ала бит. Милек мәсьәләсе килеп чыккан очракта, ир белән хатынның бергә яшәүләрен дәлилли торган фактлар китереп, шаһитлар эзләп табып, бу проблеманы хәл итәргә мөмкин. Ә язылышмыйча гына өйләнү турында сүзнең булуы да мөмкин түгел.

Бөтенроссия җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге мәгълүматларыннан күренгәнчә, сораштырылучыларның 38 проценты язылышмыйча яшәргә риза, 50 проценты – каршы, 56 проценты моны өйләнешүгә санамый.

Язылышмыйча яшәгән ирләрнең 70 проценты – «иреклe кош», ә бу хәлдәге хатын-кызның 90 проценты үзен кияүдә, дип исәпли.

йөрисе дә юк. Без – ирләр генә түгел, хатыннар да риза хәзер «ирекле кош» булып яшәргә. Бездә тавыш юк: мин соң кайтсам, ул дәшми, ул төн уртасында кайтса, мин сүз әйтмим. Шулай килештек. Ул миңа: «Без бит синең белән фатирдашлар», – дип кенә җибәрә. Кайчак ачу чыга, ләкин дөрес әйтә бит. Төрле хәлләр була. Әнә дустым бергә яши башлауларына биш ел булгач өйләнде. «Аннан башка яши алмыйм», – ди. Шулай да була.

– Ә син, син кайчан ЗАГСка барасың?

– Юктыр, мөгаен. Бер кыз белән таныштым. Чиста күңелле, сөйләшүе үк икенче, тыйнак димме... Бәлкем, киләчәктә, Алла боерса...

Бер-берсен якыннан белү өчен «өйләнешкәнче торып карау» – бүген киң таралган күренешләрнең берсе. Белгечләр әйтүенә караганда, бер-берсен сынау никадәр озакка барса, бергә калулары да шулкадәрле генә. Вакыт узган саен, шанслар кими генә бара.

Язылышмыйча өйләнү

ЗАГСка бармыйсың, паспортыңа язылышу хакында мөһер суктырмыйсың, никахлашмыйсың, ә менә өйләнгән исәпләнәсең. Ир белән хатын рәсми теркәлмичә биш ел бергә яши икән, алар өйләнгән булып исәпләнә. Ә инде уртак балалары бар икән, ул чагында ике ел да җитә. «Язылышмыйча өйләнү мөнәсәбәтләре турында» Дәүләт Думасына кертелгән закон проекты Гаилә кодексына җитди үзгәрешләр алып киләчәк, дисәләр дә, моның уңай барып чыгачагына ышануы кыен. Язылышмыйча өйләнү белән язылышып өйләнү арасында җир белән күк арасы икәнлеген чамалыйсыздыр. Гәрчә биредә төп сылтау итеп бергә яшәүчеләрнең уртак көч куеп табылган мал-мөлкәткә карата мөнәсәбәтләрен көйләү күз алдында тотылса да... Мондый парлар икесе ике якка каерылганда, балаларына гына финанс яктан ниндидер гарантия бар әле. Анысы да әтисе булуын раслаган очракта. Бүген бар, иртәгә юк мөнәсәбәтләрне уртак мал-мөлкәт, уртак хуҗалык, хәтта уртак балалар коткарып кала алыр микән? Юк, минемчә. Ул мөнәсәбәтләр юкка чыга икән, мал бүлешкәндә, дусларыңны, туганнарыңны, күршеләреңне шаһит итеп чакырырга туры киләчәк. Җитди һәм катлаулы эш бу. Әгәр дә әлеге документ кабул ителә икән, ул чагында «сожитель»ме ул, бойфрендмы – аларга карата да өйләнешеп яшәгән ирләргә куелган таләпләр куелачак, диелә закон проектында.

Ире белән язылышмыйча яшәгән хатын бик күпне оттыра. Мәсәлән, ире үлгән очракта, закон буенча аңа бернинди мөлкәт эләкми. Кинәт вафат булганда, түләнмичә калган эш хакы, больничныйлар хакында әйтеп тә торасы юк. Кыскасы, мондый хатын-кыз юридик яктан, гомумән дә, якланмаган.

«Җиңелчә караш... Зыян салу»

РФ Гаилә кодексын камилләштерү буенча комиссия рәисе Елена Мизулина бу тәкъдимгә кискен каршы чыгып, аны гаилә һәм өйләнү мәсьәләләренә «җиңел караш, зыян салу», дип бәяләде. «Язылышмыйча өйләнүләр бик тотрыксыз, – диде сенатор. – Ул хокукый бәхәсләр китереп чыгарырга мөмкин. Шуның нәтиҗәсендә карауччысыз калган балалар саны артуны да истән чыгарырга ярамый. Гаилә институтын зәгыйфьләндерү – ул җәмгыятьнең һәм дәүләтнең ныклыгына һөҗүм итү белән бер». Бер уйлаганда, әлеге закон проекты, иң беренче чиратта, хатын-кызны яклауга исәп тота. Ләкин ул барыбер мөнәсәбәтләр таркалган очракта мал бүлешү бәхәсләрен хәл итә алмый. Статистика мәгълүматларына караганда, безнең илдә өйләнешкән һәр икенче пар аерылыша. Яшьләрнең күбесе бала көтүләрен белгәч кенә язылыша. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы ЗАГС Идарәсе хәбәр итүенчә, былтыр республикада 26983 пар язылышкан, ягъни рәсми теркәлүчеләр саны 5 процентка арткан. Өйләнешкән 1000 пар исәбеннән алганда, шуның 503 се таркалган. Узган ел барлыгы 13586 пар аерылышкан. Саратов, Киров өлкәләре белән чагыштырганда, аерылышулар бездә азрак та икән әле. Җыеп әйткәндә, безгә Гаилә кодексына өстәмә проблемалар тудырырга торган әлеге дә баягы «Язылышмыйча өйләнү мөнәсәбәтләре» генә җитми хәзер. Авыртмас башка тимер тарак, кем әйтмешли...

Чәчәкләр, чәчәкләр, чәчәкләр... Чәчәкле озын күлмәктән ул үзе дә чәчәк кебек! Килешәсездер – слингка утыртып, аркасына аскан сабые аны тагын да сөйкемлерәк, матуррак итә. Яраткан чәчәкләре һәм яраткан кешеләре – янәшәдә! Ул декрет ялында да яраткан эшендә! Күр, никадәр букет ясап куйган. Тирә-юньгә хуш ис, яз исе таралган. Безнең хатын-кызлар гына 8 Мартны менә шулай каршылый аладыр, мөгаен. Бөтен күңел җылысын йөрәгә аша үткәреп, дизайнер осталыгын кушып, башкаларны сөендерә алуны алар гына шулай булдыра бугай...

Декрет ялындагы хатын-кызны ничек күз алдына китерәсез сез? Бишек тирбәтеп өйдә утыра итепме? Ялгышасыз. Алар – эшли! Баланы ашата, юындыра, йоклата, уйната, дип, тезеп китәргә ашыкмагыз. Өйдән чыкмыйча гына, акчалы чын эштә эшләп йөрү турында сүз бара монда. Юкса шулай утырса да бер сүз юк. Беркем берни әйтми, беркем эшләргә кушмый, ул аның законлы декрет ялы. Үзе шундый тиктормас, тынгысыз инде менә!

Бала белән өйдә утырган килеш эшләүнең сәбәпләре күп инде аның. Финанс кыенлыклары (кредит түлисе, гаилә бюджетын тулыландырасы...), кулыңнан килмәгән эш юк икәнен дә күрсәтәсе килә (бала белән утыра дигәч тә... әллә ниләр майтара ала бит ул!), бер үк төрле ялыктыргыч көндәлек эшләрдән беразга арынып тору да ярый, яңа һөнәр дә үзләштерәсең (репетитор, фрилансер, блогер, фотограф, дизайнер, флорист, дизайнер...), иң мөһиме – үзеңне кирәкле кеше итеп тоясың!

Эльмира ЗАКИРОВА
Фото: Ксения БОГДАНОВА



PRESSA.RU

«ЕЛ ХАТЫН-КЫЗЫ. ЕЛ ИР-АТЫ: ХАТЫН-КЫЗ КАРАШЫ»





МИН АЛАРГА СОКЛАНАМ!

8 Март бәйрәме алдыннан «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесенә йомгак ясала. Шул уңайдан «Татарстан хатын-кызлары» республика иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Зилә ВӘЛИЕВАга берничә сорау белән мөрәҗәгать иттек.

«Ел хатын-кызы» бәйгесе матурлык конкурсыннан аерыла. Бу сәхнәгә күтәрелү өчен хатын-кызлар нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?

– Ә мин менә аны матурлык конкурсы да дияр идем... Дөрес, без иң элек аларга булдыклы җитәкче, сәләтле оештыручы, менә дигән ир хатыны, яхшы әни булган өчен баш иябез. Әмма кайчак килеп чыгалар сәхнәгә – кайда утыруыңны онытасың. Ул буй-сын, йөз-кыяфәт! Тик безнең бәйге сәхнәсенә чыгучылар подиумда күлмәк күрсәтеп йөргән чибәрләрдән үзгә. Алар хәзерге заман хатын-кызы тормышта нинди булырга тиешлеген, аның бүгенге яшәү моделен гәүдәләндерә. Өй җылысын саклап, балалар үстереп, аларга күркәм тәрбия биреп кенә яшәү дә – хатын-кыз өчен зур хезмәт. Аларның шуның белән генә чикләнергә дә хаклары бар. Ә бүгенгеләр, әйткәнемчә, барысын да булдыра.

Алабугада узган зона турында бер яшь ханымга игътибар иттем. Ул яшәгән авылда нибары биш йорт калган. Таралып беткән дисәң дә була... Ә бу ханым шунда... һәвәскәрләр ансамбле оештырып җибәргән. Алай гына да түгел, шул авылда ханым кечкенә генә бизнес та булдырган: дару үләннәре җыеп сата... Хатын-кызның да төрлесе бардыр: кемдер күлмәкнең кайсын кияргә, нинди ресторанга барырга белми аптырап йөридер. Ә менә аның кебекләр юкны бар итә беләләр! Шуннан тәм, рәхәт табып, башкаларга да үрнәк күрсәтәләр. Тормыш тегеләй дә уза, болай да...

Бәйгедә хатын-кызлар берничә номинациядә көч сынаша. Аларның кайсында җиңүчене билгеләү авыррак?

– Минем өчен бөтен номинацияләр дә авыр. Сәхнәгә чыккан һәркемгә җиңүче исемен бирергә әзермен... Бәйге сәхнәсенә күтәрелгән хатын-кызларның уйламаган, көтмәгән җирдә асылташ кебек балкыган очраклары гел булып тора. Конкурс – үз-үзеңне күрсәтә белү бит ул. Ә мондый сәләт өлкәнрәк буынга бирелмәгән. Бүген исә дөнья үзгәрде. Үзләрен күрсәтә белгәннәр сәләтлеләрне дә артта калдыра... «Ел хатын-кызы» бәйгесе сәхнәсенә күтәрелүчеләр (кайчакта, бәлки, үз-үзләрен җиңеп тә!), башкарган эшләрен кешеләр сокланып карарлык, үрнәк алырлык итеп сөйләргә өйрәнә. Моны күрсәтү өчен төрле формалар эзли. Үзләре режиссерга әйләнә! Яңа сәләтләре ачыла! Бәйге булгач, әлбәттә, бөтен кеше дә җиңүче исемен ала алмый. Әмма, миңа калса, катнашучы һәр хатын-кызның тормышта яңа сулышы ачыла, бәйге, аңа үзенең бәясен, дәрәҗәсен чынбарлык белән туры китерүдә зур адым булып тора.

Бу сәхнәдә нинди генә язмышлар белән очрашмыйсың. Арада үзегезне бик тетрәткәннәре дә бардыр...

– Әлбәттә, бар! Районнарның берсендә сәхнәгә олы гына яшьтәге бер ханым чыкты. Үзләрендә театр оештырган икән. Соңыннан без аның белән сөйләшеп киттек. «Гомерлек йөрәк ярам бар. Бер улым югалды... Ләкин ул миңа исән кебек, каядыр яши кебек тоела», – диде апа, күңелен ачып. Улы Хабаровскида хезмәт иткән. «Бүген юлга чыгам», – дигән телеграммасы килгән, ләкин күпме генә көтсәләр дә, үзе кайтып җитмәгән. Шуннан бирле бер хәбәре юк! Инде ике дистә елдан артык вакыт узган... «Кеше – энә түгел, салам эскертенә төшкәндәй эзсез югала алмый лабаса!» – дип өзгәләнә әнисе. Әлбәттә, эзләткәннәр, ләкин нәтиҗәсез... Инде бу эзләүләргә без дә кушылдык. Таптык без аны! Ә бу тарих болай булган. Дембельнең кесәсендә азрак акча да була бит, шуңа кызыгыптыр инде, кичтән поездга утырганда егетне бик нык кыйныйлар. Ул больницага эләгә: башына зыян килгән була – хәтерен югалта. Кайдан ул, кем, исеме ничек – берсен дә белми. Документларын, күрәсең, акчасы белән бергә урлаганнар. Азрак аякка баскач, эшкә урнаша. (Эшнең дә кешеләрдән читтә булганын сайлый. Ул эшли торган гидрометеорологик станция дә тайгада урнашкан – аны вертолетта илтеп куялар, бер-ике айдан барып алалар.) Өйләнә. Хатыны аның язмышыннан хәбәрдар була, әлбәттә, иренең туганнарын ул эзли башлый. Безнең юллар шулай кисеште... Бәйгедә катнашкан әниләрнең солдат улларын кайтартып, бәйрәм сәхнәсендә аларны очраштырып, көтелмәгән бүләк ясаганыбыз бар. Бу ана белән баланы да сәхнәдә күрештерергә уйладык. Ярдәм итегез, дип, Хабаровск шәһәре губернаторына кадәр мөрәҗәгать иттек. «Станциядә чираттагы дежуры, аның артыннан вертолет җибәрү кыйммәткә төшә, булмый. Ә авылга алар тиздән кайтачак», – диделәр. Килешми чара калмады... Бераз вакыт узгач, аларны сәхнәдә очраштырмавыбызга сөендем дә: ананың йөрәге, бу шатлыкны күтәрә алмый, шунда ярылган булса?! Улы исән икәнен аңлагач, үзебезнең дә йөрәкләр шартлардай булган иде бит...

PRESSA.RU

«ЕЛ ХАТЫН-КЫЗЫ. ЕЛ ИР-АТЫ: ХАТЫН-КЫЗ КАРАШЫ»

ЧУЛМАН КЫЗЫ



«Машинада гына җилдерүче ирләргә биек үкчәле туфли кидереп, шәһәр тротуарларыннан бер генә көн йөртер идем үзләрен. Хатын-кызның хәлен бик тиз аңларлар иде. Безнең затның бер кулында – авыр сумка, икенчесе белән кечкенә баласын җитәкләгән. Биек үкчәле туфли, затлы күлмәк тә киясебез, шул ук ирләр алдында матур да күренәсебез килә бит әле». Сүзгә-сүз үк җиткерә алмасам да, бу фикер – Эльвира Рәфгать кызы ДОЛОТКАЗИНАныкы. Һәм ул аны Түбән Камада хатын-кызларның үз иҗтимагый оешмасын булдыру зарурлыгына төп дәлил итеп китерә. Кемгә, дисезме? Әлбәттә инде, шәһәрдә иң зур вазыйфа биләүче җитәкчегә – Түбән Кама мэры, муниципаль район башлыгы Айдар Рәис улы Метшинга. Сездә тагын сорау тудымы? Мэр кадәр мэрга шундый таләпләр куярга базучы затның кем икәнен беләсегез килә, шулаймы? Безнең түбәнкамалылар өчен анысы да сер түгел: Эльвира ханым – башлыкның беренче урынбасары. Халык теленә күчереп әйтсәк, Түбән Кама хатын-кызларының иң асылы, беренчесе. Үз дигәнен итә торган булдыклы зат ул!

...Кояш офыкка якынлашкан бер мәлдә менә шул асыл затның эш бүлмәсендә чәйләп утырабыз. Газетада эшләгән елларымда Эльвира Рәфгать кызы белән еш аралашырга туры килде. Шуңа да мин аны шактый яхшы беләм дип уйлап йөри идем. Чын кытай чәен эчә-эчә, аның тормыш сәхифәләрен күзаллаганда, акыл ияләре әйтмешли, бу эшлекле җитәкче ханым турында үземнең моңа кадәр әле берни дә белмәгәнемне аңладым.



Фирая МОРАТОВА

Балдан татлы балачак

Башкортстандагы Нефтекама шәһәре кызы Эльвира үзенең балачак елларын аерым бер сагыну белән сөйли.

Аның истәлек-хатирәләренә ияреп, балачагына – күрше республикадагы Тәтешле районының Аксәет авылына кайтабыз. Гадәттә, бу бәхет соңгы уку көненә туры килә һәм күз ачып йомган арада үтеп киткән җәйге каникул азагына кадәр дәвам итә. Нефтекамадан Эльвираны акушер-гинеколог булып эшләүче әнисе Сәвия озатып кала. Машина кузгалып киткәч тә әле кызчык артына борылып әнисенә кул болгап бара. Инженер әтисе белән машинада кайтуы аның өчен олы бәхет булып тоелгандыр.

Әтисенең бертуган апасы Гамилә йорты янына килеп туктауга, кызчык җил капкадан өйгә томырыла. Каян сизгән диген, сайгаклары балавыздай сары болдыр баскычында инде Гамилә апасы көтеп тора. Ишегалды чирәмендә чемченеп йөргән тавык-чебиләр дә, кайттыңмы дигәндәй, кунак кызга карап торалар. Кояшта иркәләнеп болдырда ятучы песи дә иренеп кенә күзен ача. Кызчыкның алар янында озаклап туктап торыр җае юк. «Венера авылдамы? Кәтү чыгамы? Бәбкәләр ничәү?» Сорау арты сорау. Җавапны да көтмичә, дусты Венераларга чабасы килә. Әмма ярамый. Башта әле олылар белән бергәләп чәй эчәселәре бар...

Һәр иртәдә кояш күтәрелгәнче капка төбенә чыгып, көтүне озатып кала бу кызчык. Кояш нурлары үләндәге иртәнге чыкта коена. Эльвира да, сандалиларын салып, яланаяк өйгә йөгерә. Өстәлдә җырлап утырган самовардагы үз чагылышына – кыска чәчле кызчыкка гаҗәпләнеп карап тора: көзге кирәк түгел икән лә. Гамилә апасы белән озаклап чәй эчәләр. Аннары Эльвира ишегалдында каңгылдашкан казлар янына чыгар. Тизрәк Әригә куарга кирәк үзләрен. Венера белән балык сөзәселәре дә бар. Ярый әле Эльвира үтә күренмәле «газовый» яулыгын алып кайткан. Балык сөзү өчен шуннан да яхшырагы юк. Әле Гамилә апасы бүген таба ашы пешерергә җыена. Әбисе Габидәгә ияреп, Венера да килер. Җәй буе шулай, бер өйдә тәм-том пешерелсә, башкалары да сыйлана. Кунаклар килгәнче, көянтә-чиләк асып, Тау асты чишмәсенә дә барып кайтырга кирәк...

Кичләрен Гамилә апаларына күрше-күлән керә, авыл хәлләрен сөйләшәләр. Кызлар йон эрли. Әтисенең мәктәптә укытучы Нәзирә апасы да килә аларга. Шул апаларына охшап, Эльвира да кул эшенә бик оста. Кибет киштәләрен бушаткан үзгәреш елларында иренә, балаларына кышкы өс киемнәренә кадәр үзе тегә. Болары – үскәч... Ә хәзергә – авылның үз тәртибе, үз тормышы...

Татарның зыялыларын, укымышлыларын, иң булдыклы шәхесләрен авыл биргән, авыл кеше иткән бит. Эльвираның да олы тормышка юлы авылдан башланган. Гәрчә шәһәр кызы булса да...

Кыңгыраулы мәктәп елларыннан алып...

Августның соңгы көннәрендә генә Нефтекамага кайткан Эльвира өчен шәһәр көннәре башлана. Класста иң актив, иң тырышлардан була ул. Отряд, дружина советы председателе, шәһәрнең пионер штабы начальнигы... Мәктәпне «бишле»гә генә тәмамлаган Эльвира югары белем алу өчен Казанга китә. Әнисе дә Казан медицина институтын тәмамлаган бит! Аннан соң, Уфага – самолетта очарга яки, елганы паромда кичеп, автобуста барырга кирәк. Казанга юл җиңелрәк: поездлар йөреп тора. Шулай итеп, 1980 елда Эльвира Шәрипова университетта укый башлый. Ул вакытта әле бик сирәк булган программист белгечлегенә!



Аппарат җитәкчесе булып эшләгәндә, Эльвира ханым тулы бер район, олы бер шәһәр халкы тормышы өчен дә үзен җаваплы тоя.

Әйтерсең ул төзелеш отрядында эшләр өчен яратылган!

Студент елларындагы мавыгулары да холкына туры килеп тора. «Константа» отрядында сылаучы-буяучы була. Кайбыч мәктәбе, Арча педагогика училищесы, Балтачның Нөнәгәр мәктәбе стеналары, бәлки, әле студент кызларның кул һәм күңел җылысын бүген дә саклыйдыр. Җәйләрен шулай эшләп тапкан акчасына Эльвира ул вакытта зур байлык саналган фотоаппарат сатып ала. Яшьлек истәлеге итеп, кадерләп саклый. Кая гына сәфәр чыкса да, рәссамнарча күзаллавын чагылдырган сурәтләрне әле хәзер дә фотоаппарат хәтеренә кертеп куя... Ә икенче елын төзелеш отрядында эшләгән акчасы «права»га китә – курсларда укып, автомобиль йөртү таныклыгы ала кыз.

Икенче мавыгуы, әлбәттә, тау туризмы. Кышкы имтиханнарны тапшыргач, Памир, Саян, Урал тауларына чыгалар. Үзләре белән походка алу өчен, кибеттә талонга бирелә торган консервланган ит банкаларын ел буе җыя алар. Дүртенче курста укыганда, кышкы сессиядән соң, Карпат тауларына җыеналар. Егетләрнең барысы да – КАИдан. Походта кызлар да, егетләр дә – бертигез. Беркемгә бернинди ташлама юк. Авыр рюкзакларын, палаткаларын Эльвира белән дусты Венера да үз җилкәләренә асып атлыйлар.

Гомерлек яры Марат белән әнә шул походка әзерлек барышында таныша Эльвира. Мордва ягыннан килгән мишәр егете Марат Долотказинның КАИдагы радиотех-

PRESSA.RU



■ Үз хуҗалыгыннан бушамаган хатыннарны бер-берсе белән аралаштыруны, халык арасына алып чыгуны, үзләрен гаиләнең җаны, асылбикәләр итеп тоюны максат иткән «Авылым хуҗабикәсе» конкурсы соңгы елларда көтеп алган бәйрәмгә әйләнде.

ника факультетының бишенче курсында укыган чагы. Уртак мавыгулар, юмор хисе көчле булган егетнең үз-үзенә бик нык ышанганлыгы һәм акыллы кызның яшендәй җитезлеге ике арада сөю хисе уята.

Хисләрне – вакыт, ара ераклыгы сыный, диләр. Һәрхәлдә, Эльвира белән Маратка бик тә туры килә торган сүзләр.

Бишенче курста Эльвиралар төркеменнән дүрт студентны, диплом эше язу өчен, Камчаткадагы вулканология институтына җибәрәләр – биш айга! Кар салкынлыгы бөркелгән якларда башны әйләндерердәй егетләр күп булса да, Эльвира вәгъдәләшкән ярына тугрылык саклый. Ә дусты Флүрәне исә Камчаткадагы татар егете гомерлек яр итеп үзенә алып кала. Еллар узгач, Эльвира белән алар бер-берсен табышалар. Анысы да кызык кына була. Узган кыш ире Марат белән Камчаткага барырга җыенгач, Флүрәне эзләргә тотына ул. Баксаң, подполковник званиесендәге Флүрә туган ягына – Казанга кайтып төпләнгән. Шулай итеп, Камчаткада түгел, Казанда очрашалар...

Эльвира белән Маратның икесенә дә хас бер сыйфат бар: башта һәркайсы үзе генә барып кайткан җиргә соңыннан бергәләп бару. Шуңа да Эльвираның яшьлек эзләреннән узу өчен кышны сайлыйлар. «Берни үзгәрмәгән, шул ук кырыслыгы белән матур кышкы Камчатка. Иремнең туганнан туган энесе шунда хәрби хезмәттә, офицер. Икенче елга Камчаткага җәй аенда барырга уйлап торабыз», – ди Эльвира ханым, фотолар сузып. Ә аларда – сопкалар, мәңге үзгәрмәс кар аклыгы, сулышлар кысылыр дәрәҗәдәге бөек кырыслык. Табигатьнең гаҗәеп могҗизасы шулдыр...

Җаннар берлеге өчен кешеләргә нәрсә кирәк икән? «Елларга һәм тормыш ваклыкларына бирешмичә, һаман да уртак хыяллар белән янып яшәү», – дияр Долотказиннар. Аларның сәяхәтләргә, табигатькә омтылу хыялларына берни дә киртә була алмый. Уллары Тимур, кызлары Галия бераз үсә төшкәч, барысы бергәләп Урал якларына сәяхәткә чыгалар. Юлларында очраган елгаларны резин көймәдә узалар. Ире Марат халыкара шкипер «права»сына ия. Шунлыктан соңгы елларда Урта диңгездә яхтаны берәр атнага арендага алалар да, диңгез киңлекләрен гизәләр... Чит илләрдә йөргәндә, Эльвира ханымга инглиз телен мәктәп программасы кысаларында белүе ярап куя бит. Рәхмәт хисләре белән инглиз теле укытучысы Бәрия Халитовнаны искә төшерә. Тел белү ягыннан уллары Тимур әти-әнисен уздырган әнә. Тугызынчы класстан соң, Мәскәү дәүләт университеты каршындагы интернат-мәктәптә укыган. Физика-математика факультетында белем алган Тимур илебез башкаласында яши, эше буенча чит илләргә еш йөри. Кызлары Галия Казан федераль университетын тәмамлаган, реклама белгече.

Хатын-кыз эше булмаган вазыйфада

«Тормышны яңадан башларга туры килсә, нишләр идегез?» – дигән сорауга Эльвира ханым: «Балаларга күбрәк игътибар бирер идем, кечкенә чакларын кабат кайтарып, күбрәк кочар, иркәләр идем», – диде.

Бар гомере эштә узган кешедән генә ишетергә буладыр андый җавапны. Эльвира Түбән Камадагы социаль яклау идарәсендә эшли башлаганда рәсми кәгазь эше кулдан башкарыла әле. Ул килгәч, 1993 елдан компьютерга күчерүгә керешәләр. Идарәдә үз тармагындагы бердәнбер белгеч булган Эльвира хезмәткәрләрнең барысын да компьютерда эшләргә өйрәтә. Ә инде сайлау кампаниясе башлангач, Түбән Кама шәһәре һәм районы хакимиятенә программист Эльвираны җәлеп итәләр. Баш күтәрми эшләүче ханымның осталыгын тиешенчә бәялиләр: 2001 елдан хакимиятнең оештыру бүлегенә белгеч итеп эшкә чакыралар. Ике елдан ул инде шул бүлекнең мөдире була. 2006 елдан башлап – аппарат җитәкчесе, ә инде биш елдан соң башлык урынбасары итеп сайлана. Бүгенге көндә дә шул җаваплы вазыйфада ул.

Хезмәте турында кыскача әнә шуларны әйтергә булыр иде. Әмма җитәкче хатын-кызның эше-тормышы турында коры гына язу дөрес булмас, күңел кичермәс. Беренче чиратта ул әле хатын да, әни дә, бала да. Бәлки, «бала да» дигәнен беренче урынга куяргадыр. Чөнки ул чагында әле әнисе Сәвия апа исән була. Картаеп, күзләре күрмәскә әйләнгәч, кызы Эльвира гаиләсендә яши. Ишле гаиләгә фатирлары кысан булгач, Эльвира ханым социаль ипотека өчен рәсми кәгазьләр җыя. Нәкъ шул чагында ул вакыттагы хакимият башлыгы Илсур Метшин, халыкка социаль ипотека алуны җиңеләйтү максатыннан, аңа бу мәсьәләне өйрәнү бурычын йөкли. Өйрәнеп кенә калмый Эльвира ханым, халыкка тарату өчен махсус буклет-күрсәткечләрне типографиядә бастыртып ук ала. Һәм берничә көннән ул буклет җитәкче өстәленә кертеп салына. Башлык

карашында гаҗәпләнү, рәхмәт хисләре. Эльвира ханым исә авыру әнисе, үз гаиләсенең дә ипотекага фатир алырга җыенуы турында сүз кузгатып, җитәкченең вакытын алырга базмый...

Түбән Кама шәһәре һәм районы башлыгының аппарат җитәкчесе итеп билгеләнгәч, иң авыры – эш күплеге түгел, ә өйгә соңга калып кайту була. Һәр кичне кайтып ишек ачкач, үзен якыннары алдында гаепле тоя. Ул кайтып кергән мизгелдә, бәлки, карашларында шелтә дә чагылгандыр, бәлки, улы белән кызы турсаеп та йөргәннәрдер. Әмма арыган йөзен, җеп өзәрлек тә хәле калмаганын күреп, Мараты өс киемен салырга булыша, Тимуры тизрәк янына килеп җитә, Галиясе бәлеш исләре таралган аш бүлмәсенә чакыра... Эльвира ханым өйдәгеләре өчен бик тә кадерле кеше булганын бар йөрәге белән тоя шул чакларда. Гаиләдә барлык проблема уртага салып хәл ителә. Анысы – Эльвира ханымның бәләкәйдән үз әти-әнисеннән күреп үскән гадәте. Шул гадәт буенча улы белән кызын да акчаны сак тотарга, гаилә бюджетын дөрес бүләргә өйрәтә ул.

Эльвира ханым хәзерге район башлыгы Айдар Метшиннан тормышта һәрбер җитәкче өчен бик тә кирәкле сыйфатка – барысын да алдан күрә белергә, һәр проблеманы вагына-төягенә кадәр исәпкә алырга, һәрбер нәрсәгә игътибар итәргә өйрәнә. Биредә ул Рәхимә Гайниева, Нина Сытина кебек зур тормыш тәҗрибәсенә ия хезмәттәшләренең һәрьяклы ярдәмен тоеп эшли. Аппарат җитәкчесе булганда, көндәлек хәл ителергә тиешле мәсьәләдән арынмаса, башлык урынбасары вазыйфасы күбрәк анализлауны таләп итә. Балигъ булмаганнар белән эшләү комиссиясе утырышларында комиссия рәисе Эльвира Рәфгать кызы әни исемен күтәреп йөрүче хатын-кызга ана хокукыннан мәхрүм итү кебек кискен чараны кулланмаска дип күпме кабатлый! «Бала үз анасы янында үсәргә тиеш. Ә анасының кешелек сыйфатларын җуймавын барыбыз бергә кайгыртырга бурычлы», – дип өздереп әйтә ул.

Эльвира Долотказина тәкъдиме белән барлыкка килгән «Түбән Кама шәһәре һәм районы хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасы да гүзәл затларның дәрәҗәсен күтәрү өчен тырыша. Алты ел рәттән районда «Авылым хуҗабикәсе» конкурсын уздырулары да – шуңа дәлил.

Ел саен Ватан сакчылары көнендә шәһәркүләм «Әни бәлеше» акциясе үткәрелүен дә әйтик. Хатын-кызлар татлы бәлешләр пешереп, Түбән Камадагы хәрби часть-та сроклы хезмәт үтүчеләрне сыйлыйлар.

Саратовтагы шәһәребез шефлыкка алган хәрби часть солдатларына татлы кучтәнәч – Ант кабул иткән көнгә туры китереп, 30 килограммлы чәкчәк пешереп илтү дә матур гадәткә әйләнде.

Аналар көненә, 8 Март бәйрәменә, Балаларны яклау көненә ике телдә «Подруга» газетасын чыгаруны да Эльвира Рәфгать кызы уйлап тапты инде. Түбән Каманың 50 еллык тарихына багышлап, Президентлар да яратып алырдай затлы китап бастырып, шәһәрнең хөрмәтле шәхесләренә, калабызга нигез салган ветераннарга таратуны да ул оештырды.



■ «Әни бәлеше» акциясендә катнашкан ханымнар өйдә пешкән камыр ризыгы һәм йөрәктән чыккан җыр-биюләр аша солдатларга өй җылысы, ана мәхәббәте бүләк итәләр.

Машина йөртүче кызларны да онытмый башлык урынбасары. Үзе дә ун елдан артык руль артында йөрүче Эльвира ханым елның-елында «Түбән Кама хатын-кызлары – юллардагы иминлек өчен» акциясен уздыра. Сүз уңаеннан, бер зур бәйрәмнән соң, ул бер әбинең кесә телефоны аша такси чакырта алмыйча утырганын күрә. Аны үз машинасына утыртып, подъезды янына ук китереп куя. Кузгалырга җыенганда гына, әби аңа кинәшен җиткерә: «Син хуҗа бит! Ник үзең рульдә? Шоферың йөртсен!»

Бик күп мәсьәләләргә хатын-кыз күзлегеннән карый.

Ихлас сүзләренә рәхмәт әйтеп, елмая гына башлык урынбасары. Читтән караганда кырысрак күренсә дә, Эльвира ханым бик тә нечкә күңелле. Тормышны, кешеләрне, туган телен ярата.

– Сабый чагымда гел татарча гына сөйләшә идем, соңыннан русчага күчелде. Шуңа да хәзер бакчамда ял иткәндә, «Сөембикә»не, «Казан утлары»н укыйм. Укыган саен, туган телемнең җырдай аһәңен бар җаным белән тоям, – ди Эльвира ханым. – Әнием флокслар ярата иде, ә кайнанам – чалмабаш чәчәген. Үземә ромашкалар ошый. Чәчәкләрне күп үстерәм. Иртән иртүк, кеше торганчы чыгам да, әниләремдәй күреп, шул гөлләр белән серләшәм. Гөлләр дә, җир дә миңа яшәү, эшләү дәрте бирә.

Менә ул – туры сүзле, тынгысыз, мең төрле уй-мәшәкатьләр белән янучы, кешеләргә игелек кылу, ярдәм итү өчен җан атып йөрүче булган ханым. Гаиләсе белән инде утыз ел гомер кичергән Түбән Кама бик кадерле аңа. Химиклар шәһәрен үзләренеке дип саный, кешеләрен ярата. Сөенеп, канатланып, сокланып сөйли ул алар турында. Шулар өчен әллә ниләр эшләргә әзер.

...Ак калабыз офыкка якынлашкан кояш нурлары балкышына коенганда, Эльвира ханым белән саубуллашам. Аның елмаюы да шул балкышның яктысы сыман.

PRESSA.RU



«БУ – МИНЕКЕ, МИН ҮЗЕМНЕ ТАПТЫМ!»

БАЛА ЧАГЫНДА ҮТӘ ДӘ ТЫЙНАК, БАСЫНКЫ ХОЛЫКЛЫ, ХӘТТА КИ КЫЮСЫЗ БУЛГАН УЛ. БҮГЕН ИСӘ БИЕК ҮКЧӘЛЕ ТУФЛИЛӘРДӘ ГЕНӘ ҮЗЕН УҢАЙЛЫ ХИС ИТӘ ТОРГАН ЗЫЯЛЫ ХАНЫМ.

Ландыш ӘБҮДӘРОВА

Татарстанның төп никахлар теркәү сарае – «Казан» гаилә үзәгенең хуҗасы – ЗАГС Идарәсенең мәдәни чаралар бүлеге җитәкчесе Гөлнара ХАФИЗОВА төгәл 15 ел никах теркәүче булып эшләү дәверендә меңләгән яшь гаиләнең кулына законлы никах таныклыгы тапшырып, фатиха биргән кеше.

1 нче пәрдә

– Әни, күл буенда үз йортында яшисең килмиме синең?

– И-и, кызым, хыялыем, безгә каян килсен, ди, инде андый йорт? Булмаганны...

12 яшьлек Гөлнара кечкенә календарьлар җыя. Шулар арасында күңеленә иң якыны – күл буенда агачтан салган йорт сурәтләнгәне. Әллә нинди тыныч бәхет бөркелә шуннан. Кызчык бу сурәтне күңел түренә үк яшереп куя һәм хыялларына бирелә. Әнисе Рәйсә коммуналь фатирдагы бердәнбер тәрәзә төбенә басып, карашын күккә төби дә бердәнбер кызы Гөлнараның бәхете өчен дога кыла...

– Мин әти белән әнинең бер генә кызы. Шулай булсам да, иркә итеп үстермәделәр. Киресенчә, әни кырысрак тәрбияләде. Тегесе ярамый, бусы ярамый...

Казан кызы Гөлнараның балалык, үсмер еллары «Казанский феномен» дип йөртелгән җинаятьчел төркемнәр чәчәк аткан чорга туры килә. Урам кануннары белән яшәүче мондый төркемнәрдән әти-әниләр кыз балаларны ничек булдыра ала, шулай саклый. Рәйсә апага да кырыс та, уяу да булырга туры килә, чөнки Гөлнараны тәрбияләү үзенең генә җилкәсенә төшә: кызы үсеп җиткәндә ире белән аерылышкан булалар инде.

– Әле бергә яшәгәндә дә, әти минем тәрбия белән бик кызыксынмады. Бала буларак, аның нинди әти булуын аңламаганмын да. Әтиләр шундый була дип уйлый идем. Әни белән аерылышкач та үзгәрмәде. Аңа бернинди үпкәм юк. 13 ел элек мәрхүм булды ул, – ди Гөлнара Рәсим кызы.

«Үпкәм юк»... Бу җөмлә кайтаваз булып колагымда яңгырый. Әтисен кичерер өчен аңа рухи үсеш баскычларының барысы аша үтәргә туры килә: 15 яше тулган көнне дә, 18 яшьлегендә дә менә-менә ишектән килеп керер дә «Кызым!» дип күкрәгенә кысар, дип көтүләр, кияүгә чыгып гаилә коргач, яшь парның аны урамда очратуы, әти кешенең кызын танымавы... «Син бабай булдың!» дип шатлык уртаклашканда да битараф калуы... Җеназасына хушлашырга барулар, әтисе ягыннан туганлык эзләрен эзләп, Пенза якларына барып чыгулар, Мазарлы мәчетендә мәрхүм булган туганнары рухына дога кылулар, март аенда әллә каян гына килеп чыккан күбәләкнең Гөлнара тирәсендә әйләнүләрен күрүләр... Бу кичерүнең бәһасе – бүген Гөлнара белән Фердинандның мәхәббәт тулы гаиләсе.

Әнисенең заводтагы эше сменалы: йә иртән өйдә юк, йә кич. Иркенләп йөрү мөмкинлеге булса да, аның сүзеннән чыкмый кыз, хәтта дус кызлары белән дискотекага да йөрми. (Беренче тапкыр дискотекага кияүгә чыккач барып карый. «Фердинанд, бер барып күрим инде, нәрсә икән ул?» – дип сорагач, ире җибәрә аны. Кайткач сорый: «Йә, ничек?» Яшь чагында андый җирләргә йөрмәве өчен үкенерлек булмый, кыскасы.)

Яшьлегенең иң матур еллары туксанынчы елларга туры килә Гөлнараның. Үзе әйтмешли, үтә дә тыйнак холыклы юаш кызга һөнәр сайлаганда да шушы сыйфат өстенлек итә: кыз училищега кереп, химик-лаборант булырга укый, 40 нчы заводка эшкә урнаша. Шул вакыт СССР дигән зур мәмләкәттә үзгәреш җилләре туза, иң беренчеләрдән булып, ул җилләр заводтагы яшь белгечләрне себереп ала да язмыш кочагына селкеп сала. Хәтерләсәгез, нәкъ менә химик, физик кебек конкрет һөнәр ияләре кирәксез булып калган, икътисадчы белән юристларның яңгырдан соңгы гөмбәләр кебек үрчегән заманы иде ул. Химик таныклыгын өйдә калдырырга туры килә яшь белгечкә, ярый әле секретарь-референт дигән катыргысы бар: шәһәр буйлап эш эзләргә чыгып китә.

Филармониянең авыр ишекләрен ачып кергәндә, Гөлнара язмыш капкалары аша атлавын да уйламагандыр, билгеле.

– Секретарь кирәкми, ә менә билетлар таратучы кирәк. Таратырга гына түгел, сатарга кирәк! – дип, эшкә алалар тәҗрибәсез кызны. Күз алдына китерәсезме: кешеләргә алтышар ай хезмәт хакы түләмиләр,



Фото: Ксения Богданова

ә ул аларны концертка билет алырга күндерергә тиеш! Бер ай үтә, ике ай... бер билет та сата алмый. Шул көннәрдә танылган җырчы Рөстәм Маликов Гөлнараны күреп ала. «Сеңлем, – ди ул, – нишләп болай интегеп йөрисең син? Синең урының сәхнәдә бит!»

> *«Кызым, тәүфыйклы бул, йөзгә кызыллык китерә күрмә», – дип үстерә әнисе Гөлнараны.*

– Сәхнәдә? Минемме? – ул хисләрне бүген дә хәтерли әле Гөлнара Рәсим кызы. – Юк, мин сәхнәнең сәхнә икәнен беләм инде, ләкин үземне сәхнәдә итеп берничек тә күрә алмый идем.

– Кызым, синнән нинди артист чыксын инде? – Рәйсә апа шакката.

Ике туган апасы Венера хуплый: «Безнең Гөлнара булдыра ул!» Шул сүз җитә, имтиханнар да тапшырыла, театр училищесы студенты да булып куя.

– Шундый рәхәт иде укуы! Минем оялчанлыгым да, кыюсызлыгым да юкка чыкты. Дөньяга ачылып киттем. Хәтта каникулларга китәсе килмәде.

...Марсель Сәлимҗановның юбилеена әзерләнеп йөргәндә Гөлнараны Фердинанд Хафизов күреп ала.

PRESSA.RU





2 нче пәрдә

– Кызым, нәрсә булды? Нишләп төннәр буе йоклый алмыйсың? – бер бүлмәле фатирда әни күзе төнлә дә күреп тора шул.

Шуннан соң бөтен серен әнисенә чишеп бирә Гөлнара: «Фердинанд кияүгә чыгарга тәкъдим ясый, син риза булмассың, дип куркам».

Өлкәнрәк тә, артист кеше дә, өйләнеп, аерылырга да өлгергән, баласы да бар...

– И кызым, – ди шул вакыт Рәйсә апа, Гөлнараның гаҗәпләнүенә каршы, ризалык бирә. – Кемдер бәхетеннән май да ката, таш та эри.

Адәм баласының гомерендә була торган өч туй да ЗАГС аша үтә.

– Гөлнара белән без бер-беребездән башка тора алмый идек. Әле дә бер тәүлек гомер дә бик озак тоела безгә, ярый әле телефоннар бар. Ул чакта аны училищедан каршы алам да Восстание урамына кадәр көн саен – яңгыр дими, кар дими – җәяү атлыйбыз. Ун-уникe чакрымны сизми дә калабыз. Өйләнешкәч тә үзгәрмәдек. Камал театрында эшләгән чагым: берәр айга гастрольләргә җибәрәләр. Сагынуга чыдар әмәл юк! Гөлнара үзе килеп җитә. Шулай бервакыт Башкортстанның Бакалы районыннан кайтканда, машина ватылды. Гөлнарага: «Кайта тор», – дибез. Ул: «Юк, үлсәк – бергә үләрбез!» – дип, мине ташлап китмәде. – Фердинанд абый шулай дип искә төшерә. Аны республикада да, аннан читтә дә танымаган кеше юктыр: театр артисты белән филармония артистының гастрольләрдә булмаган авылы каламыни аның?

1995 елның җәендә никах укыталар, туй итәләр. Театр училищесын тәмамлап, Гөлнара Рәсим кызы «Казан» милли мәдәният үзәгенә администратор булып эшкә урнаша. Озаклмый кызы Зөһрә туа, декрет ялына китә. Декреттан соң янә шунда ук эшкә чыга. Беркөнне хезмәткәрләр киңәшмәгә җыела. Шул көнне Гөлнара бер ханым белән таныша. Булачак җитәкчесе Фазулшина Зөбәрҗәт Мөнир кызы була ул. Эшкә – ЗАГСка ул чакыра аны. Тәвәккәлләп, ризалаша.

– ЗАГСның ни икәнен дә белмим. Ризалашканчы, кайтып Фердинанд белән киңәштем. «Булдырасың», – ди. Башкарма комитетка барып сөйләштек. Бу эшнең ни икәнен аңламагач, каушамаганмын да, күрәсең. Югары белем кирәк булачак, диделәр. Читтән торып Мәдәният институтын тәмамладым. Беренче көннән үк никах тантанасын алып баруны тапшырулар... Иң беренчесен бүгенгедәй хәтерлим. Йөрәк күкрәк читлеген ватардай булып тибә, хәтта блузка аша сизелә иде бугай...

Шуннан соң 15 ел узган инде. Гөлнара Хафизова ул арада меңләгән парларны кавыштырган.

Һәрбер никах тантанасы – мини спектакль. Көненә 50 шәр пар теркәгән вакытлар да булды. ЗАГС хезмәткәре бер үк вакытта психолог та, юрист та, мәдәният хезмәткәре дә.

Читтән караганда гына ЗАГС – роза чәчәкләре, шампан шәрабы исе аңкып торган тоташ бәйрәм ул. Узган елның декабрендә ЗАГС хезмәте үзенең йөз еллыгын билгеләп үтте. Йөз ел элек СССР хөкүмәте халыкның туу, үлү һәм никахка керү эшләрен чиркәү белән мәчет вәкаләтләреннән алып, дәүләт карамагына тапшырган. Метрика кенәгәләрен дә ЗАГС архивына биргән. Бүген дә ЗАГС эше – иң җаваплы өлкә. Җаваплылык дәрәҗәсе бер хәреф белән үлчәнә. Таныклыкларда бер генә хәреф дөрес язылмаса да, кешеләргә бик күп ишекләрне



шакырга туры киләчәк. Шуңа да анда эшләүчеләрнең мәшәкатьләрен, әкиятләрдәгечә, тарыны бодайдан аеру белән чагыштырып буладыр: үзе вак, үзе үтә дә әһәмиятле эш.

– Гөлнара ЗАГСта эшли башлагач («Мин аны ЗАГСка кияүгә бирдем», – дип шаярта бу урында Фердинанд абый. – *авт.*), безнең гаиләдә тормыш режимы да үзгәрде. Ләкин мин аның көнне төнгә ялгап эшләвен аңлыйм, чөнки үзем дә кешеләр белән эшли торган һөнәр иясе, үземнең дә төнге унберләргә кадәр эшләгән чакларым күп була иде. Гөлнара үз эшенә шулкадәр бирелгән, һәрбер никах тантанасына бик җаваплы итеп әзерләнә, – дип сөйли Фердинанд Хафизов. Гөлнара Рәсим кызының бөтен күңелен биреп эшләвен аның башка җитәкчеләре дә – Гөлнара Рәшит кызы да, Альбина Рафаиль кызы да бик тиз күреп ала. Казан ЗАГС Идарәсенең башлыгы Римма Шамил кызы Миңнуллина белән бүген иңгә-иң куеп эшлиләр. 2013 елда Альбина Шәвәлиеваның аны ЗАГС Идарәсенең мәдәни чаралар үткәрү бүлегенә – «Казан гаилә үзәге»нә җитәкче итеп тәкъдим итүе табигый килеп чыга: Муса Җәлил урамындагы ЗАГСта эшләгән Гөлнараны бөтен шәһәр белә булыр! Никах тантаналары гына түгел, республиканың иң матур парларының алтын туйларын, гаилә бәйрәмнәрен, яшьләргә тантаналы рәвештә паспорт тапшыру кебек бихисап чараларны Гаилә үзәгендә үткәрү матур традициягә әйләнә. Үзе сценарист, үзе режиссер, үзе алып баручы да. Игътибар итсәгез, «Казан» гаилә үзәге башкалабызның яңа символына әверелде, анда көн саен йөзләрчә туй, меңнәрчә турист була. Ләкин анда һәрвакыт тәртип, чиста, теләсә кайчан килен төшерергә әзерләнгән өй кебек!
Аны чын мәгънәсендә символ итеп таныту Гөлнара Рәсим кызының да казанышы булуында шик юк. Шушы хезмәтенең әҗере дә кайткан: күптән түгел «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән исем бирелгән аңа. ЗАГС хезмәтендә бик сирәк очрый мондый исемле кешеләр.

Ә иң зур әҗере: урамда, туктап, рәхмәт әйтеп китүләре. «Рәхмәт – дога бит ул, – ди үзе бу турыда. – Инде теркәү вакытында ук кайсы гаиләнең нинди буласын алдан сиземләргә өйрәнеп бетәсең. Әлбәттә, берничә ай элек кенә үзең кавыштырган парга «аерылды» дигән мөһер сугу күңелле хәл түгел. Кызганыч, андыйлар да була. Берсендә, ай үтмәстән, яшь хатын аерылам, дип килеп җиткән. Ике хатын-кыз, сердәш булып, бик озак сөйләшеп утырдык. Нәтиҗәдә, яшь хатын кире уйлады. Төгәл дүрт елдан әлеге пар очраклы гына каршыбызга очрады. Бәбиләрен саф һавага алып чыкканнар… Бәхетләренә сокланырлык!

Берсендә әни кеше елый да елый. Ахырдан түзмәдем, килеп, киявегез шундый әйбәт кешегә охшаган, борчылмагыз, барысы да яхшы булыр, дип юата башлаган идем. «Кияү түгел, улым ул минем», – дип төзәтте. Килене нәкъ кайнанасына охшаган булып чыкты. Ныклы гаилә булгандыр, дип ышанасы килә.

Ныклы гаилә, дигәннән… Менә үзләре дә озакламый көмеш туйларын билгеләячәк икән бит! Бик күпләргә Гаилә кодексының нигезләрен аңлатканда, Гөлнара Рәсим кызы үзенең дә гаиләсен күз алдында тоткандыр. Ә хыялдагы теге йортны, Гөлнара белән Фердинанд өйләнешкәннән соң, бер ел узуга төзи башлыйлар.

– Гөлнарага өйләнгәнче, мин коры кеше идем. Ул мине назлы булырга да, көчле булырга да өйрәтте, – ди Фердинанд Хафизов.

Хатын-кызлар белә булыр: ир кешедән мондый сүз ишетү – медальгә тиң! Өйләрендә әле һаман нәрсә дә булса төзиләр. Күрәсең, мәхәббәтле өйдә төзү теләге табигыйдыр.

Гаиләләрен дә әнә шулай гел уңай, акыллы, мәхәббәт хисләреннән генә төзегән бит алар.

– Гаиләдә ир – ир урынында, хатын хатын урынында булырга тиеш. Һәм бер-береңә карата тирән ихтирам булсын. Яратуның нигезе ул. Мин ЗАГСта эшли башлаганда, Зөһрәбезгә 2 яшь иде. Без аны кешеләргә ихтирамлы, мәрхәмәтле бул, дип тәрбияләдек. Мәктәп, дисәң… Юк, без аны әллә нинди кәттә мәктәпләрдә укытмадык. Анысы күрсәткеч түгел, күңеле чиста булсын, дип тырыштык. Моның өчен үзең үрнәк булырга тиешсең.

– Кызым, рәхмәт, йөзгә кызыллык китермәдең, уңышларың белән сөендереп торасың, – дип котлый аны әнисе, күптән түгел генә узган түгәрәк датасын билгеләгәндә…

– Рәхмәт, кызым, горурлыгым булдың, – ди аңа әнисе, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин кулыннан «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» исемен алганда…

– Рәхмәт, әни, догаларың өчен! – ди Гөлнара ханым һәр көнне иртәнге биштән торып, гаиләсенә ашарга әзерләп, иренә, кызына көн буена җитәрлек игътибарын биреп эшкә йөгергәндә…

PRESSA.RU



КАГЫЛМАГЫЗ МИНӘ!



Гөлнур
САФИУЛЛИНА

«СИНЕ ОШАТКАНГА КҮРӘ БӘЙЛӘНМИ БИТ УЛ ҖИТӘКЧЕ ИР-АТ, – ДИ ӨЧЕНЧЕ ӘҢГӘМӘДӘШЕМ.

– Аның кулында – власть, ул хуҗа, «кул астымдагы бу хатын-кызга мин акча түлим, димәк, мин нәрсә теләсәм, ул шуны эшләргә тиеш», дип саный. Хәтта синең тәнеңә дә үзен хуҗа дип белә. Чибәр дә булсаң, нәфесе тагын да котыра гына. Үзенә каршы төшүләргә ул ияләшмәгән. Аның белән йоклаудан баш тартуың шуңа да ачуын кабарта – сине ээзәрлекли, түбәнсетә, кимсетә башлый».

Аспирантурага укырга кергәндә миңа 21 яшь иде. Бу вакытта инде кияүгә чыккан, әни булырга да өлгергән идем. Җитәкчем – әтиемнән дә олырак яшьтәге ир-ат. Шуңа күрәдер инде, башта үземә аерым игътибар күрсәтүен, төртмәле сүзләрен, читләтеп нидер әйтергә тырышуын мин озак кына аңламадым. 65 яшьлек ир кеше кызы кебек яшь-яшь хатынга ничек өметләнсен?! Бу минем беренче ялгышым булгандыр. Шунда ук кырт кисеп туктатмавымны ул үзенчә аңлады бугай: ачыктан-ачык бәйләнергә кереште. «Мин бит сиңа диссертацияңне якларга ярдәм итәчәкмен, кирәкле кешеләр белән таныштырачакмын», – ди. Үзе янына килүләрне гел кичке якта билгели башлады. Берничә тапкыр дус кызларымны ияртеп барып карадым: ул көннәрне мине бөтенләй кабул итмәде. Кечкенә улымны җитәкләп бардым – тагын ишек төбеннән кире борды. Ачулануы йөзенә чыккан иде... Мин килүгә бүлмә ишеген бикләп куя. Шуннан башлана... «Сез нишлисез?! Минем – ирем, сезнең хатыныгыз бар килеш!» – дип әйтеп карыйм. «Булса соң?! Аларның үз урыны», – ди. «Мин сезне – хатын-кызларны аңламыйм. Нигә җәллисездер? Бер тапкыр булганнан нәрсә үзгәрә? Бәби тап, дип сорамыйм бит синнән», – ди.

Аптырагач, иремә сөйләдем. Аның белән ул чакта аралар шактый суык иде безнең. Әллә шуңа бер дә исе китмәде. «Моңа син үзең гаепле», – диде. Дөрес, бөтен кеше белән дә ачык итеп сөйләшәм анысы... Институт ишеген ачып керү газапка әйләнде. Ташладым аспирантураны – башка юл күрмәдем...

...Танышларым аша бер җырчының төркеменә концерт алып баручы эзләвен ишеттем. Минем дә андый хыялым бар иде! Тәвәккәлләдем. Таныштык, сөйләштек, берничә шигырь әзерләп килергә кушты. Ул чакырган вакытка кабат киттем. Мәдәният сараеның залына барып кердем. Буш, караңгы зал. Җырчы үзе генә. Сәхнәдә тонык кына ут яна – ул миңа шунда күтәрелергә кушты. Ятлаган шигырьләремне сөйли башладым. Тик ул мине бик тиз туктатты. Озын күлмәк кигән идем, «Итәгеңне азрак күтәр әле. Әллә нәрсә уйлама, сиңа бит сәхнә күлмәге тектерергә кирәк булачак – аякларыңны күрергә кирәк миңа», – ди. Аннан: «Бу шигырьләр ярамый әле, әйдә, башкаларны бирәм», – дип, сәхнә артына ияртеп кереп китте. Бүлмәгә алдан мине уздырды һәм... ишекне бикләп куйды. Сәхнә кирәк-ярагы саклый торган тар гына чолан иде бугай ул – борылырга да урын юк... Көчем бик тиз бетте. «Мин – кыз кеше, аннары ничек яшәрмен?» – дип елавым гына айнытып җибәрде аны. «18 яшьтәме?» – дип гаҗәпләнде. Аның җырлавын хәзер дә тыңлый алмыйм...

...Мин дә шундый бер азгын җитәкчегә очрадым... Бездә кыз баланы мондый ир-атларга ничек каршы торырга икәнен өйрәтеп үстермиләр шул. Җитәкче урындыгына утырган ир-ат исә үзен дөньяның кендеге дип белә – нәрсә эшләсәм дә ярый, килешә дип саный. Ә мин яшь, тәҗрибәсез идем. Күңелем дә бик нечкә... «Юк» дигән сүзне, бәлки, өздереп әйтә дә алмагандыр. Шулкадәр тупас иде ул! Тормышымны җәһәннәмгә әйләндерде. Коллективта аның миңа бәйләнүен барысы да белә иде, әмма беркем яклап чыкмады. Теләгәненә ирешмәгәч, эш буенча үчләшә башлады. Ике тапкыр «шелтә» белдерде. Иң кызыгы: берничә көннән, приказ белән, ул «шелтә»не кире ала иде. Ике ел түздем... Дөрес, бу арада мине «онытып» торып, башкаларга да бәйләнгәләп алды – сәркатибенә, бухгалтерына... Шуңа күрә генә болай озак түзә алганмындыр. Эшемне бик яратсам да, китәргә туры килде. Китеп, дөрес эшләдем дип уйлыйм. Хәзер барысы да онытылды инде: аннан киткәч, озак гомерләр эшкә урнаша алмавым (анысы да элеккеге җитәкчемнең «тырышлыгы» булып чыкты»!), фатирга түләргә дә акчам булмый тилмерүләрем, үртәлүем...

Әмма бөтен кеше дә сезнең якка басар дип өметләнмәгез – күпләр үзегезне үк гаепләячәк.

Бүгенге язмада сүзнең ни хакында барганын аңлагансыздыр инде.

«Җитәкчем бәйләнә, миңа нишләргә икән?» – дигән сорау хатын-кыз форумнарында бик еш яңгырый. Дөрес, рәсми мәгълүматларга караганда, эш урынында мондый күренеш белән бездә хатын-кызларның 15 проценты гына очраша. Тик бу сан бик шикләндерә: әле генә сезгә сөйләгәннәрнең берсен дә мин бит уйлап чыгармадым һәм бу темага тотынгач, ишеткән тарихларымның барысын да кәгазьгә дә төшермәдем. Кайдан килеп төгәл булсын инде ул: мондый бәйләнүләр бездә җинаять саналмый – беркайда теркәлми, хатын-кыз үзе бу хакта кычкырып йөрми.

Хәер, нигә бездә генә? Узган ел ахырында Америкада кинопродюсер Харви Вайнштейн белән бәйле зур тавыш чыкты. Дистәләгән актриса аның кайчандыр үзләренә бәйләнүе, хәтта көчләве хакында ачыктан-ачык сөйләделәр. Ума Турман, мәсәлән, туксанынчы еллар уртасында Лондонның бер кунакханәсендә булган хәлләрне искә төшерде:

– Вайнштейн мине этеп екты, үзе чишенә башлады... Мин теләмәгән нәрсәләрне эшләргә мәҗбүр итте, – диде ул. – Мондый чакта үзеңне ерткыч кулына эләккән корбан кебек тоясың икән...

Шуңа күрә 25 ел буе ул да, башкалар да моны сер итеп саклаган инде. Карьераларына зыян килүдән, исемнәренә тап төшүдән курыкканнар. Югыйсә Америка хатын-кызлары, бездән аермалы буларак, ир-атның «игътибары» ничә төрле булуына кадәр белә диләр. Кая ул кул белән кагылу, яшерен теләге барлыгын сиздереп, беркемнең сиңа хәтта карарга да хакы юк анда! Тик закон алар ягында булса да, дәшмәгәннәр шул әнә, оялганнар...

Фото: www.pixabay

PRESSA.RU

Эштәге харассмент турында күздән бирле бездә дә еш сөйлиләр (җитәкченең сине үзе белән түшәккә ятарга кыстап бәйләнүләрен харассмент дип атыйлар). Башта ул сиңа ялгыш кына тиеп киткән кебек була: күрешкәндә, аркаңнан кочып ала, кулыңа кагыла, беләгеңнән тота... Аннан ике төрле уйларга урын кала торган сүзләр әйткәли башлый. («Үземнән бик олы кеше булгач, аның бу сүзләреннән начар мәгънә эзләмәдем, шаяртадыр дип уйладым һәм... ялгыштым», – ди беренче әңгәмәдәшем.) Бераздан, төрле сәбәп табып, эштән соң калырга куша. («Эш сәгате бетәр вакыт җиткәндә, күзенә чалынмас өчен, кабинетымнан чыкмаска тырыша идем. Хезмәттәшләрең кайтырга кузгалганда, аларга ияреп чыгып китә алсаң, бәхетле буласың», – дип сөйли өченче әңгәмәдәшем.) Аннан инде ачыктан-ачык әйтеп бәйләнүгә күчә: «Минем белән булмыйсың икән, эштән куам (хезмәт хакыңны кисәм)». («Бергә командировкага баруны шундый оста итеп оештырды, сизми дә калдым. Ничек баш тарта аласың – эш буенча бит... Юлга өчәү чыктык анысы, әмма кунакханәгә урнашканда – аерылдык. Мин, әлбәттә, җитәкчем белән бер кунакханәдә калырга тиеш булып чыктым... Шуннан кайткач, «китәм» дип гариза яздым да инде», – боларын да өченче әңгәмәдәшем сөйли.)

Юк, андый чакта хатын-кыз ир-атны җиңә алмый икән.

Җитәкче ир-ат сиңа хатын-кыз буларак гап-гади игътибар күрсәтәме, әллә чын-чынлап бәйләнәме? Боларны син үзең генә барысын уйлап чыгармыйсыңмы, бәлки ул сиңа шулай дип тоела гынадыр? Хәер, утсыз төтен булмый инде анысы... Кыен хәлгә тарыган хатын-кыз моны флирттан – гыйшык уены уйнаудан башта ук бик тиз аера, диләр. Аның уйнап сөйләшүе сиңа ошамый, шикләндерә, куркыта, «юк» диюләреңне ул ишетми, кире кагуларыңны кабул итми икән – бу инде бәйләнү була. Ә инде ачыктан-ачык йокларга тәкъдим итсә, икеләнергә бөтенләй урын калмый – яраткан кеше бу адымга бармый. Ярату дигәннән, җитәкче – ялгыз ир-ат, ә сез кияүгә чыкмаган кыз икән, ике арада мәхәббәт тә кабынырга мөмкин, әлбәттә. Мәхәббәтнең сез икегез дә гаиләле булган очракта да кабыну ихтималы юк түгел. Тормыш бит бу... Тик без бу хакта сөйләшмибез әле бүген.

Җитәкчесе бәйләнгән хатын-кызга нишләргә соң инде? Бу катлаулы хәлдән ничек чыгарга? Ни гаҗәп, белгечләр һәр очракта да моның сәбәбен хатын-кызга башта үзеннән эзләргә кушалар. («Ир-ат сиңа бәйләнү генә түгел, хәтта көчләсә дә, барыбер үзең гаепле булып каласың. Безнең җәмгыятьтә шулай бит... Шуңа мин җырчының үземне харап итә язуын дөньяга фаш итә алмадым, милициягә гариза язмадым. Бөтен кеше миннән көләчәк кенә иде... Бу хакта онытсам, яхшырак булыр дип уйладым», – ди икенче әңгәмәдәшем.)

Киңәшләргә күчик. Вайнштейн белән булган гаугадан соң, җитәкче янында үзеңне ничек тотарга кирәклеге турында экспертлар махсус киңәшләр тупланмасы тәкъдим итте. Сезнең хакта аңарда икеле-микеле уйлар тумасын өчен кирәк болар.

■ Хатын-кыз иң элек кигән киеменә, тышкы кыяфәтенә игътибар итсен, эштә дресс-код сакланырга тиеш, ди алар. Артык ачык яки бик кыска киенмисезме? Макияжыгыз нинди: бик күзгә ташланырлык итеп буянмыйсызмы?

■ Җитәкче алдында ничек утыруыгыз да мөһим, мәсәлән, тезне тезгә куеп утырырга кирәкми.

■ Эшкә урнашканда, гаилә хәлегез белән ул, әлбәттә, кызыксыначак. Әлегә ялгыз булсагыз да, «йөргән кешем» бар дисәгез хәерлерәк.

■ Җитәкче белән бары тик эш турында гына сөйләшергә тырышыгыз.

■ Ул сезнең янга артык якын килеп утыра дип санырсыз икән, күченеп утырудан тартынмагыз: бу сезнең ике арада дистанция сакларга теләвегез турында сөйләячәк.

■ Соңрак китүегезне сорый икән, алдан ук: «Эш буенча кирәк булсам гына, калам», – дип кисәтергә онытмагыз.

■ Кулы белән кагылып китүләрен ошатмавыгызны сиздерегез.

Боларның ярдәме тимәсә, алга таба нишләргә?

Белгечләр дә үзен кире кагуны теләсә кайсы ир-ат бик авыр кичерә, диләр. Җитәкче урынында утыручылар – бигрәк тә. Өстәвенә, бу хакта коллектив та хәбәрдар булса... (Мондый хәлне тирә-юньдәгеләрдән сер итеп сакламаска да куша белгечләр. Бәлки, инде бу беренче генә очрак түгелдер – сездән алдагылар аны ничек хәл иткән, нишләгән – биредә озак эшләүче хезмәттәшләрегез акыллы, урынлы киңәш тә бирә ала бит.)

Сезнең өч юлыгыз бар. (Дүртенчесен, җитәкченең азгын теләге белән ризалашып, аның сөяркәсенә әйләнүне санамыйбыз.)

Беренчесе – җитәкче белән аңлашу. Ир-ат белән хатын-кызның төрле галәмнәрдән икәнен күптән беләбез: читләп әйтергә тырышуларны ир-ат гомерендә дә аңламаячак – әйтергә теләгәнеңне аңа турыдан-туры, ачыктан-ачык җиткерергә кирәк. «Фәлән Фәләнович, мин икебез арасында мондый мөнәсәбәтләр булуын теләмим. Эшемне бик яратам, сезне дә ихтирам итәм. Мине аңлавыгызны телим», – диярга. (Үзенә бәйләнгән җитәкчегә бер танышым: «Мин балага узудан, аборт ясатудан бик куркам. Шуңа күрә ир-ат белән булу миңа бер рәхәтлек бирми – ирем белән дә йокламаска тырышам. Сез дә кагылмасагыз иде», – дигән иде. Ачыктан-ачык шушы бер сөйләшү җитте: җитәкче аны тынычлыкта калдырды.) Әмма бу сүзләрне тавыш күтәреп, ачуланып, ярсып түгел, тыныч кына әйтергә тырышыгыз. Бу сөйләшү, әлбәттә, кеше күз алдында булырга тиеш түгел.

Алга таба нәрсә эшләячәгегез, аның бу сүзләрне ничек кабул итүенә бәйле булачак.

Икенче юл – җитәкчене акылга утырту. Судка мөрәҗәгать итәргә җыенасыз икән, кул астында аны

гаепләрлек дәлилләрегез булсын. Моның өчен сөйләшүләрегезне, телефоннан шалтыратуларын диктофонга яздырып барырга, җибәргән «смс»ларыннан скриншот ясарга кирәк. Видеога төшерә алсагыз, тагын да әйбәт. Үзегез әйткән сүзләрне, аны ничек кире кагуыгызны да яздырыгыз. Теләмәсәгез дә, хезмәттәшләрегез алдында ачылырга туры килер – судта сезгә шаһитлар да кирәк булачак.

Ярый, судка гариза тапшырдыгыз, ди. Һәм... бу хәлгә шуның белән нокта куелырга да мөмкин. Алдарак әйткәнемчә, бәйләнү бездә җинаять дип саналмый. РФнең Җинаятьләр кодексында шантаж юлы белән якынлык кылырга мәҗбүр иткән өчен генә статья бар. 2014 елны Дәүләт Думасында кодекска «бәйләнү» белән бәйле хокук бозулар буенча статья өстәү турында закон проекты каралды. Җәза итеп 30 меңнән 50 меңгә кадәр штраф түләтү яки мәҗбүри эшләргә җибәрү каралган иде. Мондый хәл тагын кабатланса, штраф күләме дә, мәҗбүри эш сәгатьләре дә икеләтә артырга тиеш иде. Әммa депутатлар, «бәйләнү» дип нәрсәләрне санарга дигән сорауда, уртак фикергә килә алмадылар – закон проекты шулай кабул ителми калды.

Өченче юл – үз телеңгең белән эштән китү. Шәрехләп тормасаң да аңлашыла – көчеңне бу мәгънәсез көрәшкә исраф итмәвең хәерлерәк. Хатын-кыз буларак сине түбәнсетә, кимсетә торган көрәшкә... («Ул миннән артист ясыйм, дигән иде. Соңыннан да әллә ничә тапкыр сүз кузгатты. Сәхнә турында кечкенәдән хыяллансам да, ризалашмадым. Мондый юл белән яулаган уңышлар кирәкми иде миңа», – ди икенче әңгәмәдәшем.)

ФИКЕР

Искәндәр СИРАҖИ, журналист

– Бер-бер нәрсә булса, Америка, «харассмент», дип тавыш куптара. Бөтен Европада да шушы хәл. Нәтиҗәдә, ир-ат белән хатын-кыз берберсенә якынаерга курка анда хәзер. Ирләр: «Безгә хатын-кыз җитәкчеләр бәйләнә», – ди. Хатын-кызлар: «Ир-ат җитәкчеләр», – ди. Югыйсә ир-ат белән хатын-кыз шуның өчен яратылган бит инде! Тик бүген күбрәк «ир-ат белән ир-ат, хатын-кыз белән хатын-кыз бер-берсе өчен яратылган» дигән фикерне ишетәсең.

Юк, мин бәйләнүләрне дөрес нәрсә димим. Әмма ул гомер-гомергә Россиядә булган (крепостнойлык чорында барин крестьянкалар артыннан чабып йөрмәгәнме?!) һәм бар. Әмма бу хакта беркем дә дәшми, дәшмәячәк тә. Әйтик заманында Билл Клинтонны стажер кыз Моника Левинскины «кыскан» өчен бөтен дөньяга хур иттеләр. Ә безнең илдә, әйтик, кайсы да булса бер министрны шулай тикшерүләрен күз алдына китерә аласызмы? Беркайчан да! Юк, андый гаугалар чыгармаячаклар. Бу илдә, кызганыч, күп законнар эшләми һәм эшләмәячәк.

Бу адымга хатын-кыз ир-атны үзе этәрә дип уйламыйм. Шундый хәл булган икән – монда ике як та гаепле. Урыста «ана эт теләмәсә, ата эт аның өстенә сикереп менми», дигән әйтем бар... Тик, эш судка барып җиткән очракта, бездә күбрәк хатын-кыз сүзенә карыйлар. Әмма монысы инде аның бөтенләй икенче проблема.

Хатын-кызны аны яратырга, хөрмәт итәргә кирәк. Шул очракта ул чын хатын-кызга әйләнәчәк, үзе дә ир-атны кадерли, аңа ир кеше итеп карый башлаячак. Ә бүген хатын-кыз, ир-ат шикелле киенеп, алар шикелле эшли, гаиләне тәэмин итә. Җәмгыятьтә вазгыять дөрес түгел: безгә хас булмаган тормыш кыйммәтләре килеп керде. Татарда хатын-кыз җил-яңгырдан һәрвакыт сакланган булган – аның өчен ир-ат җаваплылык тойган. Бүгенге ир-атта бу җаваплылык юк, хатын-кызга хезмәтче итеп кенә карау процессы бара. Хатын-кызлар да инде ир-атны үзенең саклаучысы, яклаучысы, туендыручысы, әфәндесе итеп карамый, ә диванда ятучы бер эшлексез, имгәк, булдыксыз, ялкау дип саный. Шуны балалар күреп үсә. Әлбәттә, оясында ни күрсә, аннан очканда шуны кабатлаячак.

Бу мәсьәләләрдә Американы бөтенләй аңламыйм! Урамга чыгып, 25 ел элек Вайнштейн миңа кул салды, дип игълан иткән хатын кем була инде ул?! Ә ни өчен соң ул аны чирек гасыр элек әйтмәгән? Яңа исенә төшергән.

Табигатьтә «табигый сайланыш» дигән әйбер бар: сәламәт булмаганнар анда юкка чыгып барырга тиеш. Американнарча болай фикер йөртү дә – сәламәт фикер йөртү түгел: болар шуның белән әкрен генә үлеп бетәчәк. Бу Европага да кагыла. Әнә Нидерландның Премьер-министры хатынын «беренче леди» диясе урынга «беренче джентльмен» дип язганнар. Җәмгыяте ир кеше бит. Шушы кыйммәтләрне алар безгә дә тагып маташалар. Вайнштейн турында тавыш чыгарулары да шуңа. Килер бер көн, бер хатын бездә дә беренче булыр. Шулай итеп ул үзен күрсәтәчәк! «Кыйнады», – дип, Марат Бәшаровның хатыны тавыш чыгарды бит менә. Гәрчә бөтен кеше: «Марат кул күтәрә торган ир-ат түгел, эчкәч ул хатын үзенең нишләгәнен белми», – дип әйтеп тора. Ә менә хатыны үзен бөтен дөньяга күрсәтеп алды. Аның кебек йолдыз булырга теләүчеләр тагын килеп чыгачак. Диана Шурыгина, мәсәлән. Без андый кыз барын да белми идек. Ә хәзер 14-15 яшьлек кызлар аның ролендә булырга кызыга. Йолдыз булу өчен бүген синең кем беләндер йоклавың, ә аннан «көчләделәр» дип кычкыруың һәм бу хакта «Пусть говорят»ка килеп сөйләвең генә кирәк икән бит...

Бу дөньяда һәрчак сайлау мөмкинлеге бар. Әгәр миңа, мәсәлән, каядыр, нәрсәдер язарга рөхсәт итмиләр икән, мин аннан китәм генә. Хатын-кыз да китәргә тиеш. Китми икән, димәк, ул шушы хәлдән канәгать.

PRESSA.RU

МИН БУ МӘКАЛӘНЕ ИР-АТЛАРНЫҢ ДА УКУЫН ТЕЛӘР ИДЕМ. ҺӘМ, УКЫГАЧ, ХАТЫН-КЫЗЛАРГА ШУЛАЙ ДИП ӘЙТҮЛӘРЕН.

СИН БӘХЕТЛЕ БУЛЫРГА ТИЕШ!



Ландыш ӘБҮДӘРОВА

Янгыннан да куркам, ярсыган айгырдан да...

Бу мәкаләне белгеч буларак язмыйм. «Көн саен иртән тору белән көзгегә карап: «Мин – ханбикә!» – дип кабатлагыз», дигән хикмәтле җөмләләр белән киңәш бирә торган психолог та, псевдопсихолог та түгелмен. Мондый киңәшләргә егылып төшеп колак сала торганнардан да түгел. Көзге белән сөйләшә торган итеп тәрбияләмәделәр безне. Мине, башка бик күпләр кебек үк: «Син кыз кеше», – дип үстерделәр. Бу җөмләгә бик күп мәгънә сыйган икән, кабатлаган саен яңа мәгънә өстәлә барган. Аны беренче тапкыр, мөгаен, урамнан пычранып кайткач әйткәннәрдер: «Кыз кеше болай пычранып йөрми инде...» Димәк, кыз кеше чиста, пөхтә йөри. Икенче тапкырында үземне яклап, берәр малай белән сугышып кайткач: «Кыз кешегә сугышып йөрү килешми...» – дип ишеткәнмендер. Димәк, кыз кеше йодрык катнашу ихтималы булган вазгыятьтән читтәрәк булырга тырыша. Моңа аның акылы җитәргә тиеш. Өченчесендә малайлар белән атка атланып чаба башлагач ачуланганнардыр: «Ирдәүкә!» – диярләр!» Юк инде, ирдәүкә үк буласы килми, дип, бу юлы тиз баш тартканмындыр...

Шундый буын балалары инде: без сугыштан исән кайткан ирләрен кадерләргә өйрәнгән әбиләр тәрбиясендә үстек. Бу вакытта Европа феминизмы эмансипациясенең икенче дулкыны булган, ә совет авылы әбиләренең анда ни эше бар? Өстәвенә, мәктәптә укыганда, Николай Некрасовның рус хатын-кызлары турында әйткән канатлы сүзе янып торган кызыл хәрефләр белән күңелгә уелып калган: «И коня на скаку остановит, и в горящую избу войдет...» Әбием шундыйлардан иде. Сугыш вакытында үсмер көенә ат түгел, үгез җигеп йөргән. Гәрчә үзем янгыннан да куркам, ярсыган айгырдан да. Калганына түзә аламдыр... Чын татар кызлары кебек, чөнки үсмер вакытта (туксанынчы елларга туры килде ул) теге «син кыз кеше» дигән җөмлә бераз үзгәрде: «Син – татар кызы». Милләт йөкләмәсе Зөһрә кыз кебек тыйнак, тырыш һәм карусыз, Сөембикә кебек горур, Зөләйха кебек сабыр булырга куша иде. Ләкин милләт безнең балигъльлык чорына хатын-кызны асыл зат итә торган асылташлар белән бизәп эшләнгән чулпысыннан, энҗеле калфагыннан, ефәк яулыгыннан баш тарткан иде. Затлы, кыйммәтле матурлыгы белән каймаланмагач, тыйнаклык та, тырышлык та, сабырлык та очсызланып, мескенләнеп калды. Әнә шундый тәрбия тупланмасы белән XXI гасырга килеп кердек без.

Елыйсы килде хәтта...

– Сезгә хәтта каравы кызганыч, – ди чит илгә китеп гаилә корган ватандашларыбызның берсе. Унбиш еллап инде Европада яши ул. – Берәр бала авырса, бөтен ил белән акча җыясыз. Дәваханәдә чират торып гомерегез үтә, табиблардан хәер көткән кебек ярдәм өмет итәсез. Әбием: «Чалбарлы булган өчен генә кияүгә чыкма», – дип әйтә иде, ни әйтергә теләгәнен беренче ирем белән яши башлагач кына аңладым. Классика инде: бергигез эшлибез, кич эштән кайткач, ул арып диванга ава, мин баланың дәресен карашам, ашарга әзерлим, иртәгәсе көн өчен киемнәр үтүклим. Йокларга яткач, сораганын да бир: Алла сакласын, сөяркәләр сагалап кына тора!

Европада икенче тапкыр кияүгә шведка чыктым. Алар эшне хатын-кызныкы, ирнеке, дип бүлмиләр. Ашарга да пешерә, кер юып үтүкли, җыештыра да. Баштарак моңа аптырый идем. Хәтта ирем эштән кайт-канчы ашарга әзерләп өлгертмәвем өчен ояла идем. Ә ул кибеткә барып азык-төлек алудан да баш тартмый, үзе әзерли. Һәм бу аның мин-минлегенә бер дә тими. Акчаны да синеке-минеке дип бүлмибез. Эшләгәнебез – уртак. Россиядә кайбер хатын-кызлар иренең ялкаулыгын танырга теләмичә, бөтен гаепне хөкүмәткә сылтап, гаиләсен үз җилкәсендә тартып бара яисә ир эшләгән акча – безнеке, мин эшләгән – минеке, дип туздыра, – дип тәмамлады хатын милләттәшем. Аргументларына каршы җавап та язасы килгән иде, ләкин ышандырырлык дәлилләр таба алмадым.

Мин кияүгә чыккач...

«Минем кызым кияү күргәнмени?» дигәндәй, ничек өйрәткәннәр, шулай итеп ир хатыны булып яши башлыйбыз инде без гадәттә. Оясында ни күрсә кебегрәк. Ә безне иргә хезмәт итәргә өйрәттеләр...

Иң күңеллесе бала тугач башлана икән аның. «Бер бала кирәкме – кияүгә чык, икәү кирәк булса – бәби алып кайт», дигән мәзәкне безнең хатыннар гына уйлап чыгаруына иманым камил. Бала тудыру йортында алты кешелек палатада без барыбыз да Туфан Миңнуллинның «Әниләр һәм бәбиләр»ендәге Гөлфиналәр идек.

– И Ходаем инде, ашамадыңмыни? Күп итеп пилмән ясап киттем бит, суыткычтан алып, шулпага гына саласы... Туйдың? Ә, ярар алайса, Алма апага әйтермен, кичкә берәр нәрсә пешереп куяр, кайтышлый кереп ашап чыгарсың. Оекларың шкафның аскы киштәсендә генә, алыштырып йөр... – күрше караватта ята торган Айгөл бу. Без, ирексездән бу сөйләшүнең шаһитлары, Айгөл, әниләрчә кайгыртучанлык күрсәтеп, улы белән сөйләшәдер, дип уйладык. Трубканы куйгач, әллә әрнеп, әллә канәгатьлек белән: «Әй бу ир дигәнең, минсез бер көн дә тора алмый бит!» – дигәч кенә аңладык. Күзләрендә яшь мөлдери – ирен кызгана. «Ә нәрсәгә хатын-кызга үзен яратырга? Ул гаиләсен, ирен, балаларын яратырга тиеш. Бу җирдәге төп бурычы ул аның», – дип кырт кисә ул кайберәүләребезнең «акыл сатуын».

Ул арада телефон шалтырый. Минекеләр килгән. Аскы катка йөгерәм, тәрәзә аша гына телефоннан сөйләшәбез. Үзем елыйм: шундый нәүмиз тоелалар. Минсез кыендыр аларга, бик кыендыр кебек...

Декрет ялында утырганда хатын-кыз танымаслык булып үзгәрә дигәннәр иде. Дөреслеккә туры килә бу сүзләр. Мәсәлән, ул үзе турында оныта һәм үзен гаиләсенә багышлый. Ул үзенә яңа әйберләр алмый башлый, нәрсәдер ала башласа, моны киеп кая барам инде, барыбер өйдә утырам, дигәнрәк сүзләр белән аклана. Чәч ясатырга да, тырнакка да вакыт җәл: баланы саф һавага алып чыгасы, кичке ашка берәр тәмлерәк нәрсә пешереп, ирне шаккаттырасы бар. Эш шул дәрәҗәгә барып җитә ки, ялгыш кына чирләп китсә, үзен гаепле сизә хәтта. Бездәге күп кенә хатын-кызларның «әйбәт хатын», «әйбәт әни» дигән төшенчәсе үз-үзен гаиләсенә корбан итү булып аңлашыла. Берсендә күршем 2 яшьлек кызы турында болай дип сөйләгән иде: «Кибеткә кердек. Кызым туңдырма алырга үгетли. Ризалаштым. Әтигә, абыйга, үземә, дип өч туңдырма алып салды кәрзингә. «Ә миңа кая?» – дим. – «Син бит барыбер ашамыйсың», – ди. Менә үстер инде син аларны төн йокыларыңны калдырып!» Узган җәй савыттагы иң соңгы төче чияне алып капкан идем. Нинди сәер тынлык дип, игътибар итсәм, түп-түгәрәк алты күз карап тора үземә... Ачлык вакытымыни?! Күршемнең сүзләре исемә төште...

Тиеш, тиеш, тиеш...

Бүген исә «Хатын-кыз бәхетле булырга тиеш, шуннан башка ул беркемгә дә, бернәрсә дә тиеш түгел», дигән бер җор гыйбарә йөри интернетта. Ышанасы килә. Гаиләдә хатын-кыз бәхетле булса, башкаларга да йога ул.

Исемен хәтерләмим, хатын-кызларны үзен яратырга өйрәтә торган методика авторларының берсе «Сез үзегез өчен бүгеннән нәрсә эшләргә ӘЗЕР?» дигән сорауга 50 төрле җавап языгыз дигән бирем биргән иде. «Хатын-кызлар, – ди ул, – теләкләрен тормышка ашырырга әзер түгел. Еш кына ул үз теләкләренә үзе киртә була». Ягъни исемлек – хатын-кыз өчен үзенә күрә лакмус кәгазе ул. Ул никадәр озын булса, хатын-кыз үзен шуның кадәр ярата дигән сүз. Бу исемлеккә кибеттән үзегез сатып алырга теләгән әйберләр дә, чәчтарашханәгә барып чәч кистерү дә, опера тыңлар өчен башкалага барып кайту да керә. Сез дә язып карагыз әле.

Бик тырышсам да, исемлекне иллегә тутыра алмадым үзем. Менә хәзер макияжны юып, пилинг, битлек, крем сыларга кирәк булыр. Калганы иртәгә, иртәгә...

P. S. Ә сез үзегез өчен бүген нәрсә эшләдегез? Киңәшләр, тәкъдимнәр белән хатлар көтәм.

Үз-үзеңә бәяне күтәрү өчен өйдәниләр эшләп була

- төрле юнәлештәге әдәбият уку интеллектны күтәрә;
- даими рәвештә аутотренинг үз-үзеңә бәяне кинәт төшүеннән саклый;
- тормыш максатларын билгеләргә кирәк (язып куярга да була);
- мактау сүзләрен җәлләми торган кешеләр белән күбрәк аралашырга;
- көнчелек, хөсетлек сыйфатлары белән даими көрәшергә;
- авыр уйлар агышын туктатырга тырышырга;
- үз-үзеңне җәлләмәскә (үзеңне корбан итеп хис итү тора-бара үз-үзеңне тәнкыйтьләүгә китерә, нәтиҗәдә, үз-үзеңә бәя дә төшә).

Фото: www.pixabay

PRESSA.RU

«ЯХШЫЛЫК ЭШЛӘРГӘ СОҢАРМАСКА ИДЕ...»

Саимә ИБРАҺИМОВАның тормыш кагыйдәләре



Фото: Ксения Богданова

Безнең әткәй Ибраһим Баһаветдинов Тукай белән бер елгы иде. Борынгы кеше булса да, әткәйнең русчасы заманы өчен яхшы булган. Чаллы кантонының Нөркәй волосте Башкарма комитеты рәисе булып эшләгән. Волость бетерелгәч, ул ЗАГС бүлеге башлыгы булган. Аннары әткәйне кулланучылар кооперациясе рәисе итеп куйганнар. Менә шушындый «кулак»... Аны «халык дошманы» дип утыртып куйдылар. Әткәй, иseme аклануын да ишетә алмый, китеп барды бу дөньядан. **Ә АНЫҢ КЕБЕКЛӘР МЕҢНӘР ИДЕ...**

Әнкәйнең элгәрләрен Соловкига озатканнар. Кайткан кеше дә булмаган. Югалганнар. Әтисе Салих хаҗи балаларны укытуга зур игътибар биргән. Әнкәй дини яктан бик укымышлы иде. Бөтен «Пәйгамбәрләр тарихы»н яттан белә, безгә сөйли... 1990 нчы елларда дини китаплар басып чыгара башладылар. Кешеләр мәдрәсәләргә йөри. Мин дә догалар күчереп алдым. Рәшидә абыстайдан намаз уку тәртипләрен өйрәнә башладым. Яшьләрнең дингә карашын күреп сөенәм. **ХӘЗЕРГЕ ЗАМАНДА БАЛАҢ НАМАЗ УКЫСЫН ӘЛЕ! ЗУР КУАНЫЧ БИТ УЛ!**

Алты кыз үстек. Шәмсеруй, Фатыйма, Зөләйха, Рәхимә, Саимә, Сафия. Нөркәй, Теләнче Тамак, Мөслим, Вәрәшбаш... Әткәйне бер эштән икенчесенә күчереп йөртү сәбәпле, бер авылдан икенчесенә килеп урнашабыз шулай. Рәхимә апа 7 нче сыйныфтан соң Алабуга педучилищесына укырга керде, аны Мөслим районының Вәрәшбаш авылына укытырга җибәрделәр. Аңа ияреп, без дә кузгалдык: абый, мин, сеңлем, әнкәй... Сыерны да калдырмадык. **ТАТАР АВЫЛЫ УЛ ЧАКТА СЫЕРСЫЗ ЯШИ АЛМЫЙ ИДЕ. Ә ХӘЗЕР – ЯШИ...**

«Җәмәгать, сезнең барыгызның да туган авылы бар, кайтыгыз шунда, халык белән сөйләшегез...» Баш мөхәррирebez шулай дип әйткәндә, миңа бик читен була иде... Әйе, **КЕШЕНЕҢ ТУГАН АВЫЛЫ БУЛЫРГА ТИЕШ.** Радиодан язучы Миргазиян Юнысның әңгәмәсен тыңладым. Ул шулхәтле яратып туган авылы Исергәп турында, әсәрләрен язганда авылдашларының сурәтләреннән образлар тудыруы турында сөйләде. Шуны ишеткәч, Миргазиянның Исергәбе кебек, үземнең Нөркәем юк бит минем дип өзгәләндем. Безне туган авылыбыз чит итте, бик озак нахакка «кулак балалары» исемен күтәреп йөрдек.

Бердәнбер Габдулла абыемны 18 яше тулганчы ук сугышка алдылар. «Кыш җиткәнче сугышка кереп чыгарга кирәк», – дип кенә язган иде. **Ә БЕЗ ӘЛЕ ҺАМАН АНЫҢ ШУЛ СУГЫШТАН ЧЫГЫП ҖИТКӘНЕН КӨТӘБЕЗ!..** Әнкәйгә «хәбәрсез югалган» дидек... Өметен сүндермәс өчен. Абый белән бергә фронтка киткән Вәрәшбаш егетенең дә хаты килгән. «Снаряд алып китте Габдулланың башын дип язган...» – дип, әнкәйгә килеп әйткәннәр...

Дүртенче курста укыганда рус әдәбияты укытучыбыз Семен Николаевич Никольский чакырып алды да матбугат йортына Абдулла Әхмәткә бер язу илтеп бирергә кушты. Барышлый ук ачып укыдым, әлбәттә. «По-моему, это тот человек, который вам нужен», – дип язылган. Балалар һәм яшьләр әдәбияты редакциясе мөдире икән барасы кешем. Өстәлгә йомшак тышлы юка гына унлап китап чыгарып салды ул. «Болар балалар өчен язылган китаплар, үзеңә ошаганнарын тәрҗемә ит», – диде. Кешеләр дәүләт имтиханнарына әзерләнә, ә мин хикәя тәрҗемә итеп ятам... **КАЙДА СОҢ УЛ АНДЫЙ КЕШЕЛӘР ХӘЗЕР?! БЕРСЕННӘН-БЕРСЕ ЯРДӘМЧЕЛ, КЕШЕЛЕКЛЕ, ХӘЛГӘ КЕРӘ ТОРГАН...**

ГОМЕРЕМ БУЕ БАЛА-ЧАГАГА ХЕЗМӘТ ИТӘРГӘ ТЫРЫШТЫМ. Балаларга дөньякүләм классик матур әдәбият үзебезнең туган телдә барып ирешергә тиеш дип уйлап, шул эшкә алындым. Антон Чеховның «Хикәяләр», «Малайлар», Стивенсонның «Кара ук», Марк Твенның «Том Сойер маҗаралары», Аркадий Гайдарның «Повестьлар һәм хикәяләр»е һәм башкалар минем тәрҗемәдә татарча басылып чыкты.

ЭШЛӘНМӘГӘН ЭШТӘН ШАЙТАН КӨЛГӘН. Әнкәй безгә шулай дип әйтә торган иде. Шуңа күрә эшләнмәгән эшләр турында алдан сөйләп булмый инде.

Бернинди рәсми кәгазьсез мин бөтен дөньясында бер беренче космонавт Юрий Гагаринның өенә барып кердем. Ә хәзер бәләкәй генә бер чиновник (хакимият башлыкларын әйтәсе дә юк) янына керә алмый җәфаланасың, керү ди синңа – телефоннан тоташа алмыйсың – йә кешесе бар, йә ашый, йә тагын шунда берәр нәрсә, диләр! **ЙӘ АЛЛАМ, НИНДИ ЗАМАНГА КАЛДЫК...**

60 нчы елларда миңа чех язучысы Ян Козакның «Марьяна Радвакова» исемле повестен тәрҗемәгә бирделәр. Үземчә бик тырышып тәрҗемә иттем. Теләгем – хезмәтемне тагын да әйбәтләү, тагын да ныграк шомарту. Моның өчен кульязманы аеруча таләпчән кеше укып, аның тәкъдимнәре тәрҗемәне тагын да яхшыртуга ярдәм итәргә тиеш дип уйлыйм. «Аеруча таләпчән» язучы дип мин Нурихан Фәттахны беләм. Әчке рецензияне кемгә бирик дип сорадылар. «Нуриханга бирегез», – дидем. Беркөнне шулай коридорда Нурихан очрый. «Карале, туган, син ул әйбереңне йә ал миннән, йә мин аны суям, – ди. – Син анда сүз, җөмлә тәрҗемә иткәнсең. Дөрес тәрҗемә ителгән алар анысы... **Ә БИТ ПРОЗАНЫҢ ДА ҮЗ РИТМЫ, ҮЗ КӨЕ БУЛЫРГА ТИЕШ...»**

ЭШЛӘРГӘ! ТУКТАУСЫЗ ӨЙРӘНЕРГӘ КИРӘК! ЮГЫЙСӘ ТУТЫГАСЫҢ! Тәрҗемә әсәрләре укылышлы килеп чыксын өчен шактый тырышырга кирәк. И-и! Ул Суворовны тәрҗемә итәр өчен ниләр генә өйрәнмәдем! Суворов әллә нинди кыяларга, тауларга менеп, каршылыклар аша үтә-үтә, җиңүләр яулаган кебек, тәрҗемәдә дә камиллеккә ирешер өчен күпме генә эзләнмәдем, ниләр генә актармадым, өйрәнмәдем. «Кастрюля с тюрей»ның татарча ни икәнен белми аптырадым. Сохари белән ясалган окрошка икән бит ул!

PRESSA.RU

МИН ГОМУМӘН БУЛМАГАННЫ ЯЗА ТОРГАН КЕШЕ ТҮГЕЛ! Язганнарым бөтенесе тормыштан алынган. Ясалма әйберләр миңа ошамый. Кысаларга кертеп язу минем стиль түгел.

АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ КИРӘКЛЕ ЮЛГА ҮЗЕ БАСТЫРА, ДИ. Язмыш ялгышлыгы буенча башка юлдан китеп, уңышларга ирешкән кешеләр бар ул. Туфан Миңнуллин белән әңгәмә вакытында шул хакта да сөйләштек. Ул Мәскәүдә Щепкин исемендәге югары театр училищесын тәмамлап, актер булып эшләргә дип кайткан иде. Актер булып китмәде бит! Нинди шәп драматург булды! «Бәлки, язмыш кулыдыр бу? Бәлки, Туфан чынлап та сәхнәдә уйнарга тиеш булмагандыр?» – дидем мин аңа. Бәлки, ул аны дөрес юлга кертергә теләгәндер? Ирем Фатих та, үзем дә филолог булу турында уйламагансыз. Физматка керергә тиеш булган Фатих юлда аттестатын югалта... Ә мин химия буенча китәргә, аталы-уллы галимнәр – Арбузовларда укырга хыялланган идем... Инде дәүләт имтиханнары да, чыгарылыш кичәләре дә артта. Миңа, «медальгә кандидат» кызга, ни аттестат, ни медаль юк һаман. Мәгариф министрлыгына кадәр җитеп, юллап алганчы, керү имтиханнарына соңардым. Пединститутның татар бүлегенә генә бара алам икән... Шулай язган, күрәсең. Беребез дә начар филологлар булмадык. Фатих Хәсәнов – тәрҗемәче, сүзлекләр төзүче, мин – журналист, язучы, тәрҗемәче...

Бөтен яхшылыкка балачакта өйрәтергә кирәк. Кешене формалаштыру, калыпка салу еллары – чынлыкта балачак бит. **БАЛАЛАР МАТБУГАТЫ ӨЛКӘННӘРНЕКЕНӘ КАРАГАНДА ДА КИРӘГРӘК!** Нишләттеләр безнең балалар газетасын?! Бүгенге балаларның үз газетасы да юк бит хәзер! Шуңа йөрәгем әрни.

КҮҢЕЛЕ, РУХЫ БАЙ ХАТЫН-КЫЗ МАТУР БУЛА. Беренче карашка ул артык гади, күзгә дә бик ташланмый. Ә менә якыннан белсәң, аралаша башласаң, аннан да якты, нурлы, сөйкемле кеше булмый.

«Сөембикә» журналы редакциясендә эшләгән елларымда мин Сөембикә ханбикә темасы белән шөгыльләндем. Аның фаҗигале тормышын «Казан мәликәсе Сөембикә» дигән әсәрендә сурәтләгән төрек драматургы Фатма Музаффер Кайаны эзләп таптым. Музаффер ханымга «Сөембикә» бүләзеген тапшырырга Истанбулга да бардым, үзен дә Казанга чакырдык. Карадуган авылында Бакый Зыятдиновлар гаиләсендә кунак итү аңа аеруча ошады! «Йөргән, гизгән җирләребез язып кына да бетерерлек түгел, – дип тәэсирләнде ул. – Төрки кунакчыллыкның иң матур үрнәген күрдек... «Сөембикә» журналы хезмәткәрләренең җылы мөнәсәбәте һәм ачык күңелле булуларына зур рәхмәт әйтәсе килә. Бу гүзәл кешеләрне беркайчан да онытмам... **ДӨНЬЯ КИЛСЕН ДӘ КЕШЕЛЕКЛЕЛЕККӘ МОНДА ӨЙРӘНСЕН!» –** дип язды Музаффер Кайа.

Мин гомер буе өйдә күпләп газета-журналлар алдырдым. Хәзер дә яздырам, укып барам. Бер нәрсәгә эчем поша. **ФИКЕРЛЕ, ҮЗ ЙӨРӘГЕ АША ҮТКӘРЕП, КЫЮ ИТЕП, КУРЫКМЫЙЧА ЯЗА ТОРГАН ЖУРНАЛИСТЛАР СИРӘК ХӘЗЕР.**

Югары белемле, югары квалификацияле хатын-кыз хәзер бала табуны чикли: бер, күп дигәндә ике бала белән кала. Югыйсә **ЮГАРЫ ИНТЕЛЛЕКТЛЫ ХАТЫН-КЫЗ ЗАТЛЫ БАЛА БЕЛӘН МИЛЛӘТНЕҢ ГЕНОФОНДЫН ЯХШЫРТЫР ИДЕ.** Шундыйларның бала тудырмавы милләтне корытуга китермәсме? Шул ук вакытта бәгъзе бер эчкече ташып кына тора баланы. Менә шундый шартларда сыегаймасмы милләтебезнең асыл сыйфаты?

Тыйнак дигәннән, Мирсәй ага Әмирнең **«ТЫЙНАКЛЫК БЕЛӘН МАКТАНА ТОРГАЧ, МОКЫТКА ӘЙЛӘНЕП БЕТТЕК ИНДЕ»** дигән сүзе искә төште.

Малеевкада Белла Ахмадуллина белән әңгәмә вакытында: «Кече яшьтән үк Сез безнең якка ничектер аркагыз беләнрәк торгансыз сыман тоела» дигән фикер әйткән идем аңа. «Мин гаепле түгел инде аңа. Некоторые оказались длиннорукими, некоторые – косорукими», – диде ул. Тәрҗемәче булсам да, мин бу сүзләрне татарчага әйләндерәсе итмәдем. **ШУНДЫЙ ИНДЕ МЕНӘ БЕЗ – КОСОРУКИЙЛАР, АЧЫК АВЫЗЛАР, ҮЗЕБЕЗНЕҢ КҮП НӘРСӘНЕ КУЛЫБЫЗДАН ЫЧКЫНДЫРАБЫЗ...**

Академик Мансур Хәсәнов Гаяз Исхакый иҗатына багышланган мәкаләсендә шәхесләр белән җәмгыять арасындагы мөнәсәбәт турында ачынып яза. «Татарның ачы тарихы милләтне бик күп нәрсәләргә өйрәтте: тырыш һәм батыр булырга да, мәгърур вә матур булырга да, кирәк икән сабыр һәм түземле, күндәм һәм буйсынучан булырга да!.. Әмма тарих аны тик бер генә нәрсәгә өйрәтә алмады шикелле. Ул да булса – үзенең олы талантлары, тарихи шәхесләренең исән чагында кадерен белергә...»
Ә ШУЛАЙ ДА ТАЛАНТЛАРНЫҢ ЯЗМЫШЫН БЕРЕНЧЕ ЧИРАТТА ЭШ БАШЫНДА ТОРУЧЫЛАР ХӘЛ ИТӘ.

Укучыларга минем Габдрахман Әпсәләмов кебек Кеше, Язучы турында, аның үлем белән көрәшеп язылган роман-повестьлары турында сөйлисем килде. Әмма, ни үкенеч, ниятләремне тормышка ашырып, балаларга тәкъдим итәргә җитешкәләгәнче, Габдрахман абый дөнья куйды. Соңардым... **КЕШЕЛӘРГӘ ЯХШЫЛЫК ЭШЛӘРГӘ АШЫГЫРГА ИДЕ, СОҢАРМАСКА ИДЕ ШУЛ...**

Фикерләр тупланмасын Эльмира ЗАКИРОВА әзерләде.

P. S. Язучы, журналист, тәрҗемәче Саимә апа ИБРАҺИМОВАны 90 яшьлек олуг юбилее белән котлыйбыз! Сәламәтлек, көр күңел, иҗат дәрте телибез!



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз: www.syuyumbike.ru

БАЛАНЫ УСАЛЫККА ӨЙРƏТƏБЕЗ

Данил СƏФƏРОВ



Улыбыз Сабирның бу арада туган көне булып узды. Шул уңайдан хатыным Әдиләгә әйтәм: «Аллага шөкер, 7 яшькә кадәр улыбыз акыллы кеше булып үсте, әйдә, хәзер бераз усаллыкка да өйрәтик инде үзен». Хатыным нәрсә әйтәсе килгәнемне аңлады булса кирәк, күзләрен түгәрәкләп карамады.

Бөтен ата-ана да баласын акыллы булсын дип тәрбияли. Бу табигый. Безне дә шулай үстерделәр. Әти-әниләребезне дә шулай үстергәннәр. Әмма акыллылык еш кына балада комплекслар тудыра, иҗади потенциалны тормышка ашыруга киртә куя. Сизгәнегез бар микән, «өчле»гә укучылар тормышта еш кына бизнесмен, җитәкче, түрә булып китә. Ә «медалист»лар шактый очракта мәктәптә алган «бишле»ләрен тормышта куллану җаен тапмый. Нидән бу? Бәлки, артык акыллы, тәртипле булудандыр? «Өчле»гә укучының «өчле» алу куркынычы юк, шуңа күрә ул яңа эшкә, яңа идеягә, яңа авантюрага тәвәккәлләргә курыкмый. «Отличник» исә бер сызылган эздән бара да бара, альтернатив юллар турында уйлап та карамый, аның өчен иң куркыныч нәрсә – «дүртле» алу! Бу «дүртле» алу куркынычы аны бөтен тормышы буенча сагалый, яңа эшкә тотынуга киртә куя, инициативаны баса, өстенә җаваплылык алмаска этәрә.

30–40 яшьлек дусларым белән бу турыда сөйләшкәнем бар. Күбесен мондый үгет белән үстергәннәр: «кешедән аерылма», «тыйнак бул», «кеше ни әйтер», «безнең йөзгә кызыллык китерәсе булма». Кызыллык китерү шулкадәр куркыныч булгач, иң отышлысы – берни эшләмәү. Алла сакласын йөзгә кызыллык китерүдән! Ата-ананың мондый «шантажы» ничәмә-ничә баланың язмышын хәл иткәндер.

Баланы артык акыллы итү теләге ата-ананың эгоизмыннан да киләдер ул. Бала турында уйлаган булып, алар, беренче чиратта, үзен кайгырта. Акыллы бала – бик уңайлы. Утыр дисәң – утыра, тор дисәң – тора. Бернинди тәвәккәл адым ясамый, күңел тыныч. Ахыр чиктә инфантиль булып үсә. Шуннан аны тирги башлыйлар: «нинди җебегән син», «үзеңне карый белмисең»... 20–30 яшендә өйдә компьютер уйнап утыручы егетләрне еш күрәбез. Аннары әниләре, үз-үзләрен юатып: «Ярый әле эчми», «Ярый әле начар төркемнәргә иярмәде», – дип әйтеп куялар.

Кыскасы, улыбызны усаллыкка өйрәтә башладык бит әле. Нидән тотынырга икән? Беренчедән, шуны истә тотарга кирәк: баланың үз фикере булырга мөмкин һәм аның белән санлашу мәслихәт. «Дәшмә», «монда олылар сөйләшә», «аптыратма»ише сүзләрне онытырга кирәк. Икенчедән, баланың теләкләрен хөрмәт итә белү мөһим. Безнең эшләр «генеральский», ә баланыкы – вак-төяк дип карау дөрес түгел. Өченчедән, баланы басмаска. «Бу синең өчен түгел», «башың яшь», «башта дәресләреңне хәзерлә» дип инициативаны кисәргә ярамый. Савыт ватмый гына баланы савыт юарга өйрәтеп булмый.

Усаллыктан башладым, тәвәккәллеккә килеп чыктым. Минемчә, бу ике төшенчә бала тәрбиясендә янәшә йөри. Максат куяр өчен омтылыш кирәк, ә аңа ирешү өчен – усаллык. Шул ук вакытта баланы бераз гына салкын акыллылыкка, юкка борчылмау сәләтенә, битарафлыкка, хәтта бераз ваемсызлыкка өйрәтергә кирәк. Куйган максатына ирешү өчен ул узып барышлый килеп чыккан проблемаларга («дүртле» алуга, савыт ватылуга) җиңел карый белергә тиеш. Шул очракта бала максатчан булып үсәр, үз проблемаларын үзе хәл итәргә өйрәнер.

Проблеманы мөстәкыйль хәл итә белү – бала өчен иң мөһим сәләтләрнең берседер. Һәм балага бу сәләтне сабый чактан ук сеңдерергә була. Әйтик, бала шкафның өске тартмасыннан киемен ала алмый һәм әти-әнисен ярдәмгә чакырып китерә. Без, ата-аналар, нишлибез? Әлбәттә, йөгереп килеп ярдәм итәбез. Гәрчә әйтергә була иде: «Улым, син аны миннән башка да эшли аласың, уйлап кара әле, ничек алырга була ул киемне?» Бала шундук урындык алып киләчәк. Шушы кечкенә генә хәйлә, баланың киләчәктә мөстәкыйль кеше булып үсүенә бер адым. Тормышта исә төрле хәл күрәбез. Балалар бакчасында ике бала уенчык бүлешә алмаса, әти-әниләр «разборкага» килә. Укытучы апа кырын караса, судка бирергә мөмкиннәр. Шундый заман китте. Ата-ана ягыннан баласын гиперсаклау модада хәзер. Бу эгоизмнан, мин-минлектән килә: «кем әле ул минем балага күрсәтмә бирергә?», «кем әле ул минем балага сүз әйтергә?». Көн кебек ачык, йомырка сарысы кебек үскән бу балаларга киләчәктә җәмгыятьтә үз урынын табарга җиңел булмаячак.

Хәзер бөтен нәрсәгә китап өйрәтә. Баланы да китап буенча тәрбиялиләр. Бала тәрбияләү серләре буенча меңнәрчә, бәлки, миллионнарча китап бардыр. Ни кызык, андагы тәрбия ысуллары еш кына бер-берсенә каршы да килә. Кайсы юл дөресрәк? Баланы ничек тәрбияләргә? Бирегез бер сценарий яки план. Юк шул аның төгәл планы. Иң мөһиме: бала тәрбияләү турындагы китапларга кереп китеп, бала үсеп җиткәнен сизми калмыйк.

P. S. Аллага шөкер, ике бала атасы.

PRESSA.RU



Нәҗип Нәккаш эше



Лилия
ГӘРӘЕВА

БАБАҢ КЕМ ДӘ, ЗАТЫҢ НИ?

Әллә замана модасы, әллә тарихи үзаңыбызның уянуы – нәсел чылбырындагы югалган буыннарны барлау теләге көчле хәзер. Борынгы мирасның кыйммәтен аңлый барабыз, димәк. Тарих пәрдәсенең читен күтәреп, чорлар аша ерак бабаларны ничек эзләп табарга соң? Нинди тарихи чыганакларга таянырга?

Шәхсән мине гаилә тарихларын нинди документларга нигезләнеп төзиләр дигән сорау күптәннән кызыксындыра иде. Ниһаять, архивка кереп, ул кулъязмалар белән үземә танышу насыйп булды.

Нәселне ачыклау, ата-бабаны, туганлык җепләрен табу эше төп ике чыганакка нигезләнеп алып барыла. «Ревизия язмалары» («Ревизские сказки») һәм «Метрика кенәгәләре» («Метрические книги») дип атала бу кулъязма документлар. Аннан башка губернатор канцеляриясе, волость идарәсе документлары, «похозяйственные книги», XVIII гасырда Екатерина патшабикәнең генераль межалау кампаниясе вакытында төзелгән җир планнары бар. Авыл җыеннары документлары да бик күпне сөйли ала.

«Ревизия язмалары» – XVIII гасыр – XIX гасырның беренче яртысында Россиядә уздырылган җан исәбен алу нәтиҗәләре ул. 1720–1858 ел аралыгында барлыгы ун кампания уза. Казан губернасы буенча 1834, 1850, 1858 елгы җанисәп нәтиҗәләре (8, 9, 10 ревизияләр) тулысы белән диярлек сакланган. Кайбер авыллар буенча 1735–1765 елга караган документларны да табарга була. Россиядә узган бу эшнең максаты – җан башыннан салым түләтү булган, әлбәттә. Гаиләдәге ир-ат җенесе вәкилләре санныннан чыгып салынган ул салым. Шуңа да 1, 2, 6 ревизияләрдә хатын-кызларны җан исәбенә кертмәгәннәр. Калганнарында гаилә составы тулысы белән күрсәтелгән.

Мөселманнарның метрика кенәгәләре исә 1828–1829 елдан төзелә башлый. Бу эшне инде мөфтият кушуы белән, муллалар үзләре башкара. Бер авылда әллә ничә мәхәллә булуын искә алсак, авылдагы метрикалар да мәхәллә саен тутырылган. Дөреслектә, алар ике нөсхәдә язылырга тиеш булган. Бер нөсхәсе Уфадагы мөфтияткә тапшырылган. Шуңа да хәзерге Татарстан территориясенә кергән күпчелек авылларның 1865 елга кадәргє борынгы метрика кенәгәләре әле бүген дә Уфада саклана. Мөселман метрикалары дүрт өлештән тора: туучылар, үлүчеләр, никахлар, талаклар. Бөгелмә, Әлмәт, Тукай, Актаныш, Зәй ягы авылларына караган документлар азрак. Ә менә Вятка губернасына караган (Алабуга, Менделеевск, Әгерҗе яклары) метрикаларның хәле аяныч. Сәбәпләре, билгеле, күптөрле: су басулар, янгыннар... Кызганыч, андагы мәгълүматларны хәзер берничек тә табып булмый.


Илдар ШӘФИКОВ, Татарстан дәүләт архивының фәнни эшчәнлек һәм публикацияләр буенча директор урынбасары

– Хәзер күпләр үзләренең нәсел тамырлары белән кызыксына. Бер атнага гына да якынча 130 сорау керә безгә. Кемдер берәр туганы хакында гына сорый, кемгәдер тулы бер шәҗәрә төзеп бирергә кирәк. Бөтен кешегә дә тиз кирәк, уңай җавап кирәк... Әмма бу тиз генә башкара торган эш түгел. Бер позицияне (бер кеше хакында бер мәгълүмат табу бер позиция дип атала – *авт.*) табу өчен дә бер хезмәткәр берничә көн вакытын сарыф итәргә мөмкин. Ә тулы шәҗәрәне төзү өчен еллар таләп ителә. Халык архивта нинди мәгълүматлар барын, безнең ничек эш итүебезне начар күзаллый. Алфавит буенча төзелгән әзер картотека сыманрактыр дип уйлый алар архивтагы документларны. Әмма әлегә андый картотека да, журналдан гына карап әйтә торган әзер исемлекләр дә юк. Архив мәгълүматларын эзләтү – түләүле хезмәт. Беренчедән, әйткәнемчә, күп көч сорый, икенчедән, без хәзерге Татарстан Республикасы территориясенә кергән авылларга караган документларның күчермәләрен башка регионнардан сатып алабыз.

Узган ел Мари Республикасы вәкилләре килгән иде. «Бездә гарәпчә язылган метрикалар ята, укый алмыйбыз», – диләр. Менә шул рәвешле, әле бүгенге көндә дә яңа табылдыклар булып тора. Хезмәткәрләребез, Самара һәм Уфага барып, бүгенге Татарстан Республикасы территориясенә кергән авылларга караган документларның исемлек копияләрен алып кайттылар. Мәскәүдән өченче ревизия документларының күчермәләрен алдырдык. Архивларда үзәкләштерү дигән нәрсә әлегә юк, без моңа барабыз гына әле.

Хәзер архив бик зур эшкә алынды – борынгы документларны электрон форматка күчерү эше бара. Тугыз йөздән артык «Ревизия язмалары»ның алты йөзгә якыны инде электрон базага кертелгән.


Рәйлә ГАТАУЛЛИНА, Татарстан дәүләт архивының Генеалогик характердагы мөрәҗәгатьләрне карау бүлеге җитәкчесе

– Безгә ике төрле мәсьәлә белән мөрәҗәгать итәләр. Аның беренчесе, һәм ул иң күбе дә, гражданлык хәлләре турында сораулар була. Гадәттә, туганлыкны исбатлау, гражданлык алу, мираска хокукы барлыгын раслау өчен кирәк булып чыга ул мәгълүматлар. Соңгы елларда, бабаларының иске кабер ташларын яңартасылары килеп, даталар, исемнәр төгәл булсын иде дип тә мөрәҗәгать итүчеләр бар. Шуннан кызыксынып китеп, бабаларының бабаларын ачыклыйсылары килә. Бер мәгълүмат табылса, шуннан икенчесенә юл ачыла, өченчесенә...

Шәҗәрә төзү, генеалогик тикшеренү уздыру мәсьәләсенә килгәндә, без нәсел тарихын өч төрле тулылыкта тикшерүне тәкъдим итәбез: үзебезнең архив документларына нигезләнеп, «төшә баручы» генеалогик тикшерү; шундый эзләнүләрне буыннарның билгеле бер чорда яшәгән бөтен туганнарын да кертеп һәм башка регионнар, федераль архив документларын да кулланып төзү. Мондый тикшеренүләрнең нәтиҗәсе булып, тарихи мәгълүматлар (авыл тарихын, төрле социаль төркемнәр турында белешмәләр) тупланган альбом төзелә.


Заһир ШӘЙХЕЛИСЛАМОВ, Татарстан дәүләт архивының Генеалогик характердагы мөрәҗәгатьләрне карау бүлегенең баш архивисты

– Кайда да кеше факторы дигән нәрсә бар. Борынгы кулъязмалар белән дә шулай. Кайсыдыр мулла баланың туган көнен, кайчан исем кушылуын, кайсы мулла кушканлыгына кадәр җиренә җиткереп язып куйган. Кайберләре әтисенең исеме урынына – улыныкын, улы урынына әтисенекен бутап язган. Ә болай 1917 елга кадәрге метрикалар яхшы тутырылган үзе. Менә 1918–1921 еллар арасында туганнарны ачыклавы кыен. Илдә гражданнар сугышы бара, документлар юньләп теркәлмәгән, кайдадыр бу эш бөтенләй дә тукталган.

Совет чорында тутырылган документларга бер нәрсә хас: ул вакытта кайберәүләр үзләренең озын исемнәрен кыскартып яздыра башлаган. Исемнәрен үзгәртүчеләр дә булган. Мәсәлән, бездән Зоя исемле кешене эзләтәләр. Баксаң, ул Миңҗамал исемле булган. Аның исеме үзгәрү турында аерым бер биткә язып, мөһер сугып, метрикага кыстырып куйганнар. Туганнарының хәзер бу факт белән килешәселәре килми. Барлык документларда да ул Зоя дип бара бит. Әмма без ялган мәгълүмат бирә алмыйбыз. Мондый очракларда кешеләрнең үзара туганлыгын суд аша гына раслап була.

Сораулар буенча эш ничек бара соң, дигәнгә килсәк, иң элек күрсәтелгән елны карыйбыз. Табылмаса, өч ел аска, өч ел өскә менеп, шул авылга караган документларны тикшерәбез. Таба алмасак, мәгълүматлар табылмады, дип, белешмә бирәбез. Тик уңай нәтиҗә бирәсе килә, шуңа күп очракта эзләнүче кешеләрнең туган елларын, авылларын кабат ачыклауны сорыйбыз.

Шәҗәрәләр төзегәндә һәр елныкын (әгәр сакланган булса) тикшерәсең. Метрика кенәгәләре булмаса, «Ревизия язмалары»ннан карыйбыз. «Ревизия язмалары»нда да хаталар күп. Алар бит русча төзелгән. Билгеле инде,

PRESSA.RU

татар исемнәре, фамилияләре кайчак адәм аңламаслык итеп бозып язылган. Хупҗамаллар – Хупзамяллар, Зөлхиҗҗәләр Зулхиззаларга әверелеп беткән. «Сөембикә» укучылары бу хакта хәбәрдар микән, без Габдулла Тукайның әнисен Бибимәмдүдә дип беләбез. Ә метрика кенәгәсендә ул Минсафа булып язылган. Элегрәк татарларда бала авыру туса яки аннан соң чирләп китсә, исемен алыштыру гадәте яшәгән. Минсафа да, күрәсең, шул сәбәпле Бибимәмдүдәгә әверелгән.



Рамил ГАПТРАХИМОВ, Татарстан дәүләт архивының Генеалогик характердагы мөрәҗәгатьләрне карау бүлегенең баш архивисты

– Кайвакыт шулай да була, кеше бер генә туганы турында мәгълүмат сорый, аны эзләгәндә, параллель рәвештә әллә ничаклы өстәмә мәгълүмат ачыклана. Хәтта үзең дә кызыксынып китәсең. Гадәттә, эзләү бу рәвешле бара: иң соңгы датадан карап төшәсең. Ничәдер ел саен бу кешенең балалары туганлыгы теркәлеп барган. Аннары балалар бетә. Бер-ике елдан никах теркәве килеп чыга. Никах чыкса, бик яхшы: анда ничә яшьтә булулары, аталарының исемнәре язылган була. Никахны тапмасак (димәк, никах башка авылда теркәлгән), унсигез елны санап алып, шуннан соңгы елларны карыйбыз. Анда инде бу кешенең туу турындагы мәгълүматлар килеп чыгарга мөмкин.



Рүзәл ФӘЙЗРАХМАНОВ, Татарстан дәүләт архивының Генеалогик характердагы мөрәҗәгатьләрне карау бүлегенең баш архивисты

– Нинди дә булса мәгълүматны табу өчен өч фактны белү мөһим: эзли торган кешенең исеме һәм атасының исеме, кайда туганы, ничәнче елларда яшәгәнлеге. Һичьюгы чама белән. Әмма күпләр ул мәгълүматны белми. Бу очракта кешене эзләп табу мөмкин түгел.

Борынгы метрика язуларының тагын бер үзенчәлеге: никахлар кыз ягында теркәлгән. Кызның туган көне, елы, ата-анасының исемнәре шул авылда теркәлгән документта була. Әниләрен, әбиләрен эзләтүчеләрнең күбесе аның кайсы авыл кызы булуын белми, шуңа да табуы бик кыен, хәтта мөмкин дә түгел.

Казан буенча, гомумән, сораулар күп. Элек башкалада 18 мәхәллә эшләгән. Казанга караган метрикалар да күп. Бабайлары Казанда яшәгәч, оныклары әти-әнисен Казаннан дип уйлый, Казаннан эзләгез, диләр. Әмма күп очракта ул сорауга дәлил табылмый. Казаннныкы дип саналса да, димәк, башка җирдә туган. Метрика кенәгәсенә дә үзенең туган авылында теркәлгән булган.

Тулы исемнәрне белмәү дә кыенлык тудыра. Мәсәлән, берәү Фатыйма Газизовнаны эзли. Ә ул исә Бибифатыйма Габделгазизҗан кызы булып чыга.



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз: www.syuyumbike.ru

ШӘҖӘРӘ ТӨЗҮЧЕЛӘРГӘ КИҢӘШЛӘР

■ Беренче эш итеп, әлбәттә, гарәп имлясын өйрәнергә кирәк. Гарәп язулы басма китаплар белән кулъязмадагы гарәп имлясын танып уку – икесе ике нәрсә.

■ Барлык туганнарны, авылдашларны сораштырып, мөмкин кадәр мәгълүмат тупларга тырышыгыз. Борынгы документлар сакланмаганмы икән, аларны барлагыз. Кешене туган елы һәм исеме буенча гына табып булмый: туган авылын да белергә кирәк.

■ Бу эшнең озакка сузылачагына күңелегез белән әзер булыгыз.

■ Тарихи кыйммәте югары булган документларның оригиналларын, шул исәптән метрика кенәгәләрен дә кулга бирү чикләнгән булуын да истән чыгармагыз.

■ Сезне кызыксындырган мәгълүматларның электрон копияләре булырга мөмкин. Татарстан Республикасының бердәм архив мәгълүматлары системасында (ЕАИС РТ) фонд описьләренең һәм кайбер архив документларының, шул исәптән өлешчә метрика кенәгәләренең дә электрон копияләре теркәлгән.

■ Метрика кенәгәләренең электрон нөсхәләре белән Татарстан дәүләт архивының уку залларында танышырга була. Документларны электрон форматка күчерү эше әлегә тәгалләнмәгән, шуңа да барлык мәгълүматлар да булмаска мөмкин.

■ Сезне кызыксындырган документларның электрон нөсхәсе булмаса, уку залына алдан заказ бирергә кирәк. Документларны махсус сканердан чыгарып, базага кертү бер-ике ай чамасы вакытны ала.

■ 1922 елдан соңгы гражданлык хәлләре хакындагы мәгълүматларны табу өчен архивка түгел, ЗАГСка мөрәҗәгать итәсе. Казан шәһәренә караган архив документлары – Меридиан урамы, 4 нче йортта, республика районнары буенча Әхтәмов урамындагы 14 нче йортта – Татарстан Министрлар Кабинеты каршындагы ЗАГС Идарәсендә тупланган.

■ Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының «Мирасханә» архивында да шактый бай мәгълүмат тупланган.

■ Каюм Насыйри да шактый шәҗәрәләр туплап калдырган. Аның авыллар тарихына караган хезмәтләре дә бар. Болар Казан университетының Лобачевский исемендәге китапханәсендә саклана.

■ Мөселманнарның метрика кенәгәләренең күбесе Уфадагы архивта тупланган. Самарада да бүгенге Татарстан территориясенә кергән кайбер авылларның метрикалары бар.

ТАЛАК... ТАЛАК... ТАЛАК...



Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН, «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы

Иланһи ният кылдым

Соңгы вакытта «никах яңарту» дигән сүз ишетелә башлады. Нәрсәне аңлата ул?

– Иң элек нәрсә соң ул никах дигән сорауга җавап бирик. Никах – ул килешү. Ир-ат белән хатын-кыз берсе – ир, икенчесе хатын булырга килешәләр. Никах ул гыйбадәт түгел, күбрәк сату-алу, алдым-бирдем кебек килешү.

Килешү ничек бозылырга мөмкин? Үзеннән-үзе ул ике очракта гына бозыла: ике якның берсе вафат булса яки ике якның берсе ислам диненнән чыкса. Мәсәлән, ир (яки хатын) христиан диненә күчә икән, ике арадагы никах бетә. Кайчакта ислам дине кабул иткән булып, яшьләр никах укыталар, аннан, яши башлагач, ире (яки хатыны) кире үз диненә кайта – бу очракта да никах юкка чыга. Хаталарын аңлап, дингә әйләнеп кайткан очракта, бу парга яңадан никах укыла. Бу – никах яңарту, дөресрәге, яңадан уку була.

Килешү тагын ике якның теләге белән бозылырга мөмкин. Мәсәлән, ир кеше хатын-кыздан канәгать түгел: ул аны аерып җибәрә. Моның өчен «талак» дигән сүз әйтү җитә. Әгәр бу сүзне рәттән өч тапкыр әйтсә, ир хатынынnan мәңгегә аерыла. Моны катгый талак, диләр. Ашыктым, ялгыштым, дип, хатынына кабат өйләнергә теләсә, җәмәгате иң элек башка кешегә кияүгә чыгарга, аның белән җенси якынлыкка керергә, аннан яңа ире хатынны аерырга тиеш. Шул чакта гына беренче ире аны кабат үзенеке итә ала.

Әгәр дә «талак» бер яки ике тапкыр әйтелсә, хатыны вакытлыча гына аерыла: бу очракта ул башка кешегә дә кияүгә чыга ала яки ире гафу үтенсә, «онытыйк» дисә, кире аңа да кайтырга мөмкин – яңадан никах укыталар да, бергә булалар.

«Талак»ны башка сүзләр дә алыштырырга мөмкин. Мәсәлән, «бүгенге көннән син минем хатыным түгел» дию дә «талак» сүзенә тиң. Хатын-кыз кайчак: «Китәм дә барам, синнән яхшыракны таба алмаммы әллә?!» – ди. Ире шул вакыт: «Бар, бар, дүрт ягың кыйбла», – ди икән, бу инде «талак» дигән сүз. Өч ай эчендә ул әле хатыны белән яңадан кавыша, аны никахсыз да үзенә кайтара ала. (Кайтаруга гафу үтенү, сөйләшү, үбешү-кочаклашу, якынлык кылу керә – сез инде кабат бергә дигән сүз.) Өч ай узганнан соң гына аралар җылынса, бу очракта инде никах укытырга – никах яңартырга кирәк.

Никахны кемнәр, ни өчен яңарта соң? Кайвакыт кешеләр ачуланышканда, югарыда китерелгән шушы сүзләрне әйтеп куялар. Хатын, чыгып китеп, бер-ике ай әти-әнисендә торып ала. Шуннан соң бу пар яңадан кушыла. Һәм, «безнең никах инде беткәндер», дип, яңадан никах укыта. Ә болай матур гына яшәгән җирдән никах яңарту кирәкми. Ул матурлык, хисләрне яңарту, яшь чакларны искә төшерү өчен ярый. Шәригать ягыннан аның мәгънәсе юк, ул бернәрсә бирми, өстәми. Кайберәүләр: «Әй, без яшь чакта дөрес укылмагандыр инде ул», – ди. Шаһитлар да булмады, мәһәр дә бирелмәде, әти-әни аны безсез генә укытты, без белмичә дә калдык, диләр. Совет чорында кавышканнар шулай яңартып алса да була: чыннан да, аларның никахы дөрестерме, юктырмы – кем белә?!

Хыянәт булган очракта, никахны яңарту мәҗбүриме?

– Әгәр андый хәл булган икән, моны онытырга тырышырга кирәк. Бер-береңне гафу итә алсаң, әлбәттә... Дин юлында булмаган ир-атларның күбесе яшь чакта читкә күз ата, йөри инде ул. Табигатьләре шундый аларның. Ирләренең йөргәнен хатыннары күп вакыт белми дә кала. Мәчеткә намазга килгән егетләр арасында: «Хатыныма хыянәт иткәнем булды. Намусым борчый – сөйләргәме икән аңа бу хакта?» – диючеләр бар. «Булган – беткән, тәүбә итәргә дә онытырга һәм моңа кире әйләнеп кайтмаска кирәк», – дим. Сизмичә калган икән, хатынга аны хәзер белгертмәсәң хәерлерәк. Белсә, әйткәнемчә, гаилә таркалуы бар: синең инде тәүбә итүеңне, бүтән бу адымга бармавыңны хатын-кыз аңлап бетермәскә мөмкин.

Инде хыянәт аркасында никах яңарту турында. Хыянәт никахны таркатмый, аңа карап никах бетми. (Никах шул чагында юкка чыгарга мөмкин, әгәр ир (яки хатын) бу гаебен казый каршында таныса, һәм ул аларны аерса). Хыянәттән соң кешегә рухи яктан зыян килә, үзенә, хисләренә. Күңелдә туган шушы авырлыктан котылу өчен кайберәүләр никах укытып, аны яңартып алалар. Бу очракта аның мәгънәсе бар. Әмма иң мөһиме: тәүбә итәргә кирәк, тәүбә итсәң, Аллаһы Тәгалә гафу итә ул.

Ир-атның озак вакыт командировкага китеп эшләүләре гадәти күренеш хәзер. Кемдер ике-өч айга китә, кемдер ярты елга... Озакка аерылып тору никахны бозмыймы?

– Хатын-кыз казыйга барып: «Ирем югалды, мине тәэмин итми, башка болай яши алмыйм», – дип әйтмәсә, озак күрешмичә торудан никах бозылмый. Хәтта аерым торуларына бик озак, әйтик, егерме еллап вакыт узса да.

Ире белән үпкәләшкәннән соң: «Мин сине аермыйм, син минем хатыным», – дип торса, кумаса да, хатын төенчекләрен җыеп, әти-әнисе янына кайтып киткән очраклар бар. Мондый чакта да никах бозылмый: алар кабат кавышсалар, аны яңарту кирәкми. Бездә, гадәттә, шулай була: хатын, «аерылам» дип, иреннән китә (дин буенча исә бу сүзне бары тик ир-ат кына әйтә ала!), бераз вакыт узгач, бу хатын икенче кешегә кияүгә чыгарга җыена. Чыга да. Чынлыкта, ислам дине буенча, ул әле һаман беренче иренең хатыны булып санала. Кабат кияүгә чыкканда укылган никахы шуңа күрә дөрес булмый.

PRESSA.RU

ЯРАТУ УЛ ЯЗДАН ГЫНА ТОРА

Луиза ЯНСУАР

* * *

Бу язга бер үпкәм юк минем –
Елмая көннән-көн яктырак.
Сабырым сынганда...
Еласам...
Тик тора мөлдерәп... аптырап...

Ул бары яз гына. Нарасый.
Ул белми язларның бүтәнен:
Мин ничек таңнарда уянып,
Сагынып, күзләрең үпкәнем.

Һәм ничек сагыштан... үлгәнем,
Синнән соң яшәгән дәвердә.
Бу язга бер үпкәм юк минем.
Ул миннән,
Мин аннан –
Бәхилләр.

* * *

Грустные люди мы друг без друга...
Диана Арбенина

Сине сагынып чыгам юлларга,
Сине сагынып керәмен кайтып.
Һәм чынаякка хуш исле җәйме
Ага челтерәп? Әллә соң вакыт?

Онытып тәмам барлыгын җирдә
Эш сәгатьләре, кеше сүзенең
Мин табам, кайтып, синдә үзеңнән,
Хәтта үземнән үзрәк үзеңне.

Моңсу бу җирнең моңсу икәве –
Хәзер дә шул без. Тик ул моңсулык,
Икегә бүлгәч, яктыра төшә...
Шуңа кайтасың син дә – юксынып.

Ашыкмый гына. Кадерең тоеп.
Җилли чәчләрең. Күзләрең көлә.
Бүген. Шушында. Бар без.
Калганын...
Икебезгә бер –
УЛ гына белә.

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА

* * *

Югарыга, дисең, югарыга!
Югарыда, дисең, җилләр өне...
Юлларымда җирсү моңнар улый,
Югалырга килгән бердәнберем.

Бердәнберем... Бер китәсе иде
Башым куеп уйчан дулкыннарга.
...Вулканнарда яшим тыныч кына
Югарыда әле җилләр барга.

* * *

Син! Күкләргә кайтыр көннәремдә –
Бары синең сулыш, синең тын.
Менә тагын тының белән тартып,
Кирмәннәрне җилгә тараттың.

Ничәнче кат мин орышсыз гына,
Синең карашыңа буйсынам.
Кем син – дошманыммы,
аркадашмы?
Бер тартынам, берчә ымсынам

Синең биләмәңә. Тының белән
Тартып китерәсең җанымны.
Эзлим синнән синле чакларымны,
Эзлим сиңа игез чагымны...

Яңгырдан соң

Үтеп барыш.
Чагыламмы яңгырдан соң
калган тамчы эзләрендә?
Күзләреңдә?

Иркәлиме, өзгәлиме
үзәгемне җирге җилләр?
Читегемә сарыламы
изге җирләр?

Камчылыймы, кочаклыймы
ят дулкыннар иңнәремне?
Яннан үтеп баручыга
тиңнәр безме?

Безме якты дип атадык
ак та кара дөнья йөзен?
Иртәгә дип, суза килдек
сәгатьләрне, соңгы сүзне...

Һәм шулардан китеп барыш.
Кая? Нигә? Ни хакына?
Аякларым арыганда,
ник очрамый бер атлы да?

Күләгәмә кырын карап,
үтеп бара кара болыт.
Китү авыр. Үтү авыр.
Ах, кычәргә болыт булып!

Ах, туктарга һәм багарга
сагыш тулы күзләреңә!

Үтеп барыш.
Чагыламы яңгыр төсе
эзләремдә?

Эльвира ҺАДИЕВА

* * *

Синеңчәрәк – чакырмыйча –
керде бер төн.
Һәм дәшмәде...
Келәмнәргә сеңгән
кыргый шәүләң – күрде –
Көнләшмәде.
Синең исне саклар гөлләр арасында
Адашмады.
Толымнарым – син үргәннән,
сүткән идем –
Тарашмады.

Керфегемдә яшең калган –
мин белмәдем,
Сизелмәгән...
Ишетелде тик чың
һәм таң белән керде
Яз бүлмәгә...

Ул чакларда – беренче яз,
онтылырлык,

Тоям тәмен...
Хәзер беләм инде чыңлап...
Горур төннең
Өзелгәнен.

Һәм кызганмыйм,
үкенмим дә төннәр кебек,
Җанны ярып...
Бөек горурлыктан
нәни генә сөю хәтта
Мең югары!

Гөлназ ГАЗИЗОВА

* * *

Кышның кыйпылчыгы,
Адашыпмы,
Кызыл таҗлар сыйпый буранда.
Алдануын кичермәгән – җете,
Басып тора өмет сагында...
...Язгы кардан эзләр салып барыш.
Бер-берендә дөнья гизеп йөреш...
Әмма, белмим, нинди көтә сәяхәт.
Мине бу үтәли салкын яздан
Алып калган җылың өчен
Рәхмәт!

* * *

Син киткән тарафтан җил исми.
Су акмый. Таң атмый.
Һичьюгы,
юлыннан тайпылган мосафир,
Бер йотым су сорап,
Бусагам аркылы атламый.
Тып-тынлык.
Ә миңа бары бер сүз җитә.
Сәламең булмасын,
Булмасын ул – миңа әйтелгән.
Бары сүз. Бары ым.
Бары бер ачыклык –
Йокысыз төннәргә тезелгән.
Мин үзем сине бер сулышлык
арага китердем.
Җылыга тартылды күңелем.
Чигәне ватардай
акылым сулкылдый
Мин – сиңа, син миңа түгелен.
Ирек бир... Бер сулыш алырга,
Син киткән тарафтан
тик хәбәр бирсеннәр.
Килсеннәр дә, карап күземә:
«Сагынмый!» – дисеннәр.

* * *

Мин кайчан да булса кайтырмын бер
Син теләгән дөнья чигенә.
Кайтыр юллар бары сиңа илтер,
Илтер синең капкаң төбенә.
...Һәм гап-гади тормыш булыр анда,
Җан сызлатмый торган өметләр.
Көтәр кешең барга – ашыгулар,
Бәхет саный, диеп, сәгатьләр.
Мин дә башка анда, син дә башка,
Мизгел кадерен белгән тик икәү.
Беркайчан да ваз кичмәслек
булдык, –
Дөнья ничәү дә соң, без ничәү...
Ә мин кабат үз-үземә кайтам,
Юрганымны каплыйм башымнан.
Кыя таудан ташланырдай булам,
Син булдырган упкын ярыннан.

Тик язмышның чиге башка ярда –
Мәхәббәткә гашыйк мизгелдә...
Без бер хиskә өлкәнәйдек бугай –
Бәхет дөнья куйган ул төндә.

* * *

Кышның кыйпылчыгы,
Адашыпмы,
Кызыл таҗлар сыйпый буранда.
Алдануын кичермәгән – җете,
Басып тора өмет сагында...
...Язгы кардан эзләр салып барыш.
Бер-берендә дөнья гизеп йөреш...
Әмма, белмим, нинди көтә сәяхәт.
Мине бу үтәли салкын яздан
Алып калган җылың өчен
Рәхмәт!

Гөлүсә БАТТАЛОВА

* * *

Гашыйк булдым. Сиңа.
Февраль шаһит.
Ничәнче кат акыл җиңелде.
Җанны кисәтүдән ни мәгънә соң,
Җыеп йөр дип, итәк-җиңеңне?!

Күз ачкысыз буран иде юкса,
Мәхәббәтне кайчан, кем көткән?
Күңелемдә калган эзләреңне
Көртләр күмгән иде бик күптән.

Гашыйк булдым. Сиңа.
Мең мәртәбә.
Мең тапкырлар сыздым йөрәктән.
Хәтер җуйган минут, сәгатьләрне
Үткәрәсе иде иләктән.

Сиздермәсен җилләр хисләремне
Өермәләп карлар очканда.
Гашыйк бул да миңа, тилмер әле,
Ялгызлыгың килеп кочканда.

Гаепмени?

Яратам! дип кычкырасы килә!
Тик оялам. Беләм – килешми –
Утызымнан чыгып, кырыгыма
Кызу-кызу кайтып килешли...
Сабыр! Сабыр... диеп, тыя-тыя
Чалулады инде чаптарлар...
Бәгырь куенында тилмерешкән
Утсыз калган күпме чакма бар!
Килешми, дип әйтелмәгән сүзләр,
Яшерелгән ымнар, карашлар...
Гаепмени – җирдә берәү булса,
Соңгы сулышыңны багышлар?!
Дөньялыкта үксез җан авазын
Килешми, дип куйдым тышаулап...
Кайтавыздан иңрәп, җир тетрәр күк,
Мин яратам... дисәм, пышылдап...

Эльмира ҖӘЛИЛОВА

Ярату ул яздан гына тора

«Гомереңнең җылы җәе», – дисең,
«Минем җаным тулы көзге моңнар!»
Көзләр, дисең,
Көзләргә ни булган?!
Көзләрнең дә матур көннәре бар!

«Җәйләреңне көзгә алыштырма,
Ашыкмале, – дисең, – бераз уйла!»
«Син – җәйләрдә!» – дисең,
Синсез булгач,
Җәйләрдә дә елак көннәр була.

Көзләрне – җәй,
Җәйләрне яз итү
Бары үзебездән генә тора!
Мин – җәйләрдә,
Син – көзләрдә икән –
Мәхәббәтнең үз язлары була!
Ярату ул яздан гына тора!!!

* * *

Йолдызлардан келәм чигәм.
Күккә күз сал,
Юл табалмый өзгәләнсәң әгәр.
Аз да, күп тә түгел. Безнең ара –
Яратудан яратуга кадәр!..

Зәңгәр күлдәй күзләремә чумган
Йолдыз нуры. Шуны эзләвеңме?!
Эзләмәдем, димә! Мин таныдым
Ай битендә калган эзләреңне!

Сине көтәм. Күңел капкаларын
Биклә түгел, юктыр япканым да!
Яратудан яратуга кадәр келәм –
Өмет җебе энәм сапларында!..

PRESSA.RU



Гөлүсә
ЗАКИРОВА

ЮЛДАШЛАР

(Хикәя)


«Кеше ниндидер бер тетрәнү кичермичә генә үсешнең яңа баскычына күтәрелә алмый». Камалиянең бу юлларны психология дәреслегеннән мең кат укыганы бар. Ышанмый иде. Сүзләргә түгел, кешеләргә ышанырга кирәк. Дөнья гаделләр, матурлар, саф күңеллеләр кулында!

...Тимер-томыр шавына колак тонмалы! Кыз, ирексездән, йөзен пәлтә якаларына яшерде. Юеш яка җылытмый. Салкынлыгы битне куыра хәтта. Йә, нишли инде ул кешеләр берсен-берсе күрми торган бу вокзалда? Нигә аны берәү дә юатмый? Һичьюгы бер чынаяк кайнар чәй тәкъдим итми? Иртәдән бирле тамагына ризык валчыгы да кергәне юк. Камалия еларга тотынды. Еламаслыкмыни? Чит-ят Мәскәү вокзалында мескен булып басып тора. Билеты да, акчасы да юк. Ярый әле кайтыр юлы билгеле. Әнә теге «Мәскәү–Казан» дигән язулы поездга гына утырасы да... Бәлки берәр мәрхәмәтлесе табылыр? Аны – җиде юл чатында ялгыз басып калган кызны вагонның тамбурына гына булса да утыртыр? Беренче вагон, икенче... Юк, икенчегә утырмый. Икенче вагонга утырып килде ул башкалага. Бу сан аңа килешмәде. Югыйсә, кичә киңәшмәдән соң, билетны вокзалга барып үзе сайлап алган иде.

– Искәндәрова, федераль казначылык үткәрдеме безнең документларны? – дип сорады аннан директоры. Ул чакта бар да гадәттәгечә иде. Дүшәмбе. Киңәшмә. Әнә директорның ике урынбасары, кичә генә институт бетереп, бу оешмага бухгалтер булып эшкә урнашкан кызны астыртын гына күзәтә. Җавап биреп кара, янәмәсе.

– Узган атнада элемтәгә кергән идем, оригинал документларны сорадылар. Командировкага барып кайтмый булмас, Әсхәт Фәтхерахманович, – диде башлыкка Камалия. Бу сүзләрдән директорның йөзе май кояшы кебек балкып куйды.

– Озакка сузасы түгел. Бүген үк җыен юлга. Как раз мине дә чакыралар Мәскәүгә. Кунакханә ягын үзем кайгыртырмын.



Рәсем: Наталья Васильева

Урынбасарларның берсе, башкаларга да сизелерлек итеп, хихылдап алды. Камалия генә берни аңламады. Башкала кунакханәсендә директорның икесенә бер номер алганын күргәч кенә күзләре шарланды. Ничек диде әле?

– Башка бүлмәләр юк, асылым. Әйдә, кунагым бул. Нигә күзләреңне шарландырып карап торасың. Белмәдем, дип кенә ачуымны чыгара күрмә. Кәефне бозма. Хәер, бу килеш тә минем сине тотып ашарлык дәртем уйнап тора. Күлмәгеңне, сәдәфләрен чишеп тә тормый, йолкып төшерәм хәзер. Ай, асыл кошым, кил кочагыма, кил. Мәскәү турында ничек шәп уйлап таптың, ә? Алайса, Казанда күзләр җитәрлек. Йә хатынга җиткерерләр. Ашап бетерәм үзеңне бүген.

– Кагылмагыз!!! Кагыласы булмагыз! – Камалиянең бөтен кимсенүе, ачуы, нәфрәте шушы сүзләргә сыеп бетте. Аннары шомлы, караңгы Мәскәү кочагына ташланды ул.

– Әтрәк-әләм! Асмановка берәүнең дә кычкырырга җөрьәт иткәне юк. Синең дә чабуыңны кыскартырмын! Искәндәрова, ты уволена!!! – Җитәкченең ачуы кинәт каһкаһә белән көлүгә күчте – бүлмәдә кызның сумкасы онытылып калган иде. – Кайтырсың, тутый кош, Мәскәү кадәр Мәскәүдә акчасыз, билетсыз әллә ни ерак китә алмассың...

Кунакханә каршындагы парк эскәмиясенә утырып күңел савытын бушаткач, салкын карга калын эзләр сала-сала, туп-туры вокзалга китте Камалия. Бүген үк кайтып китәргә! Билетны алмаштырырга да бу пычраклыктан арынырга! Тик хәсрәтләре әле башлана гына иде, ахрысы. Үзе белән сумкасын алмаганын билет кассасы каршында гына төшенгән кызны чираттан төртеп чыгардылар. Кара, әле генә ачудан ут булып яна иде. И әни, тормышның мәхәббәттән генә түгел, көрәштән дә торганын нигә аңлатмадың беркатлы кызыңа...

– Гражданочка, ни булды? – Тимер урындыкны кочаклап елап утырган Камалия, форма кигән кешене күргәч, айнып киткәндәй булды.

– Берни булмады, – диде ул яшьләрен сөртә-сөртә.

Тәртип сакчысының тәҗрибәсе зуррак иде булса кирәк, бу сүзләргә ышанасы килмәде. Кырыс тавыш белән әмер бирде:

– Кая, документларыңны күрсәт!

Камалия куртка кесәсенә кулын тыккан итте һәм... Ни хикмәт – паспорт шунда! Кыз, балаларча шатла-

PRESSA.RU

нып, паспортын полиция хезмәткәренә суззы. Документы кулда, димәк, кайтып китәргә өмет бар.

– Казанга кайтам. Бүген үк утырам поездга! – дип сөйләнде ул. Әнә паспорт арасында берничә йөзлек акча да күренә. Әле генә елап утырган кызның рәхмәт әйтеп китеп баруын тегесе ни дип тә юрарга белмәде:

– Хәерле юл, туташ!

Чират, һай, озын тоелды аңа. Бу дөньяның кеме генә юк. Әнә бер әби кассир хатыннан билет таптыра. Тегесе баш чайкаган саен: «Улым янына кайтам. Билет кирәк! Бәлки соңгы юлым булыр», – дип тәкрарлый. Икенчесе – студент бугай – «Билет юк!» дигәнгә исе китми генә, башка көнгә дә ярый, диде. Ә Камалиягә билет бүген үк кирәк. Аңа монда калырга ярамый.

– Билет юк.

– Ничек инде юк?

– Бүгенгә билетлар юк. Иртәгәгә аласызмы? – Кассир хатын хисләрнең төрлесен күргән – исе китми.

– Миңа бүген кайтырга кирәк. Монда башка сәгать тә кала алмыйм.

– Берни белән ярдәм итә алмыйм. Кая, икенче кеше кем анда?

Кызны тагын чираттан этеп чыгардылар. Әрсезләнгән, күзгә күренеп терсәклегә әйләнә барган Камалия янәдән пыяла тәрәзә төннегенә бакты.

– Минем бүген билет алу мөмкинлегем бармы? – диде ул шактый нык итеп.

– Өметсез – шайтан! – диде кассир хатын. – Ходайдан сорагыз, бәлки, берәрсе алган билетын кире тапшырыр. Бездә шундый хәлләр дә була.

Менә анысын бик дөрес әйтте бит. Камалия белән дә ни генә булмас. Вакыйгалар, үз өеренә бөтереп, әллә нинди маҗаралар да әзерләп куймагае. Хәерле булсын!

Сәгать телләре авырлык белән генә алга тәгәри. Бер сәгать үтте, ике сәгать. Билет сатучы хатын аны таный ук башлады. Сорау биргәнче үк, юк, дип, башын гына чайкый. Эчкә салкын үтә, елап арыган күзләрен йокы сыкысы сара. «Минем әни әйтә торган иде, Ходайның һәр эше хәерле дип. Менә мин дә юлга чыктым әле, – ди аңа бер тавыш. – Якты дөньялардан кайчан китәчәгең белеп булмый. Кеше балчыктан ярала, балчыкка китә, диләр, анысы хак. Тик җаным тыныч түгел. Соңгы сулыш алганда, газизем – улым, бердәнберем янында буласым килде...» Камалия сискәнеп китте. «Җаным тыныч түгел», – дип, аның әнисе әйтәме әллә? Ә кызы аны юата да алмый, ул еракта, Мәскәү калаларында, таш диварда өметсезлек белән көрәшә...

– Апа, сезне кассага чакыралар.

Бу тавыш Камалияне генә түгел, улы янына кайтырга ниятләп билет өмет иткән тавыш иясен дә касса тәрәзәсенә капланырга мәҗбүр итте. Ярый әле, билет икәү булып чыкты. Карчыкның да йөзе яктырып китте. Бәхет бер килсә, колач җәеп килә – Камалиягә дә җиле кагылып үтте. Аңа дигән билет, әнә, кассада көтә. Тик... «СВ» вагонга акчасы җитми иде шул аның. Ә кассир хатын башканы тәкъдим итми. Алсаң, ал, югыйсә башка берәүгә сатам, тагын ике сәгатьтән поезд Казанга китә, ди... Китә, ди! Мең ике йөз сумны каян табарга? Вокзал уртасында кеше талап булмый бит инде. Нишләргә? Бертуктаусыз башта шул уйлар бөтерелде. Бер юлы булырга тиеш ләбаса! Менә хәзер җае чыгарга тиеш! И-и Ходаем, ярдәм ит, дип кулларын догага күтәрде ул. Шулчак могҗиза булды – муенындагы алтын чылбыры өзелеп, кулоны чылтырап асфальтка тәгәрәде. Камалиянең исә өмет дисбеләре бер җепкә тезелә башлады. Алтын яфракны учына йомарлаган килеш, ломбард эзләп, әрле-бирле сугылды ул. Менә тапшырды да. Билетны алып, бәхетле вагонын эзләп йөгерде. Һәм... тамбурда баягы әбине күреп, аптырап китте.

– Ни булды сезгә? – диде ул, аның агарынган йөзенә карап.

– Таныш булмаган ниндидер сакаллы ир-ат белән бер купеда ничек кайтмак кирәк? – Үзенә күрә аның да борчуы җитди иде.

Камалия, үз купесындагы юлдашы белән килешеп, әбине үз янына урнаштырды. Аның авыз эченнән укыган рәхмәтләренә эреп китте кыз. Менә шул халәттә Казанга кайтып җитәсе иде. Әнисе тавышы кебек ягымлы шул. Бер чынаяк чәй йотса, тагын да дөньялары түгәрәкләнер иде. Әбинең тәмләп чәй шүпергән тавышына чыдамады, бөтен үпкәләре кайнап диярлек тышка ишелеп чыкты – сулкылдып елап җибәрде кыз. Бу юлы әби юатты инде аны. Беренче һәм соңгы күргән танышыңа бушанырга була. Сөйләде Камалия, нинди мыскылга дучар булганын да сөйләде, интегүләрен дә яшермәде.

– И-и балакаем, борчылма, барысы да артта калсын. Күңелеңнән алып ташла ул адәм актыгы кыланмышларын. Минем сүзем үтә әле – улым белән сөйләшеп карармын, үз янына эшкә алыр. Бу бозыклар янында ни эшләмәк кирәк? Улым бик яхшы минем. Менә Мәскәүгә дә юллады, әни, акча күпме кирәк, әйт, жәл түгел, диде. Зур кеше ул минем. Директор. Кулыннан килмәгән эше юк. Самолетка гына утырып кайт, диде дә, ризалашмадым. Куркам мин ул һава очкычларыннан. Менә каршы алыр әле...

Казан аларны чыннан да якты нурлары белән каршы алды. Камалия ирексездән елмайды. Башкаладан әллә нинди маҗаралар белән иза чигеп кайтып килә ул. Ә барыбер рәхәт. Әнә Әсма әбисе дә үз итеп өлгерде аны. Ул әйтмешли, ничу изелеп яшәргә. Дөньяда әнә яхшы кешеләр дә җитәрлек икән ич.

Камалия үз күзләренә үзе ышанмады. Әнисен каршыларга дип, әле яңа гына самолет трабыннан төшеп, машинасын тимер юл вокзалына куып килгән кичәге директоры – Асманов басып тора иде.



Лариса
МАЛИКОВА

БАЛАЧАКТА УК СПОРТ САРАЕНЫҢ МОЗАИКАЛЫ ДИВАРЫНА ЯЗЫЛГАН «О, СПОРТ, ТЫ – МИР!» СҮЗЛӘРЕН УКЫП УЗА ТОРГАН ИДЕМ. НИКАДӘР ТИРӘН МӘГЪНӘ САЛЫНГАН БУЛГАН ИКӘН АҢА!

ОЛИМПИАДА ДӘРЕСЕ

Олимпиада... Ул башланганчы ук әле никадәр каршылыклы хисләр кичердек без. Минем өчен генә түгел, күпләр өчен бу Олимпиада башта – өметсезлек, соңыннан могҗиза, горурлык, сабак биргән Олимпиада булып чыкты. Баштарак бу Олимпия уеннары Россия җанатарларына бик кирәк тә булмады кебек. Бер танышым (мин аны спортның бөтен төрләрендә дә эксперт дип санаган идем): «Юк, мин Олимпиаданы карамыйм», – дип гаҗәпкә калдырды. Һәм монда хикмәт Корея белән Мәскәү вакытындагы сәгать аермасында гына да түгел! Ярышларның күбесенең төнлә йә эш вакытында узуы да сәбәп була алмый. Бу инде принципка әйләнгән иде. Олимпия уеннарына безнең иң көчле, иң шәп спортчылар чакырылмады. (Бу инде билгеле факт, аларга тукталып тормыйм.) Чөнки безнең намусыбызга, абруебызга тия торган, безне түбәнсетә торган хәл иде ул. Бу Олимпиадада командабыз да юк, әләмебез дә... Җанатарларның күпчелегендә уеннарга карата битарафлык чагылды. Якын танышларым, дөресен әйтим, үзем дә телевизор экраннары каршына ашыкмадык. Мин хәтта Олимпия уеннарының ачылышын да карамадым. Ләкин... берзаман безнең 15–21 яшьлек спортчылар – кичәге юниорлар могҗизага тиң күрсәткечләре белән таң калдыра башлады. Халыкка җан керде. Без инде хәзер Олимпиаданы гади күзәтеп баручылар гына түгел, без җан атабыз, көч бирәбез, горурланабыз, сөенечтән елыйбыз, сабак арты сабак алабыз. Һәм безнең өчен бронза медальләр, ышаныгыз, алтыннардан да кыйммәтрәк!

Олимпиада биргән сабакларның берсе – бу яшь балаларга әллә ни өмет тә багламаган идек бит без! Ә алар... карагыз инде! Дүртенче булып барган чаңгычы Денис Спицов, Франция спортчысын узып, Норвегиянең легендасына әйләнгән Клэбоның үзе белән беренче урын өчен ярыша! Финишка икенче булып килә һәм, булдыра алмадым дип, гафу үтенә!..


Фото: wikipedia.org

Дмитрий Губерниевның тимераякта фигуралы шуучы кызлар турында әйткәннәре мактау сүзләреннән дә көчлерәк: «Болар – тимер кызлар! Алар алдында тезләнсәк тә була!» Ә бит алар арасында татар кызы Алинә Заһитова да бар! Менә шунда инде тамакка төер тыгыла, күзләргә яшь килә. Олимпиадада сокланырлык чыгыш ясаган Татарстан спортчылары Евгения Тарасова, Андрей Ларьков, Анна Нечаевскаялар турында берберебезне бүлдерә-бүлдерә сөйлибез.

Инде икенче сабак... Беләбез: күп спортчыларыбыз бер сәбәпсез Олимпиадага чакырылмады бит. Спорт белән сәясәт буталды. Шунысы сөендерә: башка илләрнең спортчылары бу позициядән өстен булып чыкты. Тимераякта шуучы Наталья Воронина Олимпиадага ялгызы гына килгән: тренеры да юк, булышучы командасы да. Тренировка вакытында күзләре тулы яшь иде аның. Спортның бу төрендә парлап шуарга кирәк шул. Чех спортчысы Мартина Сабликова аның янына килеп: «Болай булмый, әйдә бергәләп», – ди. Һәм... Мартина – алтын, Наталья бронза медаль яулады.

Россия белән АКШ чаңгычылары арасында да җылы мөнәсәбәтләр урнашкан. Спринт вакытында егылып чаңгысын югалткан безнең Алексей Виценкога АКШ командасы тренеры Мэтт Уиткомб трассага чыгарга булышты.

Ток-шоуларда Украина экспертлары тарафыннан күпме пычрак ява безнең якка. Без инде «москаль» гына... Һәм менә күрегез! Фристайлда беренче урынны яулаган украин егете чемпион Абраменко белән үзебезнең көмеш алган егетебез Илья Буров, Украина әләме астында кочаклашып торалар...

Спортчылар гаиләсе Анастасия Брызгалова белән Александр Крушельницкий Олимпиадада да, илебез тарихында да кёрлингта беренче медальне яуладылар. Ләкин Пхёнчханнан күңелсез хәбәр килде: Крушельницкий тестында мельдоний табылды. Әлбәттә, беркемнең дә ышанасы килми! Шунысы сөендерә: башка илләрнең спортчылары да ышанмый моңа. Хәтта дүртенче урынны яулаган һәм, Россияне медальсез калдырган очракта, бронза алачак Норвегия спортчылары да моның белән килешергә ашыкмый.

Шулай ул – безнең олимпиячеләр җиңүгә беркемдә бернинди өмет калмаганда да җиңә беләләр. Олимпия уеннары ябылу тантанасында да безнең спортчылар Олимпия экипировкасыннан горур рәвештә Россия әләме белән узар дип өметләник.

Һәм мин Олимпиада ябылу тантанасын, һичшиксез, караячакмын.

PRESSA.RU

Мин аларда эшем буенча еш булам. Җай чыкканда, сөйләшеп утырырга да яратам. 95 яшен тутырса да, зирәк акылы, зиһене белән сокландырган Нәҗия апаның хатирәләре күбрәк гел бер тирәдә әйләнә. Вәли... Сөйләп туктый да, үзе дә сизмәстән, гел өстәлдәге фотосурәтләргә үрелә – әкрен генә аларны сыйпый башлый. Алар анда икесе дә – Нәҗия дә, Вәли дә – яшьләр, чибәрләр, бәхетлеләр...



Рәхилә НИЗАМЕТДИНОВА



Фото: www.pixabay

ГОМЕРЛЕК ӘРНҮ

Бу бәхетсез мәхәббәт кыйссасын ерактан – Нәҗиянең балачагыннан ук башларга кирәктер. Салам түбәле йортлар янәшәсендә калкып күренеп торган кызыл кирпечле бай йортыннан. Сукыр мәхәббәт корбаныннан – Нәҗиянең әтисеннән...

Революциядән соңгы еллар. Хәмит атлы чекист яхшы сакланган бай йортына хуҗа булып ала. Заманасы шундый: кемнең кулында – шуның авызында. Кем аягын алдан киенә, кем үткенрәк, кем усалрак... Ярлы кызы Гөлсемне урлап диярлек алып кайта ул. Кызның: «Сөйгән ярым калды», – дип ялварганын ишетергә теләми көче ташып торган ир-ат. Кырыслыгы һәм каты куллылыгы белән тирә-юньдә атказанган була Хәмит. Гөлсемне күрергә, хәлен белергә килгән олы яшьтәге әтисе, бикле капка аша уза алмый, кире борыла. Кеше янына ничә чыкса да, Гөлсем битендә гел кара янган, күгәргән эзләр була. Хәмитнең кулы бер дә тик тормый – хатынын яшь чакта йөргән егетеннән көнли. Шулай еллар уза. Сынган сөякләр төзәлә дә тагын сына, күгәргән күз төпләре гадәти күренешкә әйләнә. Түзә Гөлсем – түзми кая барсын?! Бер-бер артлы гаиләдә өч бала туа. Нәҗия – аларның олы кызлары. Әнисенә өй эчендә булышулар, кечкенә туганнарын караулар – барысы да аның өстендә була.

Әнисенең ничек җәберләнеп яшәвен кечкенәдән күреп үсә Нәҗия. Гаиләгә фаҗига килгәндә аңа 9 яшь була. Берсендә әтисе әнисен бик каты кыйный. Идәндә аунап яткан әнисен жәлләп, кызының аңа су биргәнен күргән ата кеше тустаган белән Нәҗиянең башын яра. Өстәвенә, кыз, җайсыз егылып, кулын да авырттыра. Сызлануга, әрнүгә түзә алмыйча, аннан бигрәк чарасызлыктан кыз үксеп еларга тотына...

Әнисе өчен соңгы тамчы була бу. Бәхетсезлекләренә каршы... Иренең чыгып китүен генә көтеп тора да, балаларын җыеп, атасы йортына кайтып китә ул. «Юклыкка гына түзәрбез, көн саен баш өстемдә йодрык уйнамас, изелеп яшәмәм, ичмасам», – ди әниләре.

Ачуыннан котырган Хәмит гаиләсе артыннан шул көнне кичкә үк килеп җитә. Ләкин, ни гаҗәп, үз-үзен кулда тотып, башта ул алар белән матур сөйләшә. Киявен бу халәттә күрмәгән бабай, аны акылга утырту

нияте белән, Хәмиткә катырак – тавышын күтәребрәк эндәшә: кызын якларга теләп, үзенчә ниндидер таләпләр куя. Үз сүзен генә сүз итәргә, башкаларга баш булырга өйрәнгән әзмәвердәй ирне арканларга теләве аның бик зур ялгышы була... Коточкыч ялгышы. Кызы, өч онығы каршында кансыз кияве картны атып үтерә... Калганын Наҗия бик начар хәтерли... Ата кешене кулга алалар, бабаларын гүргә иңдерәләр, әниләрен җүләрләр йортына озаталар. Берсенә – 5, икенчесенә 2 яшь булган сеңлесе белән энесен, ат чанасына утыртып, каядыр алып китәләр. 9 яшьлек кызның: «Туганнарымнан аерылырга теләмим!» – диюен, әлбәттә, берәү дә ишетми. Кинәт килгән бу хәсрәттән югалып калган, ни уйларга белмәгән Нәҗиянең үзен Норлат балалар йортына озаталар. Әтисе бәреп екканда кулы сынган булуы берничә көннән генә ачыклана, тик вакыт инде узган – ялганса да, кулы зәгыйфь булып кала.

Ятимлектә узган еллар... Төшендә әнисен күреп елап уянулар, сеңлесе белән энесен сагынулар... Күңелгә ул чакта утырган юшкынның беркайчан юылмаячагын, йөрәгендә гомерлек яра эзе калдырачагын ул әле белми.

Сугыш башлана... Наҗиянең чәчәк атып килгән гүзәл яшьлек чоры... Кечкенә генә гәүдәле булса да, эшен җиренә җиткермичә туктамаучы тырыш бу кыз Казанга тегү фабрикасына өйрәнчек булып урнаша. Матур күлмәкләр тегәргә хыялланып йөргән кызны шинель тегәргә утырталар. Зарланырга яратмый Наҗия: гарип кулы арыса, чиратлаштыра – сиздермичә генә сул кулы белән эшләүгә күчә. Авырткан кулына вакыт-вакыт тамган ачы күз яшьләрен дә берәүгә дә күрсәтми. Хәер, күрсәләр дә, кем жәлләсен – чоры нинди бит: һәркемнең үз хәсрәте. Кулы бу кадәр сызламаса, әтисе искә төшкәндә: «Күралмыйм!» – дип уйламас иде... Тагын – йөрәге сулыгып-сулыгып әрнемәсә...

Туганнарын эзләп караулар бернинди нәтиҗә бирми – сабыйлар суга төшкәндәй юкка чыга. Беркайда Наҗияне куандырырлык яңалык әйтмиләр. Ә аннан, көтмәгәндә, ерак бер туганын очрата Наҗия. Язмыш үткен балтасы белән кызның йөрәгенең уртасына ук чаба ул көнне. Кечкенә сеңлесе вафат, энесе Казан артындагы бер гаиләдә асрамада, атасының башы төрмәдә черегән... Болары, әйе, фаҗига. Ә әни кешенең кияүгә чыгып Кырымга китеп баруын ничек кабул итәргә?! Монысын кыз бөтенләй башына сыйдыра алмый. Нигә ул аны эзләмәгән? Нигә тапмаган?!

Көзләрне – язлар, кышларны җәйләр алыштыра. Наҗиянең соры булып тоелган тормышына ташкындай ургылып мәхәббәт килеп керә. Вәли исемле була ул. Гашыйк кыз өчен дөньядагы иң матур исем!

Яшьлекнең күлмәге матур: авырлыкларны сизми дә, аңа уен, җыр, бию кирәк. Наҗия пианинода уйнарга өйрәнү, җырларны көйгә салу турында хыяллана. Их, вакытында белем алырга да мөмкинлеге булса... Ләкин үзлегеннән барыбер уйнарга өйрәнә ул! (Мәхәббәт кешене нишләтә!) Киләчәген Вәли белән бәйләргә тели кыз. Моның шулай булачагына ышана да...

Егет, ниһаять, тәвәккәлләп, Наҗияне туганнары белән таныштыра. Бусагадан атлап кергән яшьләрне куанып каршылыйлар, кызның уңганлыгын да бик тиз чамалап алалар. Әмма икенче бер баруларында Вәлинең әнисе Наҗиянең кулына игътибар итә. Сөлектәй улының тормышын зәгыйфь куллы хатын белән бергә күз алдына китереп карый да, ана кеше Вәлине икенче бүлмәгә чакыра. Сүзен кыска тота, турыдан бәреп әйтә: «Тормыш итәргә пар куллар кирәк. Минем оныклар сөясем килә. Гарип килеш бала алып кайтмас ул, безнең муенга бер элмәк кенә булыр. Аннан, картайгач, безне кем карар? Синең хатынның түгелмени?!» Күрше бүлмәдәгеләр ишетер дип тормыйча, курыкмыйча кычкырып әйтә. Аны берәү дә туктатмый, каршы төшми. Үз бәхетеннән исереп йөргән Вәли дә, күкрәк астында инде яңа җан яралуын сизгән Наҗия дә, киленнең миһербанлы бала икәнен тойган кайната да... Очрашулар сирәгәя, аралар суына. Наҗия, соңга калып булса да, баласын төшертә. Бу яшьлек хатасы һәм ашыгу аны мәңгегә ана булу бәхетеннән мәхрүм итә. Ә Вәлине... Вәлине ул гаепләми, гафу итә һәм... гомере буена өзелеп ярата, онытa алмый, башка ир затына инде күтәрелеп карамый. Йөрәкне соң... тыеп буламыни?!

Күз алдында гел бер сурәт – Вәли була аның...

Язмышның тагын бер сынавы аны яше иллегә якынлашканда эзләп таба. Тегү фабрикасыннан бирелгән фатирга күчеп йөргән вакыты. Бусагасында таныш түгел бер ханым пәйда була. Наҗия имәнеп китә – әнисенең чалымнары лабаса бу хатында! Танышалар... Әйе, ул, чыннан да, аның Кырымда туган сеңлесе булып чыга – Флера. Икенче ире үлгәч, әнисе өч бала белән Казанга күчеп кайткан икән. «Моңарчы мине искә төшермәдегез бит, хәзер генә нәрсәгә кирәгем булды?» – дип сорарга талпынган Наҗияне беренче тапкыр күргән сеңлесенең:

– Торырга урыныбыз юк... – дигән сүзе туктата.

Ничек «юк» диярго?! Әни бит ул!.. Әле үзе рәхәтен дә күрергә өлгермәгән фатирына Наҗия яңа туганнарын да сыйдыра. Бераздан бертуган энесен дә эзләп табалар. Ике еллап урын өстендә яткан әнисен тәрбияләп, соңгы юлга озату да аның җилкәсенә төшә.

Тормыш янә үз эзенә төшеп, тигез юлдан әкрен генә тәгәри. Ул арада гомер генә узып китә. Бердәнбер гомер... Ә Вәлинең гомере бөтенләй кыска булып чыга: 40 яше дә тулмыйча кинәт вафат була ул. Вәлинең әти-әнисе онык та, тәрбия дә күрмичә картая...

Бүгенге көндә Наҗия апаның инде үзе дә 80 гә якынлашып килүче туганы Флера карый. Ялгызлык, әниләренә соңлап булса да килгән үкенү хисләре, гафу соравы барыбер якынайткан аларны. «Ничә тапкыр талпынсам да: «Ул чакта нигә мине ташлап киттең?» – дигән сорауны әнигә бирмәдем, кызгандым, – ди Наҗия апа. – Туганнарым бар – шулар белән бәхетлемен».

PRESSA.RU

БӘГЫРЬЛӘРГӘ ТӨШЕП, ҖАННЫ ТЕЛЕП ТОРГАН АЧЫ ЯЗМЫШЫНА ҮПКӘЛӘМИ УЛ. ХЫЯЛЛАРЫ ЗУРДАН АНЫҢ...

Сокландым, тетрәндем... Каршымда, берни булмагандай, көләч йөзен балкытып, минем белән дөнья хәлләре турында фикер алышып утырган әңгәмәдәшемә күрсәтмичә генә – ихтыярсыздан күзләремә килгән яшьләрне сөрткәләп тә алдым.



Мәдинә АВЗАЛОВА

ЯШӘҮ — ҮЗЕ БАТЫРЛЫК

Сөйләшү көтмәгәнчәрәк башланып китте. Дөресрәге, җырдан... Тизрәк аның тавышын ишетәсем, җырлавын тыңлыйсым килде.

Ул ялындырып тормады. «Иң яраткан җырым», – диде дә, күкрәктән чыккан моңлы тавыш белән: «Шатлык нуры балкый безнең йөзләрдә / Өмет-ышанычны аклыйк без, аклыйк», – дип җырлап җибәрде. Җыр өй эченә генә сыеша алмыйча, Чүпрәленең карлы-буранлы урамнарына агылды. Аннары: «Мәскәүдә «Россиянең алтын тавышы» бәйгесендә беренче урынны алган җырым», – дип, «Киек казлар»ны сузып җибәрде. Тын да алмый өй түрендәге өстәл артында утырган кызны күзәтәм: озын итәкле зәңгәрсу күлмәге үзенә шундый килешә, толымлап үреп салган чәчләре аңа балалык төсмере дә биргән сыман. Җыр ничек кинәт башланган булса, шулай кинәт кенә өзелде дә. «Күп алар, мин яраткан җырлар», – ди кыз, җитди сөйләшүгә әзерлеген белдергәндәй итеп.

Бусаганы атлап керүгә урнашкан киеренкелек шундук юкка чыга. Без өчәү: Дарина, әнисе Венера ханым һәм мин язмышның ачылмаска дип ябылган капкаларын, сак кына ачып, тәрәзә артында улаган җилбураннан да көчлерәк, җан өшеткечрәк халәттә калабыз. Бар дөньясын онытып, хәерсез хатирәләргә бирелгән ул минутларда кызның ара-тирә әнисенә: «Хәлең ничек? Начар түгелме сиңа?» – дип өзгәләнүеннән, янымда әле күптән түгел генә инсульт кичергән авыру кеше утыруын аңлап алам.

«Әни булмаса, тормыш юк миңа»

Дарина шулай ди. Әни ул һәркемгә изге, кадерле. Ә аның өчен бигрәк тә...

– Икәү торабыз, икәү пешерәбез. Әни булганда, яшим әле мин, – ди кыз, пакет тулы дарулар арасыннан кирәклеләрен сайлап. – Үзем күзәтәм, әчми югыйсә. Гел әйтеп торырга кирәк.

Әни, әни, әни... «Кызыгыз бигрәк кайгырта инде», – дим,順ныбызда тып-тын гына утырган хуҗабикәне сөйләштерәсем килеп. Ләкин ул дәшми. Сабыр гына без сөйләшкәнне тыңлый.

– Мәктәпне шушы авылда тәмамладың инде, – дим, сүзне ерактан башлап.

Шулай диюгә, Венера ханымның йөзе үзгәреп китә. Күрәсең, бертуктамый тынгысызлап торган газаплы уйларын уятып җибәрү өчен шушы бер сорау да җитә аңа. Аңлыйм аны. Шуңа да артык төпченмим. Үзләре сөйләгәнне көтәм.

– Унынчы сыйныфта чагы, – дип ачыласы итә үзе дә шул мәктәптә озак еллар укытып, лаеклы ялга чыккан Венера Гариповна. – Тәнәфестә ике кыз баламны баскычтан төртеп төшергән. Шуннан соң атна-ун көн йөрде әле. Карыйбыз: кызның аягы зәңгәрләнеп чыкты, аннары шешә башлады. – Ул туктап кала. Күзләренә яшь килә. – Кызлар гына гаепле...

– Әни, беркем дә гаепле түгел. Очраклылык... – ди кыз, әнисен туктатып. – Берәү дә иртәгә үзе белән ни буласын белми. Үпкәләмим мин аларга.

Очраклылыкмы, күрәчәгеңме... Ничек кенә дип әйтсәң дә, шаярышып төртешүләрнең ахыры Даринаны гомер буе озата барган авыр сынаулар алдына куя. Кызны бер хастаханәдән икенчесенә йөртүләр башлана. Бер ел шулай дәвам итә. Дарина хәзер ничә мәртәбә операция кичергәнен дә төгәл генә әйтә алмый. Күп алар, санап бетергесез. Ул Казан хастаханәсендә ятканда чыгарылыш имтиханнарын тапшыра. Гел «бишле» билгеләренә генә. Кызның аягын саклап калу өчен табиблар мөмкин булганның барын эшли. Ләкин иң тәҗрибәле хирурглар үткәргән операцияләр дә файда бирми.

Шул ук елны Дарина Фәхретдинова Казан дәүләт химия-технология институтының икътисад факультетына укырга керә («Ул чагында хет бер аягымда идем әле», – дип куя кыз. – *авт.*). Шул ук елны ул яшь җырчылар белән төрле кызыклы проектлар алып баручы продюсер Җәүдәт Гыйльмановны эзләп таба. Протезлы аягы кызга сәхнәгә чыгарга да, бәйгеләрдә беренче урыннар алырга да, институтта укырга да, беррәттән ТИСБИда юрист белгечлеге алып чыгарга да комачауламый. Тормышны, кешеләрне яратканга шулай буладыр ул! Сүнмәс кояш шикелле нур чәчеп торганга! Даринаның дуслары, якыннары аны әнә шундый итеп беләләр.

Йөзеннән азга гына да елмаю китми. Хәтта тормышындагы иң авыр мизгелләр турында сөйләгәндә дә...

Сынаулар дәвам итә

Дарина соңгы курсларда читтән торып укуга күчә. Сәламәтлек саклау идарәсенә баш белгеч булып эшкә урнаша.

– Укы да, эшлә дә, концертларга да йөр... авыр булмадымы соң? – дим.

– Ю-ю-к, – ди кыз суза төшеп, – яраткан эшең булгач, берсе дә ардырмый, рәхәт кенә ул.

Әмма озак та үтми, Даринаның җайга салынып килгән тормышына җитди төзәтмәләр кертүгә сәбәпче булган тагын шул каһәр «очрак» кабатлана.

– Бервакыт халык белән шыгрым тулы автобуста эштән кайтып киләм, – дип сөйли кыз. – Беркемнең беркемдә эше юк. Һәркем каядыр ашыга. Үземнең тукталышыма килеп җитәрәк, ишек янына килеп бастым. Ул ачылып китүгә, ашыга-кабалана төшүче кешеләр мине төртеп җибәрделәр. Басып кала алмадым, сәламәт аягымның тезе белән җиргә килеп төштем.

Янә шул бер хәл, янә шул бер сүз: төртеп төшерделәр. Тагын хастаханә, йокысыз төннәр, сызланулар... Табибларның инде бу юлы икенче аягын саклап калу өчен көрәшүләре... һәм ул тагын берниндн нәтиҗә бирми. Озак эшләми торгач, кыз кыскартуга эләгә. Эшен югалта. Әмма аны шул мәлдә эш түгел, башкасы борчый: Казанда ясалган протезлар бик уңайсыз.

Фото: Фәхретдиноваларның шәхси архивыннан

PRESSA.RU



Кызы өчен әнисе җан сөенече генә түгел, тормыш терәге дә. Тормыш тоткасы, аягы, кулы... Киләчәккә уй-хыялларын ул әнисе белән бәйли. Алар гел бергә.

Җырчы кеше сәхнәгә аю кебек алпан-тилпән килеп чыга алмый бит инде. Әйбәтләрен каян табарга? Красноярск шәһәрендә яшәүче бер танышы аңа Мәскәүгә барырга киңәш бирә.

Шөкер, арабызда игелекле кешеләр бар. Җирдәге фәрештәләр алар Дарина өчен.

«Очып йөрдем»

– Мәскәүгә барыр алдыннан, протезлар белән шөгыльләнүче шәхси эшмәкәр Валерий Перевозников белән телефоннан сөйләштем. Ул протезларны, заказ буенча, Германиядән кайтартуларын, аларның бик кыйммәт торуын аңлатты. Бәясен әйткәч, чүт егылып китмәдем (ул авыр сулап куя. – *авт.*). Булырлык түгел икән, дидем. Бер танышым интернетта, минем хәлләрне әйтеп, хәбәр урнаштырды. Минтимер Шәймиевкә ул ничек барып ирешкәндер? Берзаман ТАИФ аша минем счетка 4 миллион (кирәкле сумма) акча күчте. Сөенүләремне күрсәгез! Мин аңа чиксез рәхмәтле...

2013 елда ясалган ул протезлар хәзер искергән. Даринага алар белән йөрүе көннән-көн кыенлаша бара. Без килгәндә дә ул утырып кына торды. Протезларны яңартыр өчен миллион сум акча кирәк. Кыз игелекле кешеләр ярдәменә ышана. Ике сүзнең берендә Аллаһыга мең кат шөкер укый. Шөкрана кылучыга Аллаһы Тәгалә бирермен дигән. Бәлкем, бу язма кайберәүләргә изге эш кылу өчен этәргеч тә булып куяр. Мин дә моңа ышанам.

Кыз әлегә бирешми. Ул инде Мәскәүгә барып, ВТЭК мәсьәләсен дә хәл итеп кайткан. 2012 елга кадәр өченче группа белән йөргән Дарина Фәхретдиновага Мәскәүдән беренче группа инвалидлык биреп кайтарганнар. Ай саен килеп торган 12 мең сум пенсия, аз булса да акча бит әле ул.

– Планнарың нинди? – дигән соравыма Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Дарина Фәхретдинова: «Планнар зурдан», – ди дә тезеп китә. Алла боерса, аны әнә Мәскәүгә апрель аенда булачак «Таланты России» бәйгесенә чакыралар. Тагынмы?! Тагын аның продюсеры белән бергә «Дарина һәм яшь йөрәкләр» проектын гамәлгә ашыруда катнашасы бар. Ә тагын аның фатир проблемасын хәл итәсе бар. Килешү буенча биш елга дип алган фатирны үз милке итеп яздыру турында хыяллана ул. «Фатир өчен дә, коммуналь чыгымнар өчен дә үз вакытында түләп барам, – ди әңгәмәдәшем. – Тик миңа килешүне тагын да озайтырга мөмкиннәр», – дип кисәттеләр. Әгәр милекче булсам, Юдинодагы ул фатирымны Казанга алыштырыр идем. «Таттелеком» җитәкчесе Лотфулла Нурисламович Шәфигуллин алыштырырга булышырмын, дигән сүз әйтте».

Дарина «Таттелеком» җитәкчесе белән 2009 елдан бирле таныш. Дөрес, ул аның үзен күреп белми. Ә менә аның ярдәмен, озак еллар тоеп-күреп яши. Бер тапкыр дус кызы аны үзенең туенда җырларга чакыра. Шул тантанада Лотфулла Шәфигуллин да була. Кызның җырлавын ишеткән, күрәсең. Күп тә үтми, Даринаны Казанда уздырылачак «Возьмемся за руки, друзья» дип аталган бәйгегә чакыралар. Бәйгедә катнашу өчен «Таттелеком»нан машина җибәрәләр. Кыз анда Гран-при яулый. Шул көннән алып быелга кадәр ничәмә-ничә еллар кызны шул оешманың машинасы йөртә. Эшкә алып бара, алып кайта. Кирәк икән, авылга әнисе янына алып кайта. Бәйгеләргә йөртә. «Быелдан тукталды инде, – ди Дарина. – Эшләрендә проблема килеп чыкты, ахрысы. Хәзер бит бөтен җирдә кыскартулар бара».

Әлбәттә, Дарина Юдинодан Казанга такси белән эшкә йөри алмый. Аннары... эш бирергә атлыгып торучы да юк бит әле. Хәзергә ул вакытлыча, декрет ялына киткән кеше урынына эшләп тора. Ә аннан соң нишләр? «Нинди эштә эшләр идең?» – дигән соравыма, ул: «Мин – юрист. Хатлар, суд карарлары белән шөгыльләнер идем, яратам мин шундый эшләрне», – ди.

Ә бит кызның мәшәкатьләре аннан башка да җитеп ашкан. 2011 елгы операциядән соң Даринада аллергия башланган. Бакчага чыгып, үлән җыйса да – аллергия, мунчага кереп, парланып утырса да – аллергия... «Күкрәгемне шундый итеп китереп кыса, яшәү белән үлем арасында калам».

Юк, ул зарланмый. Ул, гомумән дә, зарлана белми. Аның «барысы да яхшы, барысы да әйбәт». Ул арада радиодан җыр тапшыра башлыйлар. «Дөнья бит ул, дөнья бит ул / Миннән соң да, беләм, калыр. / Ришвәт биреп калып булмый, / Бер көн, беләм, килер әҗәл, / Ярдәмемә мохтаҗ булып / Кемдер калыр, шунысы жәл...» Нинди матур җыр! Кем ул, кем җырлый?!

– Дарина Фәхретдинова җырлый, – ди кыз, моңсу гына. – Минем яраткан җырым...

Һәм ул, радиодан агылган моңга кушылып, җырлап җибәрә. Ул җырларда аның әйтелми калган сүзләре, күңел түренә яшеренгән, хәтта үз-үзенә дә таныргa кыймаган серләре-хыяллары... Гомеренең үткән кадәресе дә, алдагысы да тоташ көрәш кенә аның. Яшәү өчен көрәштән. Яшәү аның өчен үзе батырлык! Ә җырлап яшәү бигрәк тә...



РӘХИМБАЙ Илшат

Казан дәүләт гуманитар-педагогика институтының музыка факультеты, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетының кино факультеты

Өйләнгән, бер кыз үстерәләр

Карьера: кинорежиссер

Тормыш шигаре: «Дөрес хәрәкәттә – хакыйкый бәрәкәт!»

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

сөендерде

Җәннәт туган телдә сөйләшә!

Кызым Җәннәт җөмләләп сөйләшә башлады. Миңа бигрәк тә аның бормалы-бормалы итеп, иярченле кушма җөмләләр белән сөйләшүе ошый. Саф татарча! Мин, үзем дә сизмәстән, сөйләмемә рус сүзләре кыстырам икән. Кызыбызга бу «чир» йокмасын дип, аның телендәге чисталыкны саклап калу өчен тырышабыз. Әлегә тырышлыгыбыз бушка түгел – шунысы мөһим!

Кыстылар – кыздырдылар

Татарстандагы ике вакыйганы атыйсым килә. Беренчесе: балалар өчен татар телендә «Шаян» телеканалы ачылды. Уңышлар аңа!
Икенчесе: «Татаркино» белән берлектә, Татарстан районнары буйлап «Алмачуар» фильмы өчен кастинг турларына чыктык. Тулы метражлы әлеге жанр дебютым булачак. Төп геройны уйнар өчен 12–16 яшьлек үсмер егетләрне, кызларны эзлибез.
Мәктәпләрдә татар теле дәресләрен кысу тагын да кызыклырак, тагын да үтемлерәк яңа проектларга юл салсын иде.

Сакчылар да юк, турникетлар да...

Хатыным Язгөл Лейпциг шәһәрендә укыганда, мин дә анда барып, кызыбызны карап тордым. Германиядә бер җирдә дә сакчылар һәм метрода турникетлар булмавы сәер тоелды. Алар урынына метроның һәр станциясендә каһвә, донерлар бар. Станцияләр әллә ни купшылык белән аерылып тормый, тыныч. Кешеләрнең бер-берсенә ышанычы бар дигән сүз бит инде бу. Күңелләр җылынып китте, югыйсә соңгы араларда безне күзәтәләр, дигән коткы арыткан иде.

көендерде



Вакыт тизлеген арттыра...

Олыгайган саен вакыт тизрәк үтә икән ул. Балачак үзе бер гомер булган. Исегезгә төшерегез әле, ул бик озак үтә иде бит. Тизрәк үсәсе килә иде. Балачакта әти-әниләр вакыт җитмәүдән зарланганда, мин аларны шаярта дип уйлый идем. Хәзер үзем шул сүзләрне еш кабатлый башладым. Вакыт тиз узамы, әллә без үзебез гомер узганын сизмибезме?



Ә күңелдә барыбер канәгатьсезлек...

Европадан кайткач, күп кешедә канәгатьсезлек синдромы уяна.
Нигә бездә кешеләр сирәк елмая?
Ни өчен бер-берсенә ихлас хисләрен белдерүдән куркалар? Ни өчен Татарстанда җитештерелүче сыер маена пальма мае кушалар? Ни өчендер бездә гап-гади әйберләрне дә катлауландыралар? Ә бит бөтен нәрсә дә гади. Хәтта яшәү үзе дә.



Көйсезләнер чак түгел

Сәясәтчеләр, зур-зур түрәләр, малай-шалай кебек, бер-берсен уздыра-уздыра әшәкеләнеп кылана. Халык, телиме-теләмиме, шуларны күзәтергә мәҗбүр... Менә, мәсәлән, Көньяк Кореяның Пхёнчхан шәһәрендә узган кышкы Олимпия уеннарына Россия спортчыларының үз илләрен яклап катнаша алмавы, бары тик Олимпиада әләме астында гына чыгыш ясавы нәрсә инде? Әле болар белән генә бетсә, бер хәл. Көн туды исә сугыш белән яныйлар! Атом-төш сугышы белән дә! Ярый ла, Олимпиада – уен, ә сугыш?..

PRESSA.RU



БОЗ ҺӘМ... УТ ИЛЕ

Эльза НӘБИУЛЛИНА

Иң элек, кулыгызны күтәрегез әле, арагыздан кайсыгыз Исландиянең кайда икәнен беләʔ Юк, бу шаяру түгел, әлеге илне белмәүчеләр чыннан да бар. Югыйсә машинада сәяхәт итәргә яратканыбыздан хәбәрдар булган кайберәүләр: «Анда да машина белән бардыгызмы?» – дип сорамас иде бит. Ярар, зыян түгел, алай да иренми генә картага бер күз салыгыз да... (Карта белән танышу, гомумән, яхшы гадәт ул!) Әнә тегендә, Атлантик океанда, төньяктарак, шундый кечтеки генә утрау-ил бар. Менә шул инде ул – Исландия! Татарчага тәрҗемәдә: «айс» – боз, «лэнд» – җир дигәнне аңлата. Гәрчә халык телендә аны «Боз һәм ут иле» дип тә атыйлар. Ә утрауның ни өчен шулай аталганын соңрак аңларсыз!

«Ничек инде, монда да кешеләр яшиме?» – диярсез. Әйе, яши. Хәзерге көндә Исландия – планетабызның кешеләр иң соң үзләштергән почмакларыннан берсе. Исландия халкының викинг бабалары безнең эраның IX гасырында гына утрауга күчеп яши башлаган. Хәзерге көндә биредә нибары 320 мең тирәсе кеше яши. Билгеле, җәйге чорда – июль, август айларында туристлар хисабына утрауда халык саны ике тапкырга диярлек арта. Без дә узган җәй аларда халык санын арттырып кайттык әле.

I

Ә бу урында яңабаштан башлыйк. Гомумән, каян килеп чыктык соң без Исландиягә? Бер дә уйламаганда, хыялда, төшләрдә генә күреп ятканда...

Чыннан да, Исландия дигән могҗизалы утрау-илне күрә алсак шәп булыр иде дигән теләк инде берничә ел элек үк күңел түренә кереп оялаган иде. Әнә бит гел шуны сөйлиләр, әкияти ил, диләр, үзеңне анда башка планетадагы кебек хис итәсең, диләр. Табигатьнең бар могҗизасы – суы, уты, бозы, тавы бер урында, имеш. Тарихтан мәгълүм, биредә су юлларын «дер селкеткән» викинглар токымы яши. 2016 елда футбол буенча Аурупа чемпионатында аларның җыелма такымы бар дөньяны уңышлары белән шаккаттырган иде...

Ерак киттем, ахрысы. Тик шулай да, кызык бит! Әмма бик кыйммәт! Аеруча безнең ил туристлары өчен бу чынга ашмас хыял... кебек. Әмма теләгең зур булса, язмыш үзенекен итә икән. Җәйге ялларга бер ай чамасы калганда безгә дә уңыш елмайды. Көтмәгәндә, Исландиягә илтә торган арзан билетларга юлыктык. Әмма әлеге билетлар буенча вакыт чикле: нибары дүрт тәүлек! Тик бу вакыт эчендә утрауны урап, төп истәлекле урыннарны карап чыгарга мөмкин бит! Илнең төньякта урнашуы да безнең өчен өстәмә плюс булачак: биредә җәйге чорда кояш баемый. Димәк, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында Исландияне рәхәтләнеп гизәргә мөмкин!

Безнең бюджетка туры килердәй машинаны алдан ук арендалап куйдык, чөнки «тимер ат»сыз утрауда сәяхәт итүнең мәгънәсе юк: ерак китеп булмаячак. Утрау әйләнәсе, якынча, 1700 чакрым. Безнең максат – төрле кызыклы урыннарда туктала-туктала, утрау белән танышып чыгу.

Шулай итеп, Исландиягә без самолетта очтык. Утрауга эләгүнең тагын бер юлы бар: Даниядән паром белән су юлы аша килергә дә мөмкин. Ләкин күпчелек туристлар, билгеле, беренчесен сайлый, чөнки уңайлы да, тиз дә!

Исландиядәге коточкыч бәяләрне һәркем күз алдына китергәндер инде: утрауга бар кирәк-яракны, азык-төлекне шулай ук су яки һава юлы аша китерәләр бит. Әлбәттә, ул бик кыйммәткә төшә. Үз чиратында, бу ил үзе күп нәрсә җитештерми, мәгълүм сәбәпләр аркасында, җитештерә дә алмый. Шуңа күрә ашау, яшәү ягын без алдан ук уйлап куйдык. Әбугалисина белән Әбелхарис бер елга мәгарәгә ничек әзерләнгән булса, без дә якынча шулай әзерләндек. Минималь ашау: булганы белән чикләнү, нибары зур кибетләргә туктальп, чемченеп алырлык ризык алу; минималь йокы: анысы да машинада! Рухи азык чыганагы – табигать, һава һәм океан.

II

«Бозлы җир» безне яңгырлы салкын һавасы белән каршы алды. Хәер, монда җылы, кояшлы көннәр бик сирәк күренеш. Аэропорттан чыккач ук, йон оекбаш, башлык, свитерлар алганыма сөенеп куйдым. Ләкин шул ук вакытта күңел яңа маҗараларга әзер, кәеф тә күтәренке иде. Озак та узмады, арендага алынган машинага утырдык та элдерттек. Юллар бормалы булуга карамастан, бик уңай һәм шома.



Фото: автор

Җир астыннан бәреп чыккан кайнар чыганаклар – минем өчен чыннан да зур могҗиза!

Иң элек игътибар иткән нәрсә, ул, әлбәттә, утрауның ландшафты. Тирә-юнь мүк белән капланган, ара-тирә вак куаклар күренгәли һәм кайсы якка карасаң да, бөтен җирдә шәмәхә люпин чәчәкләре үсеп утыра.

Исландия, барлыкка килү ягыннан, дөньяда иң яшь утраулардан санала. Анда 140 тан артык вулкан бар, бүгенге көндә шуларның 26 сы – уяу вулканнар. Бу җирлекнең үзенчәлекле төзелешен һәм аның әле дә үзгәреп торуын шушы янартаулар билгели.

Утрауның зур мәйданнарын алып торган лава кырларына карап, таң каласың. Аларның күбесен йөз, ә бәлки инде мең еллар элек мүк каплап алган, әлеге мүк яшел келәмне хәтерләтә. Рәхәтләнеп ятып аунарга да була шушында. Ирексездән: «Әллә мин чынлап та башка планетага аяк бастыммы?» – дигән уй килә.

Биш чакрымга сузылган Рейнисфьяра пляжында да вулканнар үз эзен калдырган. Кешеләр бирегә су коенырга, кояшта кызынырга түгел, ә гадәти булмаган кара төсле – кара комлы пляжны күрергә дип килә. Моның хикмәте нәрсәдә соң? Кайчандыр янәшәдәге вулканның уянуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән лава океанга агып торган, һәм йөз еллар буена су аны

PRESSA.RU



■ Исландия – күпсанлы гейзерлар, термаль чыганаклар иле. Алар җирле халыкның көндәлек тормышында киң кулланылыш тапкан. Биредә өйләрне әлеге табигый чыганаклар, аларның пары ярдәмендә җылыталар, теплица, бассейннар өчен шушы кайнар су кулланыла, геотермаль электростанцияләр дә шулар хисабына эшли.



Зәңгәр төснең нинди генә төсмерләре юк монда!

ярдагы кыяларга бәреп ваклаган һәм шул рәвешле кара ком барлыкка килгән.

Кемдер әле хәтерли дә торгандыр, Исландиянең Эйяфьятлайокудль (бу атаманы әйтергә тырышып та карамадым!) вулканы әле 2010 елда гына үзен дөньяга танытты. Ул ату сәбәпле, кыска вакыт эчендә күккә вулкан көле күтәрелеп, берничә көнгә Аурупадагы 100 меңнән артык авиарейс очышын туктаткан иде. Ләкин җирле халык һәрнәрсәнең уңай ягын таба, хәзерге көндә шушы вулканнарга туристлар өчен махсус экскурсияләр оештырыла. Экстрим сөюче меңләгән кеше уяу вулкан кратерына төшеп, янартаулар белән «якыннан таныша» ала. Утрауның ни өчен ут иле дип аталуын чын-чынлап менә кайда аңлыйсың!

III

Без исә үз чиратыбызда Рейкьявиктан утрауның көнчыгышына таба юнәлдек. Исландиягә килгән һәр сәяхәтче танышырга тиеш булган «Алтын боҗра» (Голден ринг) маршруты буенча хәрәкәт иттек. Әлеге «Боҗра»да өч тукталыш ясала: Тингведлир паркы, Гюдльфосс шарлавыгы һәм минем иң яраткан һәм көтеп алган урын – Хёйкадалюр гейзерлар үзәне.

Беренче тукталышыбыз – Тингведлир милли паркы. Дөньядагы иң борынгы парламентларның берсе – Исландия парламентына 930 елда шушында нигез салынган. Биредә күз явын алырлык саф сулы зәңгәр күл җәйрәп ята. Шунда ук тирән ярыклар белән «сызгаланган» кыялар бар. Югарыдан карасаң, аларның еракеракка сузылганын күрәсең. Китап сүзләренә ышансаң, нәкъ менә бу урында Аурупа һәм Америка кыйтгаларының тектоник плитәләре елына 7 мм тизлек белән бер-береннән ерагая икән. Монда йөреп алганнан соң, юлыбызны Хёйкадалюр гейзерлар үзәненә таба дәвам итәбез. Гейзерлар – утрауга алып килгән хыялларымның иң беренче һәм иң төп сәбәбе! Әле бит алар, матур итеп һава шарлары чыгарып, ара-тирә «уфылдап» та алалар. (Күрәсең, география дәресләренең миңа ниндидер тәэсире булгандыр инде.)

Хёйкадалюр гейзерлар үзәненең иң башында һәр килгән кунакны танылган Geysir гейзеры каршы ала. (Нәкъ менә аның исеме белән дөньядагы башка кайнар чыганакларны атый башлаганнар да инде!) Бер-бер артлы җирдән кайнар пар күтәрелә. Йөзләгән вак чыганаклар бер-берсе белән кисешеп ага. Кайберләренә, суның температурасын язып, кисәтү тамгалары да куйганнар. Монда туристлар өчен шактый уңайлы шартлар тудырылган: билгеле бер маршрут буенча агач басма салынган, әлеге матурлыкка озаграк хозурланырга теләүчеләргә утыргычлар да куелган. Ерак түгел бер урында шактый күп халык җыелган: 2-3, ә кайчакта 5-10 минутка бер ата торган иң зур гейзерның уянуын көтәләр икән.

Без дә шул якка юнәлдек. Гейзерның һәр ягын карап, һәр тарафында фотога, видеога төшеп, тәмам сокланганнан соң, әле һаман монда килүебезгә ышанып бетә алмый торабыз. Менә бит, янәсе, дөньяда ни генә юк!

Әлеге хисләрне мин Хверир геотермаль үзәнендә булганда кабат тойдым. Монда инде җир чынлап та Марстагы кебек – җирән төстә. Хисләнгән арада, сулыш алуны гына бераз чамаларга кирәк, чөнки тирә-як күкерт исе белән уратып алынган.

«Алтын боҗра»ның соңгы тукталышы – Гюдльфосс шарлавыгы. Исландиялеләр фикеренчә, бу – утраудагы





иң матур шарлавык. Ә утрауда шарлавыклар бихисап: без инде анысын соңрак аңладык. Тик менә монысы иң күп сулысы икән.

IV

Исландия шәһәрләре (аларны шәһәр диюдән бигрәк, торак пунктлар дип атасаң, күпкә дөресрәк булыр иде), нигездә, яр буенда урнашкан. Гади машиналар уза алырлык юллар да шушы шәһәрләр аша бара. Җирле халык белән аралаштык дип әйтә алмыйм, чөнки аларны шушы шәһәрләрдә, кибетләргә туктаган арада гына күрә алдык. Анда да ялгышмаган булуыбыз икеле, чөнки, әйткәнемчә, җәйге чорда бирегә күпсанлы туристлар килә. Бу абзый яки апа турист түгел, ә викинг дип әйтеп кара син!

Менә бу шәһәрләр аша бара торган юл гына аз булып тоела икән, утрауның «урта»сына узарга теләүчеләргә махсус машиналар яки очкычлар ялларга туры киләчәк. Билгеле, анда бөтенләй кеше аягы басмаган җирләргә дә юлыгырга мөмкин. Тик шунысын ышандырып әйтә алам: яхшы юллар аша узып та утрауның күп кенә истәлекле урыннары белән танышырга мөмкин. Мәсәлән, шундыйларның берсе – Айс Лагун (ягъни «бозлы диңгез култыгы»). Бу урында бозларның хәрәкәтенә таң каласың. Исландия – Аурупадагы иң эре бозлыклар иле. Утрауның 10 проценты боз белән капланган. Айс Лагунда йөзеп йөргән бозлар – Вахтнайёкудль бозлыгының аерылып төшкән өлешләре. Алар, әреп, океанга таба агалар. Бу – үзенә бер сихри манзара. Вакыт агышын, тормыш үзгәрешен хәтерләтә... Сихерләнгәндәй басып карап торасың. Салкын булса да, нигәдер үзенә тарта... Бозларның океанга агып төшкән урыны култык хасил итә.

Култыкка океаннан балыклар да «адашып» керә. Мондагы күпсанлы акчарлаклар шул балыкларны аулый. Яр буенда кошларның үз территориясе бар, ул хәтта махсус билгеләнеп тә куелган. Анда ялгыш та аяк басам димә: дистәләгән кош шунда ук үз ояларын яклап, һөҗүм итә, баш түбәңне чукый башлый.

Тупиклар, мөгаен, дөньядагы иң кызык кошларның берседер.

Утраудагы кошлар турында сөйләгәндә, канатлы дусларның тагын берсен искә алмый мөмкин түгел. Бу кошларны латинча «арктика монахлары» дип атыйлар. Инглизчә – «паффин», русча «тупик» дип йөртәләр. Алар Атлантик океанның төньяк утрауларында яши. Шул исәптән, Исландиянең берничә җирендә биек кыялар арасында көн күрәләр. Тупикларны фотога төшерү өчен, туристлар өчен аерым турлар да оештырыла.

Тупиклар кош базарларында яши. «Кош базары» дип кошларның колонияләрен атыйлар. Аларда моногамия киң таралган: ике кош гомер буе бергә тормыш итә ала. Ата кош ана кошны үзенә пар итеп аласы килсә, башта аңа балык ашатып карый. Ул шулай итеп ана кошка игътибарын һәм балаларын ашатырлык сәләте барлыгын күрсәтә икән.

Миңа бу кошлар нәни пингвиннарны хәтерләтте!

P. S. Исландия турында язу бераз катлаулы, чөнки ул күптөрле һәм аннан алган тәэсирләр дә күп һәм төрле, йөгәнләп, тәртәгә салам димә. Булмый! Бу ил турында күп язылган, фильмнар, өстәмә мәгълүматлар да бихисап. Ләкин укып та, карап та, хәтта барып күреп тә аны әле тулысынча үзем өчен ачтым дип әйтә алмыйм. Гәрчә дүрт көн эчендә гомеремдә күрмәгән нәрсәләрне күреп, яңа тәэсирләрдән тәмам арып, «әлегә җитте» кебек тоелса да, шушы кечкенә генә илнең дә ачылмаган сәхифәләре бихисап калды!

PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Кешенең күңелен күтәрү өчен әллә ни күп тә кирәкми. Подъездан чыкканда күршеңнең бер елмаеп сәламләве, транспортка кергәч, кондукторның бер ягымлы сүзе җитә кайчак.

Беркөнне трамвайда эшкә барам. Халык күп, керәләр, чыгалар... Юлны яратам мин, үз дөньяңа чумып, рәхәтләнеп уйланып барасың. Әмма бу юлы үз кабыгыма кереп качарлык булмады. «Яңа кергән пассажирлар! Әле сезнең белән исәнләшмәдек бит. Барыгызга да хәерле иртә!» – дигән ягымлы тавыш ишетелде. Халык җанланды, ягымлы тавыш иясенең үзен күрергә теләп, башлар уңга-сулга боргаланды. Кара син, кондуктор икән! Гадәттә, кондукторлар алҗыган була, билетка тиешле акчаңны бирсәң, башкасы аны кызыксындырмый. Ә бу кондуктордан ниндидер уңай энергия бөркелә иде. Берәүгә дә битараф түгел тагын үзе. Һәркемгә дә үз итеп – елмаеп карый. «Эчкәрәк узыгыз әле, ягез-ягез! Әнә анда урын бушрак!» Ишек янына өелешкән яшь-җилкенчәк, аның әмеренә буйсынып, эчкәрәк уза. Таягына таянып, трамвай баскычыннан көчкә менеп барган әнә теге апага да ярдәм кулын сузарга өлгерә. «Апа, монда килегез, менә бу егет урын бирер сезгә». Бу дөньяда бер гаме дә юк шикелле, ваемсыз гына урындыкка чүмәшкән озын чәчле егеткә ягымлы итеп ике генә тылсымлы сүз әйтә: тәрәзә буендагы җылы, уңайлы урында хәзер типсә тимер өзәрдәй егет түгел, ап-ак тузганакны хәтерләткән теге апа утырып бара. Тамаша карагандай, кондукторны күзәтәм. Шушы – күп булса биш-алты тукталыш арасы бергә барган халыкны бер-берсенә якынайтты димме соң, һәрхәлдә, кешеләр бер-берләренә игътибарлырак булгандай тоелды.

Киләсе тукталышта миңа инде төшәсе. Баскан урынымнан кузгалып, ишеккә якынрак килдем. Трамвайга олы яшьтәге ябык кына бабай керде. Бу юлы, кондукторның әйткәнен дә көтми, сикереп торып аңа урын бирделәр. Бабай, кесәсеннән кечкенә төенчек чыгарып, калтыранган куллары белән тиеннәр барлады. «Әллә үзем түлим микән?» – дигән уй йөгереп узды. Кыймадым. Өлкән яшьтә булса да, ир кеше бит, түбәнсетүдән курыктым. Ул арада салонның аргы башыннан кондуктор да әйләнеп килде. Бабайның тиеннәрен кысып тоткан кулын үзенең ике учына алды да: «Сез түлисен инде түләгән. Билет өчен акча алмыйм, кечкенә генә бүләгем дип кабул итегез!» – диде. Шулкадәр күңелем тулды аның бу сүзләреннән.

Мин инде үз тукталышыма килеп җиткән идем. Көне буе шул кондукторны уйлап йөрдем... Бик яшь тә түгел үзе. Яшьлегендә, мөгаен, укытучы яки тәрбияче булгандыр... Пенсиясе яшәренә җитмәгәнгә чыкты микән кондуктор булып, әллә инде кешеләргә биреп бетерәсе яратуы, җан җылысы булгангамы?..

Миләүшә ШАКИРОВА.
Казан.

Тормыш иптәшем Мәрьям белән 70 елдан артык бергә без. Икебезгә дә быел 90 яшь тула. Әти ягыннан да, әни ягыннан да бик борынгы морзалар нәселенә – Богдановларга барып тоташа безнең ыру. Шәҗәрәләр белән мавыгам.

Без «Азат хатын»–«Сөембикә» журналын 1970 елдан бирле алдырабыз. Электән үк журналларны күп алдырсак та, «Сөембикә» журналыннан да яхшысын очраткан булмады.

Журналның 2017 елның октябрь аенда Эльмира Закированың «Чишмә җыры» (бер җыр тарихы) дигән язмасын укыгач, бик күп еллар элек үткән вакыйгалар искә төште. Сезгә шул турыда язмакчы булам. Ул язмада Ясәви Хөсәенов һәм Сара апа Садыйкова искә алына.

Ясәви абый белән без 1984 елның маенда беренче мәртәбә Дәүләкән районы Имай-Карамалы авылында очраштык. (Мин үзем шул авылда туып-үстем.) Әнием белән бертуган Шәйдулла абзый белән Ясәви абый 1943 елның кышында Карелия фронтында бергә булганнар. Очрашуга әнә шул уртак язмыш сәбәпче.

Командование Шәйдулла абзый отделениесен разведкага җибәрә. Разведкага элемтәче Ясәви абый да бара. Бу очрашу турында «Советская Татария» газетасы (1984 ел, 8 июнь) «Встреча через сорок лет» дип язып та чыга. Эчтәлеге болайрак:

«...Карелия фронтында сугышлар кызган чакта, десантчыларга дошманнан «тел» алып кайтырга дигән сугышчан бурыч куела. Сержант Солтанаев җитәкчелегендә җиде сугышчы, билгеләнгән урынга яшеренеп кенә үтеп, маскировкаланган танкларны, артиллерияне абайлап ала. Кыйммәтле мәгълүматлар җиткерәсе «тел»не дә кулга төшерәләр. Разведчиклар кайтыр юлга борылгач кына, аларны дошман дозоры күреп ала. Кул сугышы башлана. Шәйдулла Солтанаев һәм аның сугышчылары, дошманнарны кырып, алга шуыша. Югалтулар да була. Дошман пулясы Солтанаевны да яралый. Командирның аңын җуеп егыла баруын күргән рядовой Хөсәенов, Шәйдулланы чаңгыга яткырып, үзебезнең гаскәрләр ягына алып кайта».

Әнә шулай үзенең командирын үлемнән коткара ул. Шуннан соң юллар аерыла. Шәйдулла Солтанаев, госпитальләрдә дәваланганнан соң, кабат фронтка китә. Ә аның ярасы бик каты була. Бер пуля кендек астыннан кереп, умыртка сөяге кырыннан үтеп чыга, икенчесе янбаш сөягенә кереп туктый. Ул пуляны Шәйдулла абзый үзе белән алып кайткан иде. Операция ясаган врач Бүздәк районыныкы булып чыга – пуляны Шәйдулла абзыйның кулына тоттыра. Сугыш бетәргә ике ай калганда, мина кыйпылчыгы эләгеп, тездән түбән аягы да бик каты яралана. Госпитальдә дүрт ай ятып, ике култык таягы белән кайтып төшә авылына...

Шактый еллар узгач, ике фронтовикның очрашуы үзе бер вакыйга була. Шәйдулла абзый Казан радиосын бик яратып тыңлый иде. Бер тапшыруда Миңнеәхмәтясәви абыйга мактаулы исем бирелү турында ишетеп кала да, «полкташым Ясәви түгелме икән?» дип уйлап куя. Икенче көнне үк Актаныш райкомына хат язып җибәрә.

Ясәви абыйның сөйләве буенча, язгы чәчүнең кызган вакыты була бу. «Чәчү барышы белән танышып йөри идем, конторадан бер егетне мине алырга җибәргәннәр. «Срочно райкомга чакыралар сезне. Тиз арада килеп җитәргә куштылар», – ди. Барып кердем. Райком секретареның: «Шәйдулла Солтанаевны беләсезме?» – дип соравына шаккатып калдым, чөнки аның ул ярасы белән исән калуы икеле иде. «Минем командирым иде ул», – дидем. Булган хәлләрне сөйләп биргәч, Шәйдулла Солтанаевның хатын тоттырды. Ә икенче көнне командирым безнең авылга ук килеп җитте».

Шул вакыттан соң гомер ахырына кадәр гел аралашып яшәде алар. Бер килүендә Сара апа Садыйкова турында да искә алды, безнең авылга килеп, ял итеп китә иде, дип сөйләгән иде. Миңнеәхмәтясәви абый киң күңелле, мәрхәмәтле, башкаларга ярдәмчел кеше булып хәтердә калган. Аларны очраштырып йөрүче фотохәбәрче Мидхәт Шакирҗанов белән язучы Мәхмүт Хәсән (фамилиясе җуелган, Хәсән йә Хөсәен булырга мөмкин) бу очрашу турында күп газеталарда язып чыктылар, фронтовикларның фотоларын бирделәр. 1985 елда «Азат хатын»да да «Еллар үткәч» дигән мәкалә күренә, Шәйдулла абзый белән Әминә җиңгинең фотолары да урнаштырыла. 1971 елда журналда Асия Хәсәнованың «Штурман» дигән язмасы чыккач, Башкортстанда яшәүче берәү: «Хәзер исәнме ул? Сугыштан соңгы язмышы ничек булган?» – дип кызыксынган. Күрәмсең, шуңа җавап рәвешендә чыккан инде ул.

Шәйдулла абзый 1994 елда вафат булды, ә Ясәви абый аңардан алданрак китеп барган...

Мөкаддәс ХӘБИБУЛЛИН.
Башкортстан. Уфа.

Кеше бәхетсезлегендә бәхет төзеп булмый дигәнгә гомер иткән саен ныграк инанасың икән. Ачы күз яшьләренә чыланган бәхет үзе дә ачы була.

Гөлниса белән Таһирның тормышы күз алдымда булды (исемнәр үзгәртелде). Ике кыз үстерделәр. Бәхетле, үрнәк гаилә иде алар. Таһир автомеханик, Гөлниса аш пешерүче булып эшләде. Үзләре яшәгән район үзәгенең Мәдәният йорты сәхнәсендә Таһир гармунда уйнап, Гөлниса өздереп җырлаганда аларга карап кемдер сокланган, кемдер яшерен генә көнләшкәндер дә... Аларның мәхәббәтләре мәңгелек шикелле иде.

...Ул елны Таһирны кайсыдыр бер колхозга уңыш җыярга җибәрделәр. Авыл белән район арасы ерак булса да, гаиләсе янына еш кайтырга тырышты ул. Әмма тора-бара кайтулары сирәгәйде. «Тизрәк җыеп бетерәсе бар дип тырышалардыр... Вакыты юктыр... Җае чыкмыйдыр...» Гөлниса үзен ничек тә тынычландырырга, күңеленә вәсвәсә кертмәскә тырышты.

Тик өзелеп көткән ир кайтмады... Медпунктта эшләгән Гөлиягә йортка кергән, дигән хәбәре генә кайтып ирешә. Үзеннән 18 яшькә яшьрәк иде икенче хатыны. Гомер уртасына якынлашкан ирнең башын тәмам әйләндергән икән. Яшь, сылу тәннән сихерләнгән ир үзен өзелеп көткән ике кызын, сөекле хатынын бөтенләй оныта. Ул арада яшь хатын балага да узып куя.

Иренең хыянәтен ишеткән Гөлниса җирләр тырнап елады. «Әни, әйдә, ул хатынны барып кыйныйбыз да әтине бәйләп алып кайтабыз», – дигән иде кызлары. Андый түбәнлеккә төшмәде Гөлниса. Ялынып та бармады, үч алу җаен да эзләмәде. Күңеле ирен көтеп өзгәләнгәндер, ятимлек ачылары йөрәген өткәндер, әмма ул үз дәрәҗәсен төшермәде.

Ә Таһир яңа гаиләдә башаяк белән эшкә чумды. Гөлия әнисе белән генә яши иде. Хуҗалыклары ир-ат кулын бик тә тансыклаган. Инде малай да тугач, яшь хатын ирен яңа йорт салырга күндерде. Кредитка батып булса да, хатынының теләгән үтәде Таһир. Бигрәк тә назлы, бигрәк тә мут иде шул Гөлия. Үз сүзен сүз иттерә белә иде.

Алар шулай тыныч кына яшәгән дә булыр иде... Гөлия хакында ямьсез сүз тарала. Сылу ханымга баш табибның күзе төшкән, мәхәббәт учаклары инде шактыйдан ук үрли икән. 55 яшен тутырган ирнең үзе салган йортын хатынына калдырып чыгып китми чарасы калмый.

Кайчандыр йөрәген яралап, үзләрен язмыш кочагына ташлап калдырган иренең анда сугылып, монда кагылып йөрүен ишетеп, бик кызгана Гөлниса. Андый түбәнлеккә төшә торган кеше идемени ул?!

Теге вакытта, аңлатмый-нитми барысын да чәлпәрәмә китергәндә, бәхетебезне шулай бер селтәүдә юк итеп буламыни, аңына килер, кайтыр, гафу үтенер, дип тилмереп көткән ире 12 елдан соң кабат шакый аның ишеген. «Булдыра алсаң, гафу ит». Кабул итә аны Гөлниса, тик кызлары гына... Алар елаганда шатланып көлгән, алар ачынганда сөенечтән балкыган бу кешегә «әти» дип әйтәселәре килерме?..

Фәризә ГАЛӘВЕТДИНОВА.
Чирмешән районы,
Ибрай-Каргалы авылы.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU

16+

УЛ БИТ ХАТЫН-КЫЗ!



Айдар ГАЛИМОВ,
Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты, Башкортстанның Дәүләт Җыелышы-Корылтае депутаты.
гаилә стажы – 29 ел;
өч бала (Гүзәл, Айгизә, Данияр) атасы.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Боларның барысына да һәм тагын әле тавышына да игътибар итәмдер. Анысы да минем өчен мөһим. Тик шунысы кызганыч, соңгы вакытта хатын-кызлар барысы да бер-берсенә охшый башлады. Бигрәк тә – яшьләр. Аларның һәммәсендә дә эшләнгән керфекләр, кашлар, тырнакны әйтмим дә инде... Хәтта эшләнгән иреннәр! Кайда табигый чын матурлык, кайда ясалма – аеру да авыр хәзер. Дөресен әйткәндә, бу күренеш куркыта...

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Аңа – хатын-кызга гына хас булган барлык сыйфатларын да гафу итәргә була, минемчә. Әйтик, логик яктан кайчак ялгышуларын. Хәер, аны җитешсезлек дип тә булмыйдыр... «И-и, ярар, хатын-кыз бит инде ул», – дисең дә, уздырып җибәрәсең.

3 Ир кеше өчен хатыны аңа дус та була аламы?

– Миңа калса, ул дус булырга тиеш тә. (Һәрхәлдә, беркем беркемгә берни тиеш булмаса да!) Дуслык – ул зур нәрсә. Мин моны бергә яшәгән еллары шактый җыелган кеше буларак әйтәм. Еллар узу белән ниндидер хисләр азрак тоныкланырга да мөмкин. Ә дус була белү, яши-яши, бәлки, беренче планга ук та чыгадыр әле. Тик бөтен кеше дә дус була алмый.

4 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Бик күптән булды бит инде ул, хәтерләмәсәм дә гаеп түгелдер... Без Зилә белән Уфа автотранспорт техникумында бергә укыдык. Үзешчән сәнгатькә зур игътибар бирелә иде бездә – мин инде, әлбәттә, сәхнәдән төшмим. Зилә дә җырга мөкиббән киткән кеше – бер бәйрәмдә оештырылган концертта сәхнәгә ул да чыкты. Шулай таныштык...

Ул мине армиягә озатып калды. Ә аннан, күрергә дип, яныма килде! Литвага кадәр! Балтыйк буе ул чакта да барыбер чит ил кебек иде бит. Аның киләсен белми идем, әлбәттә. Өйрәнүләр вакыты иде. Бер лейтенант: «А ты знаешь, что к тебе девушка приехала?» – ди. Ышанмадым! Булмас дим! Бергә үткәргән һәр мизгеле истә ул чакның... Армиядән кайткач, озак очрашып йөрмәдек инде, өйләнештек. Тәкъдим ясау ничек булды икән? Безнең вакытта бүгенгеләр кебек мөгез чыгарулар юк иде бит әле. Хәзер әнә тәкъдим ясауны шоуга әйләндерәләр.

Читкә киттем. Зилә – Урал аръягыннан, таулар артыннан, ә мин Башкортстанның бөтенләй башка ягыннан. Әти белән әни барып кызны сорап кайтты. Ул чакта туй – башта бер якта, аннан икенче якта уза иде. Икешәр көн! Борынгылар зирәк булган шул: икешәр көн туй уздыру күңел ачу өчен генә булмаган бит. Ике як бер-берсен шунда белеп калган. Кайчакта, башка күрешмәсәләр дә, бер-берсен хәтерләп, сәламнәр әйтешеп яшәгәннәр. Шөкер, без шуларны үткәнбез.

5 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Шунда ук «Москва слезам не верит» киносы искә төште әле. Екатеринаның генераль директор булуын белгәч, Гоша-Георгий (А. Баталов) бөтенләй өйдән үк чыгып китә бит. Безнең менталитет турында сөйли инде бу. Чит илдә моңа, бәлки, гадәти күренеш дип кенә карарлар, игътибар да итмәсләр иде...

Хатыннары күбрәк мал тапкан гаиләләр танышларым арасында да бар. Ир-атка моны тыныч кына кабул итәргә кирәк. «О-о, син миннән күбрәк аласың!» – дип, күтәрелеп-бәрелеп чыгып китә торган заман түгел хәзер. Киресенчә, бәлки моңа эчтән генә шатланып торыргадыр? Әмма үзеңнең ир-ат буларак горурлыгыңны да югалтмаска инде. Андый хатын-кызны ничектер тотып та тора белергә кирәк әле. Егәрсез булмый!

6 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Без элеккерәк заман кешеләредер инде – моның белән бик үк килешеп бетә алмыйм. Беренче адымны ир-ат ясарга, беренче булып ул эндәшергә тиеш кебек. Әмма гаепли дә алмыйм. Дөнья үзгәрә, хатын-кызлар да икенче хәзер. Алар үзләренә ни кирәген яхшырак белә.

7 Хатын-кызлардан үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүен көтәсез?

– Матур прическа, матур костюм, матур күзләр, матур җырлардан гына торган образ түгел, ә кеше күрүләрен телим. Өстен яклары, кимчелекләре булган шундый ук кеше... Ир-ат буларак ныклыгымны, ышанычлы икәнемне. Хуҗалыкчыл булуыма да игътибар итсеннәр иде.

8 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Тормыштан беләм: үзе бик чибәр дә булган, уңышка да ирешкән, әмма кияүгә чыкмаган хатын-кызлар бар. Алар матур киенгән, чәч-башлары ясалган. Читтән караганда, гади егетләргә буй җитмәслек булып күренәләр. Андыйлардан егетләр, чыннан да, курка. «Юк, бу кыз беркайчан миңа карамас, мин аңа лаек түгел», – диләр. Ир-ат барыбер кыюсызрак ул. Бигрәк тә бүгенге заманда. Ә әрсезләр кайсы заманда да бар, әлбәттә...

9 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңлаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Бар андый бер очрак! Безнең өлкәдә эшләүче бер хатын-кыз: «Урамда ач калсам да, бу команда, бу кешеләр белән беркайчан эшләмәячәкмен», – дигән иде берсендә. Мин сорамадым – үзе әйтте. Тик шул командадан тәкъдим булу белән, ул алар белән китте дә барды!

10 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– Элек яшьлегем белән үз туксанымны туксан иткән: «Минемчә булырга тиеш», – дигән чаклар да бар иде. Хәзер инде аңлыйм, бу алымны хатын-кызга карата кулланып булмый. Иң яхшысы – тыңлап торырга да эндәшмәскә... Барысы да соңыннан әкренләп үз урынына утырачак. Күтәрелеп бәрелеп, үз дөреслегеңне исбатлый башлаудан берни үзгәрмәячәк.

11 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Сез нишлисез инде? Кафега чыгып китәсез яки пиццага заказ бирәсез? Тиз генә үзегез берәр нәрсә пешерәсез?

– Берсе дә туры килми! Башта бөтен төс-кыяфәтем белән канәгать булмавымны күрсәтәм инде. Яшерергә тырышсам да, йөземә чыгачак, һәм Зилә моны бик тиз тоячак. Аннары инде бер дә ятып тормаячак... Юк, андый хәл берничек була алмый! Зилә үзенең алиһә дә, комфорт та тудыручы хатын-кыз икәнен күптән күрсәтте инде. Гомергә шулай булды – 29 ел буена. Хәзер генә үзгәрмәс.

Ә үзем пешерүгә килгәндә... Беркайчан да болай дип мактана алмадым. Әмма мондый хыялым бар: кайчан да булса берәр нәрсә пешерергә өйрәнермен дип уйлыйм. «ТМТV» каналының «Тәмле көрәш» тапшыруында катнашырга чакырдылар күптән түгел. «Тамашачыларны өйрәтә алмыйм, үзем өйрәнергә барсам гына», – дидем Булат Бәйрәмовка. Күп нәрсәне хәтерләп калдым болай, ләкин тапшыру чыккач, тагын бер тапкыр җентекләп карыйм әле – аннары шәт өйдә дә пешерермен. Дуслар, тапшыруны күреп: «Пешереп, безне дә сыйла әле», – дип сорамасалар ярар иде, дип куркып торам менә.

12 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан.

– Дөресен әйтимме? Оят булса да, үземнең тагын бер кимчелегемне ачам инде. Иҗат кешесе шул мин – башаягым белән! Еш кына Зилә, әзерләнеп, ишек төбендә басып тора, ә мин әле киенеп тә бетмәгән булам. Ул моңа ничек түзәдер, анысын белмим. Әлеге дә баягы, халык алдындагы – гел игътибар үзәгендәге кеше бит мин – теләсә ничек йөрергә хакым юк. Аларның күз алдында – гел синең сәхнәдәге (тышлыктагы, экрандагы) образың. «Син бит шул егет, ничек инде пима кия аласың? Бүрегең кыек...» – дип карый алар. Бик сирәк кенә – дуслар арасында гына шулай йөреп була. Дусларым янында – мин аларның берсе. Рәхәт моны тою...

13 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша...

– Мин матур күлмәкләр кияргә яратам – башкаларныкыннан аерылып торганны. Зилә бу хакта белә, әлбәттә. Кайчак киеп-киеп карап та, үземә туры килгәнен таба алмыйм. Кайсының җиңе кыска, кайсының якасы зур... Тегүче генә сиңа чаклап тегә ала, ә кибеттә сайлау... Зиләнең ничә тапкыр миңа нәкъ туры китереп күлмәк алганы бар. Киям дә башка салмыйм. Ничекләр шулай ала белә, шаккатам.

Мин аңа чәчәкләр бүләк итәм дисәм... Бик еш кына концертлардан да чәчәкләр белән кайтам бит. Кайчак Зилә, ятыр алдыннан, чәчәкләрне утыртырга вазалар әзерләп калдырган була. Ә минем бер букетсыз да кайтып кергән көннәрем бар. Моның сәбәбе үземдә. «Туганнар, инде ничә еллар чәчәкләр бүләк итәсез, рәхмәт, – дигәнем булды сәхнәдән. – Тик, әйдәгез, бергәләп бер изге эш эшлик әле...» Хәзер миңа чәчәк түгел, ә уенчыклар, китаплар бүләк итәләр. Аннан аларны мин балалар йортларына таратам. Казан тамашачысы да бу үтенечемне һаман хәтерли. Әмма үзем уйлап чыгарган яңалык түгел бу. Танышларым – Англиядә бергә укыган Уфа егете белән Минск кызы – үзләренең туйлары алдыннан: «Кадерле кунаклар! Мөмкин булса, чәчәк бәйләмнәре урынына безгә бала уенчыклары алып килегез – ятимнәрне бергәләп сөендерербез», – дип, хат җибәрделәр. Сокланырлык үрнәк! Бер көнлек матурлык өчен акча түгү түгел инде бу.



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз:
www.syuyumbike.ru

PRESSA.RU



АШЫЙ-АШЫЙ ЯБЫГАБЫЗ

Көннәр язга авышуга, «диетага утырам әле» диюче хатын-кызлар саны геометрик прогрессиядә арта. Диета – ул ризыкны дөрес куллану кагыйдәләре комплексы. Һәм менә нәкъ шушы формадагы диета гәүдәне тәртипкә китерергә, сәламәтлекне яхшыртырга булыша да инде. Бу хакта безгә Казанның 7 нче хастаханәсенең югары категорияле диетологы Юлия КИСЕЛКОВА сөйләде.

Дөрес итеп сайлыйбыз

Зифа буйлы булырга теләгән хатын-кыз азык-төлекне дөрес итеп сайлый белергә тиеш. Төрле калорияле ризыклар бар. Күп калориялеләр: баллы, майлы, камыр ризыклары, алкоголь. Уртача калориялеләр: бәрәңге, ярмалар. Фән телендә соңгыларын «катлаулы углеводлар», диләр. Алар озак эшкәртелә, шул сәбәпле, май катламнарына да тиз генә кереп утырмыйлар. Аз калорияле ризыкларга исә баллы булмаган җиләк-җимешләр, яшелчәләр һәм су керә.

1 килограмм гәүдә авырлыгына 30–40 миллилитр су кереп торырга тиеш. Моңа эчемлекләр, ботка, шулпалар да керә. Чиста суны көнгә 1,5–2 литр эчәргә кирәк дип санала. Ашарга ярты сәгать кала ноль калорияле бер стакан су эчеп куйсаң, күп итеп ашый алмыйсың.

Организмга кирәкле тагын бер матдә бар: ул – клетчатка. Клетчаткага ярма, җиләк-җимеш, яшелчә һәм көрпә (отруби) бай. Үзен генә ашасаң, көрпә ашказанын җәрәхәтләргә мөмкин, шуңа аны боткага, кефирга, катыкка кушып ашарга киңәш ителә. Ул ризыкның организмга май булып сеңүен тоткарлый, эчәклекнең вакытында бушануын тәэмин итә, микрофлораны яхшырта.

Туклану режимын көйлибез

Табигатьтә энергия саклану законы бар. Аның буенча, ябыгырга теләгән кешенең ашаган калориясе тотылган калориясеннән азрак булырга тиеш. Һәр очрак та индивидуаль, ләкин диетологиядә кабул ителгән мәгълүм стандартлар бар. Әйтик, уртача авырлыктагы (70 кг) хатын-кызга, ябыгу өчен, тәүлек буена ашый торган калорияләре 1000 нән артмаска тиеш. Сәламәт яшәү рәвеше алып баручы гадәти кеше көнгә 2000–2400 калория ашаса, ябыкканда бу норманы яртылаш киметәбез. Туклану рационының калориягә иң бай өлеше иртәнге ашка туры килергә тиеш, чөнки без күбрәк көндез хәрәкәтләнәбез. Әгәр без кичке ашка күп калория ашыйбыз икән, ул тотылып бетмәячәк (сүз кичен тренировкаларга йөрүчеләргә кагылмый). Ашау арасындагы тәнәфес өч сәгатьтән дә озаграк булмасын. Капкалап алу өчен сумкаңда алма, кефир, чикләвек, шешәле су йөртү кыен түгел.

Кайберәүләр ризыкны чикли торган диетада утырып, бераз ябыккач, кире гадәти режимга кайта һәм югалткан авырлыгын кабат җыя. Ашау белән болай «уйнау» аркасында организм шок халәтендә булып, запаска май туплый башлый. Калорияләрне кисәк киметергә ярамый. Организмга яңа рационга иялләшү өчен ике атна кирәк.

Дөрес итеп эшкәртәбез

Кешегә көненә 30 грамм атланмай һәм 20 грамм үсемлек мае кирәк. Аның кадәр генә майны без табигый ризыкларда да ала алабыз. Мәсәлән, үсемлек мае чикләвектә бар. Балык та майга бай.

ДӨРЕС МЕНЮ ҮРНӘГЕ

Иртәнге аш

Уянгач, ашарга ярты сәгать кала, бер стакан су эчәбез. Ашау барышында су эчмәскә тырышабыз. Ашаганнан соң ярты сәгать узгач эчеп куябыз. Иртән катлаулы углеводка бай ризык ашыйбыз:

- ботка (ябыгу өчен дөге белән манный боткасыннан тыелып торырга кирәк);
- ипи кисәге;
- атланмайның көнлек нормасын йә боткага салабыз, йә ипигә ягып бутерброд ясыйбыз.

Аксымга бай ризыклар да кертеп җибәрәбез: йомырка, эремчек.

Чәй, кофены да иртәнге якта эчәбез. Ләкин иртәнге аштан соң, кимендә ярты сәгать узган булырга тиеш.

Икенче иртәнге аш

Беренче иртәнге ашның 5–10 проценты күләмендә була. Мәсәлән, алма яки гөлҗимеш компоты эчеп куярга, берәр җиләк-җимеш ашарга мөмкин.

Төшке аш

(ризыклар 100–150 граммнан артмасын)

- яшелчә салаты;
- беренчегә – җиңелчә яшелчә ашы, ә гарниргa – бәрәңге боламыгы йә ботка белән котлет, парда пешкән тавык ите яки
- беренчегә – ярмалы аш, ә гарниргa томалап пешерелгән яшелчә белән ит кисәге;
- кипкән җиләк-җимештән эчемлек.

Төштән соң ашап алу

җиләк-җимеш салаты яки йогырт/кефир.

Кичке аш

Аксымга бай ризык, ягъни ит ашыйбыз:

- томалап пешерелгән яшелчә белән күркә ите яки
- җиңелчә салат белән тавык ите.

Бәрәңге, токмач, ботка кебек ризыкларны кичен ашамыйбыз, чөнки алар таркалып бетәргә өлгерми. Ипи ашарга ярый. Эчәргә җимешләрдән мусс яки компот әзерләргә мөмкин.

Тоз исә 10 граммнан да күбрәк киңәш ителми. Шикәрне сәламәт кешегә – 50, ашкайнату тракты авырулары булганда 30 граммнан арттырмаска, дибез. Бөтенләй балсыз булмый. Ләкин ул торт, печенье конфет рәвешендә булмасын. Кипкән җиләк-җимеш куллану файдалы.

Организмга бер-ике шакмак чын шоколад та (составында какао 70 проценттан да ким булмаганы) кирәк. Ул баш мие эшчәнлеген яхшырта, картаюдан саклый. Ә үзе баллы, үзе файдалы продукт дип, әлбәттә инде, балны әйтәбез.

Безнең организм аксымнан төзелә. Аксым дүрт сәгать эшкәртелә, шуңа күрә аксымлы ризык ашагач, озак вакыт тамак ачмый. Мәскәү белгечләре кеше организмына иттә генә була торган аксым кирәклеген ачыклаган. Алар сыер итен аеруча файдалы дип аерып күрсәтә.

Диетологларның төп кагыйдәсе болай: бөтен нәрсәне дә ашарга була, тик чамасын белеп кенә. Әйтик, инде ничә көннән бирле торт ашау турында хыялланып йөрисең икән, ашап куй син ул торт кисәген (тик иртәнге якта!). Аша да күңелеңне тынычландыр, чөнки сәламәтлеккә, гәүдә төзелешенә эмоциональ халәт тә зур йогынты ясый. Үзебезне нәрсәдән дә булса чикләсәк, стресс барлыкка килә, ул матдәләр алмашын боза. Ә эштә, көндәлек тормышта тупланган стрессны торт кисәге белән түгел, спорт белән җиңәргә өйрәнегез. Төз гәүдәле, сәламәт буласыгыз килсә, дөрес туклану яшәү рәвешенә әйләнергә, актив хәрәкәтләнү (йоклар алдыннан бер сәгать җәяү йөреп керү кыен түгел бит!) һәм стрессны җиңә белү гадәткә керергә тиеш.

Фәнзилә МОСТАФИНА әзерләде.

МИФ #1

ГӘҮДӘ АВЫРЛЫГЫ АРТУ БЕРЕНЧЕ ЧИРАТТА НӘСЕЛДӘНЛЕККӘ БӘЙЛЕ



Гәүдә авырлыгына нәселдәнлекнең йогынтысы бар. Күп ашап та тазармый торган һәм бик аз ашап та авырлык җыя торган кешеләр була. Беренчеләренең организмында матдәләр алмашы тиз бара, димәк. Бу үзлек тә нәселдән күчә. Ләкин артык авырлык җыюны нәселдәнлеккә генә сылтарга ярамый. Энергия саклану законы буенча, ашамаган кеше берничек тә тазара алмый.

ЧЫНБАРЛЫК

МИФ #2

КИЧКЕ АЛТЫДАН СОҢ АШАРГА ЯРАМЫЙ



Кеше төнге икеләрдә генә йокларга ята, ә кичке ашны алтыда ук ашап куя икән, сигез сәгать активлык дәвамында аның тамагы ачачак. Йокларга ятарга 1,5–2 сәгать кала, җиңелчә ризык ашап куярга киңәш ителә. Кичке алтыдан соң ашарга ярамый дигән фикер кичке сигездә ятып йоклаучылар өчен генә файдалы. Ә ябыгучы кешеләргә кичке ашны йокларга ятарга 3–4 сәгать кала ашарга кирәк.

ЧЫНБАРЛЫК

МИФ #3

ИПИ АШАРГА ЯРАМЫЙ, УЛ СИМЕРТӘ



Ипидә файдалы матдәләр бик күп: шул ук клетчатка да, аксым да, безнең нерв системасы өчен бик кирәкле В төркеме витаминнары да. Шуңа күрә иписез булмый. Көнгә берничә телем ипи ашап куярга киңәш ителә. Ә ак ипидә витаминнар азрак, димәк, без буш калорияләр ашыйбыз дигән сүз.

ЧЫНБАРЛЫК

МИФ #4

ДИЕТИК РИЗЫК – УЛ АЗ КАЛОРИЯЛЕ РИЗЫК



Диетик ризык дигәндә, беренче чиратта табигый продуктлар күздә тотыла. Хәзер кибеттә нәрсә генә юк: әллә ничә төрле казылык, соуслар, ярымфабрикатлар һәм башкалар. Ләкин боларның берсе дә агачта да, җирдә дә үсми – аларны кеше ясый. Диетик ризык ашыйбыз дисәк, табигатьтә булганны ашарга кирәк.

ЧЫНБАРЛЫК

МИФ #5

КАЙБЕР РИЗЫКЛАР (МӘСӘЛӘН, АНАНАС, ГРЕЙПФРУТ, СЕЛЬДЕРЕЙ) МАЙ КАТЛАМЫН «ЯНДЫРЫРГА» СӘЛӘТЛЕ




Ананаста матдәләр алмашын тизләтә торган компонентлар барлыгын белгечләр дә ачыклады инде. Ләкин бу атна буе ананас ашап торсаң, май катламың үзеннән-үзе эреп юкка чыга, ябыгасың дигән сүз түгел. Ябыгу – ул комплекслы процесс. Бер генә төрдәге ризык ашап, ябыгып булмый.

ЧЫНБАРЛЫК

МИФ #6

БЕР ГЕНӘ ПРОДУКТТАН ТОРГАН ДИЕТА ТИЗ ЯБЫКТЫРА



Ябыктыруын, ябыктырадыр да, ләкин организм үзенә кирәкле матдәләрне алып бетерми. Шуңа күрә, тиз арада ябыгам, дип, кеше башка органнарына зыян сала. Эшләү сәләте кими, хәлсезлек, стресс барлыкка килә. Әйтик, кефирдан, әчегән сөт бактерияләреннән кала, тагын нәрсә алып була соң? Шунлыктан, диетологлар бер генә продукттан (шул ук кефирдан, мәсәлән) торган «бушану» көнен атнага бер генә тапкыр рөхсәт итә.

ЧЫНБАРЛЫК

PRESSA.RU



Рафаэль ШӘВӘЛИЕВ, Республика клиник балалар хастаханәсенең баш табибы

ЗАМАНА ЧИРЕ

Бүген тормышны гаджетлардан башка күз алдына да китереп булмый – моны барыбыз да аңлыйбыз. Электрон җиһазларның организмга, бигрәк тә бала организмына зыянлы икәнлеген дә беләбез. Идеаль җәмгыятьтә яшәсәк, 8 яше тулмаган балага бернинди гаджет та бирмәс идек. Тик мондый тормыш хыялда гына шул...

Әти-әнисендә, иптәшләрендә, телевизордагы геройлар кулында төрледән-төрле гаджет күреп үскән бала көннәрдән бер көнне үзе дә бу «уенчык»ны сорый. Бөтенләй бирми кала алмасак та, без баланы гаджетны куллану вакытын дөрес итеп билгеләргә өйрәтә алабыз. Башта электрон җиһазларның нинди зыяны барлыгын ачыклап китик.

Гаджетлар электромагнит нурланыш тарата. Ул нурланыш беренче чиратта баланың үзәк нерв системасын ярсыта. Нәтиҗәдә, бала кызып китүчәнгә әйләнә, игътибары кими, хәтере начарая, йокысы бозыла.

Гаджет тотып, кәкрәеп-бөкрәеп утырган баланың гәүдә төзелеше үзгәрә, умыртка баганасы кәкрәя. Гәүдәнең табигый хәле бозылса, бөтен организмга – нерв һәм йөрәк-кан тамыры системаларына, эчке органнарга да зыян килә. Гаджетка бәйле бала вакытында ашамый. Ашказаны-эчәк авырулары килеп чыгарга мөмкин.

Психологлар аңлаешлы сөйләме барлыкка килгәнче, ягъни 3 яше тулганчы балага гаджет бирми торырга куша. Беренчедән, 3 яшькә кадәр үк гаджет белән уйнап үскән баланың сөйләм үсешендә тоткарлыклар күзәтелә. Икенчедән, бармак очлары сизгерлеге чикләнгән була. Телефонда ике бармак белән генә уйнап утырган баланың баш миендә бик аз зоналар гына «эшли», шул рәвешле баш мие бөтенләй ялкаулыкка чыга. Өченчедән, сөйләшә башлаганчы ук гаджетка «кереп киткән» баланың сизү органнары дөрес итеп эшләргә өйрәнми кала.

Бәйлелек барлыкка килмәсен өчен нәрсә эшләргә соң? Беренчедән, гаиләдә әхлакый кыйммәтләр дөрес куелган булса, әти-әни эштән кайткач, гаджетка чумып утыруны түгел, бала белән сөйләшү, бергәләп уйнау, урамда йөрүне сайласа, моны күреп үскән балада да гаджетка дөрес караш формалаша.

Икенчедән, һәр кешенеке кебек үк, баланың да көндәлек ихтыяҗлары була. Шуларны канәгатьләндерсә – ул бәхетле, аңа бернинди гаджет та кирәкми. Әйтик, баланың кадак кагып карыйсы килә, ди. Әни кеше нишли? «Юк, юк, бармагыңа сугасың, аягыңа төшерәсең», – дип, чүкечне тартып ала. Моны эшләмә, тегене эшләмә, дип тукып тора. Шуннан бала гаджетка үрелә – әһә, монда тынычлап уйнарга була, әни кысылмый. Бу тормышта канәгатьләндерә алмаган ихтыяҗларын бала шул рәвешле уенда канәгатьләндерә башлый.

Гаджетларны куллану кагыйдәләре

- смартфонны колакка 5 сантиметрдан да якын тотмаска;
- кечкенә бала янында смартфонны «самолетта» дигән режимга көйләргә, ә планшетларны бөтенләй сүндереп куярга;
- гаджетны йоклаганда мендәр астында һәм, гомумән, баш янында тотмаска;
- баланың күз карашы гаджет экранына өстән аска төшәргә тиеш (яткан килеш карарга ярамый);
- экран күздән 30–40 сантиметр ераклыкта булырга тиеш;
- транспортта барганда балага планшет бирү киңәш ителми, чөнки транспорт хәрәкәтләнгәндә планшеттагы сурәтне карау күзләргә көчәнеш китерә, күзләр арый.

Баланы гаджетка бәйлелектән ничек коткарырга

Әгәр:

- бала элеккеге кызыксынуларын оныта;
- дәресләрен карамый башлый;
- үз эченә йомыла;
- йокысы һәм ашау режимы бозыла;
- сезнең белән тау шуарга барасы урында, гаджетына «чумып» утыра икән, чаң кага башларга кирәк. Балада бәйлелек барлыкка килгән.

Мондый очракта баланың планшетын тартып алырга, интернетны өздерергә ЯРАМЫЙ! Бәйлелек барлыкка килгән баладан гаджетын тартып алсаң, анда стресс була да була инде. Гаджетны бала әлегә кызыксына торган әйберләр белән әкренләп «алыштыра» барырга кирәк. Мәсәлән, «син планшетыңда биш минутка азрак «утырсаң», без синең белән паркка барабыз», «әйдә, бүген планшетта «утырганчы» киного барабыз», дип тәкъдим итәргә була. Әгәр бала сезнең тәкъдимне кабул итә икән, димәк, сез баланың гаджетка бәйлелеген үзегез дә җиңә алачаксыз. Әгәр бала сезнең тәкъдимнәргә игътибар итми икән, кичекмәстән педиатр, невролог һәм психологка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Гаджетка бәйле баланы «кире кайтару» өчен, аңа озак вакытка сузылган психотерапия курсы үтәргә туры киләчәк. Күпчелек очракта психотерапия курсы бөтен гаиләгә дә кирәк була, чөнки, баланы дәвалау өчен, гаиләдә формалашкан гадәтләрне дә алыштырырга кирәк.

Гаджетны куллану вакытын мәктәпкәчә яшьтәге балаларга – көнгә 15 минут, урта мәктәп балаларына – 30–60 минут, югары сыйныф укучыларына 90 минуттан да арттырмаска киңәш ителә.



САКЛАНУ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШИК

Кайчандыр әбиләребез саклаучы чара буларак лимон телемен (сперматозоидларны үтерә торган әче мохит барлыкка китерә), алтын балдакны (бала тапканнан соң ук аналыкка кертеп калдырылган балдак спираль ролен үтәгән) кулланса, бүген исә контрацептивларның йөздән артык заманча төре бар. Балага узудан саклый торган чаралар кешелек эволюциясе белән бергә үзгәргән, камилләшкән. Шулар турында РКБның гинекология бүлеге кураторы, КДМУның акушерлык һәм гинекология кафедрасы доценты, медицина фәннәре кандидаты Люция ЭГАМБЕРДИЕВА сөйли.

Хатын-кызларның айлык җенси өлгереш циклында уңай һәм уңайсыз көннәр бар. Күрем тукталганнан соң бер атна һәм яңа күрем башланыр алдыннан ун көн чамасы дәвамында балага узу ихтималы кими. Ләкин андый көннәргә тулысынча ышанып булса, шуның хәтле саклану чарасы уйлап табылмаган булыр иде.

Шактый озак вакыт табибларда гормональ контрацептивлардан шикләнү яшәде. Гади халыкта һаман да бар әле ул. Тик без, табиблар, соңгы вакытта уйлап табылган ораль (таблеткалар) контрацептивларның (КОК) балага узудан саклый торган иң нәтиҗәле чара булуын гына түгел, аларның дәвалау үзлекләренә ия булуын да танымый кала алмыйбыз. Хәзер составында эстроген гормоны бик аз күләмдә булган, анысы да табигый эстрогенга мөмкин кадәр якынайтылган зыянсыз препаратлар бик күп. Гормональ препаратларның дәвалау үзлегенә килгәндә, без, әйтик, балага уза алмый тилмергән кайбер хатын-кызларга КОК билгелибез. Ул аны 3-6 ай эчә дә туктата, шуннан соңгы циклда балага узу ихтималы арта.

Ораль контрацептивларны фәкать табиб кына билгели. Халыкара сәламәтлек саклау оешмасы тарафыннан кабул ителгән 14 сораудан торган программа бар. Гинеколог андагы барлык сорауларны да хатын-кызга биреп чыгарга, шуннан соң гына КОК билгеләргә тиеш. Тәмәке тарткан хатын-кызларга ораль контрацепция бөтенләй киңәш ителми. Гомумән, хатын-кыз спорт белән шөгыльләнәме, кисәк ябыгудан куркамы, депрессиягә бирелүчәнме, тән тиресе проблемалы түгелме – КОК билгеләгәндә барысы да исәпкә алына.

Составында эстроген булмаган препаратлар да бар. Мәсәлән, имплант рәвешендә тире астына куела торган контрацептив (анда бер генә гормон була) имезүче хатын-кызларга да рөхсәт ителә. Бу чара балага узудан 99,6 процентка саклый дип санала.

Гинекологлар гадәти «спираль»не яратып бетерми. Ник дигәндә, алар еш кына ялкынсыну барлыкка китерә. Гомумән, без киләчәктә бала табарга теләгән хатын-кызларга «спираль» куйдырырга киңәш итмибез.

Гормональ препаратларга ышанмый торган хатын-кызлар механик һәм химик контрацептивлар куллана. Механик саклану чараларының ышанычлылыгы бик түбән, ә менә химик төргә караган спермицид «свеча»ларның нәтиҗәлелеге зуррак. Алар җенси мөнәсәбәткә керер алдыннан гына аналык җиңсәсенә куела һәм кыска вакыт аралыгында яхшы гына саклый. Ләкин мондый төр саклану чарасы бер уңайсызлык тудыра, аннан соң ул хатын-кыздан тиешле тәртип, тәҗрибә һәм оешканлык таләп итә.

Иң еш бирелә торган сораулар

Кайбер контрацептивлар балага узудан гына түгел, җенси юл белән йога торган чирләрдән дә саклый. Андыйларны башка саклану чараларына өстәмә рәвештә кулланырга ярыймы?

– Ярый. Ике саклану чарасын берьюлы куллану – Голландия ысулы дип атала. Әйтик, хатын-кыз балага узудан саклый торган таблеткалар да эчә, шул ук вакытта «свеча» да куллана ала. «Свеча» сперматозоидларны үтерә, ә җенси юл белән йога торган чирләрнең күбесе сперматозоидка ияреп «йөри».

Күп кенә гинекологлар гормональ контрацептивлар билгеләгәндә гормонга анализ тапшырырга кушмый, бернинди анализсыз гына билгелиләр. Бу дөресме?

– Дөрес. Әгәр хатын-кыз Халыкара сәламәтлек саклау оешмасы программасындагы 14 сорауга да «юк» дип җавап бирә икән, гинеколог аңа бернинди анализсыз гына да ораль контрацептив язып бирә ала. Хатын-кыз организмында ниндидер тайпылыш барлыгы ачыкланса, өстәмә анализлар билгеләнә. Мондый очракта бары тик проблеманы тапкач һәм аның килеп чыгу сәбәпләрен ачыклагач кына таблеткалар билгеләнә яки башка саклану чарасы тәкъдим ителә.

Кайбер гормональ таблеткаларның абортка китерү куркынычы бар. Ә барлык диннәр дә абортка каршы. Димәк, мондый таблеткалар диндә тыелган булып чыга?

– Юк. «Ашыгыч контрацепция» дип атала торган гормональ таблетканы саклanusыз җенси мөнәсәбәткә керү очрагыннан соң, күп дигәндә, 48 сәгать эчендә табиб язган буенча кабул итәләр. Тик бу аборт түгел. Мондый таблеткалар кукәй күзәнәк сперматозоид белән очраша калса, аталанырга өлгермәсен өчен, балага узу ихтималын алдан ук юкка чыгару өчен эчелә.

PRESSA.RU



«Алтын Барс» (дистәгә якын!), «Алтын йолдыз» милли музыкаль премияләре лауреаты, автор-башкаручы Илназ БАҺны бер дә өйдә туры китерерлек түгел икән. Бер карыйсың – хәләле Гүзәл белән әле Төмән якларында, әле Мәскәүдә... «Аңла йөрәгемне», «Бер курешү үзе бер гомер», «Мин сине көтәрмен», «Ярый әле син бар, туганым» – тамашачы аны әнә шушы җырлары белән кабул итте, яратты... Казан афишаларыннан да Илназ Баһ–Гүзәл Идрисова исемнәренең төшеп торганы юк. Әти-әнисенә ияреп, уллары Камил белән Рамил дә еш чыга сәхнәгә. Хәтта бәләкәйләре – икенче яше белән генә барган Марсельләре дә әтисенең концерт баянына барып ябышырга гына тора. Артист балалары шул!

Артист гаиләсе белән якыннанрак танышу, бер уңайдан «Сөембикә»нең март саны өчен аш-су дәресе дә уздырырбыз, дип, кышның соңгы көннәрендә аларга кунакка барып кайттык. Кадерле хатын-кыз укучыларыбызны бәйрәм белән котлап, җиңел кулдан гына... бик тәмле бәйрәм торты пешереп күрсәтте Илназ. Якыннарын куандырырга теләгән ир-егетләребез өчен менә дигән рецепт. Бәйрәм табынын ни бизи? Әлбәттә, тәмле ризык һәм матур савыт-саба. Бүгенге дәресебезнең иганәчесе – Казандагы «Савиново» сәүдә үзәгенең өченче катында урнашкан «Божья коровка» кибете. Болеславец осталары ясаган керамик савыт-сабалар бөтен дөньяга билгеле. Алар матур гына түгел, сыйфатлы һәм чыдам. Ялгыш бәреп алсаң да, кулдан төшеп китсәләр дә, ватылыр дип куркасы юк.

«ҖИЛӘКЛЕ АЛАН» ТОРТЫ



Кирәк:

камыр өчен

- 2 йомырка;
- 1 стакан шикәр комы;
- 1 стакан кефир;
- 1 стакан җиләк кайнатмасы (теләсә нинди кайнатма да ярый, әмма төшсез булырга тиеш);
- 1 кап камыр күперткеч (10 г);
- 1 кап ванильле шикәр (10 г);
- 1,5 стакан он.

Крем өчен:

- 1 стакан кибет каймагы;
- 140 г эремчекле сыр («Творожный сыр»);
- ярты стакан шикәр оны (пудра);
- тортның өстен бизәр өчен бер-ике уч җиләк тә кирәк (катырылганы да ярый).



Фото: Ксения Богданова

Эш барышы:

■ Тирән эчле савытка йомырка сытып, шикәр комын кушабыз һәм бик яхшылап күпертәбез. Кул белән озаграк булыр, блендер белән күпертсәгез – эш тизрәк барачак.

■ Икенче бер савытта кефир, кайнатма һәм ванильле шикәрне бергә кушып болгатабыз.

■ Күпертелгән йомыркага кайнатмалы кефирны салып, камыр изәбез. Онны кулланыр алдыннан гына иләргә һәм коры килеш камыр күперткечне кушып болгатырга кирәк.

■ Камырда төерләр булмаска, һәм ул куе каймакны хәтерләтергә тиеш. Әзер камырны төбе мул итеп майланган табага агызып, кайнар мичкә куябыз. Әзерлеген коры шырпы батырып белергә мөмкин, шырпы коры чыкса, димәк, пешкән.

■ Крем белән бизи башлаганчы, торт суынырга тиеш.

Крем ясау:

■ тирән эчле савытка каймак һәм шикәр оны салып, яхшылап туглыйбыз. Аннары эремчекле сыр өстәп, блендер белән күпертәбез. Крем ярты сәгать суыткычта торсын.

■ Суынган торт өстенә мул итеп крем ягабыз. Тортны табынга пешкән савыты белән чыгарабыз, чөнки ул бик матур. Әгәр дә аны табадан бушатасы булса, кремны тортның кырыйларына да ягасы.

■ Тортның өстен туңдырылган каен җиләге белән бизибез. Монда инде тулы ирек – кем ничек булдыра ала, шулай бизи. Каен җиләген теләсә нинди җимеш – кура җиләге, карлыган, бөрлегән дә алыштыра ала.

Марина Дмитриевадан

Мәкле пилмән

Калын төпле кәстрүлгә 100 г мәк орлыгы, 300 мл сөт салып, кайнап чыкканнан соң, өстен каплап, бер сәгать чамасы сүрән утта тотабыз. Бүрткән мәкне изәбез яки блендерда ваклатабыз. 2 аш кашыгы төшсез йөзем, 1 аш кашыгы бал, бер чеметем ванилин өстәп, болгатабыз. Эчлек таралып торырга тиеш.

2 йомырка, 1 чеметем тоз, 1/4 стакан су һәм 1-1,5 стакан оннан пилмәнгә баскан кебек камыр басабыз. Әзер камыр ярты сәгать торырга тиеш. Аны 2-3 мм калынлыктагы зур җәем итеп җәеп, түгәрәкләр кисәбез. Һәр түгәрәк уртасына берәр чәй кашыгы эчлек салып, кырыйларын матурлап бөрәбез. Пилмәннәрне кайнап торган тозлы суда 2 минутлап пешерәбез. Әзер пилмәннәрне эретелгән атланмайлы табага салып, бер минут чамасы ут өстендә тотабыз.

Табынга кесәл белән чыгарабыз.

PRESSA.RU


Фото: Газинур Хафизов

КАЕН СУЫ

Яз айлары түбәләрдән тамган тамчылары, челтерәп аккан гөрләвекләре белән генә түгел, каен суына барулар белән дә күңелле. Әле без үскәндә, кояш язга борылу белән,буш шешәләр, каз каурые – кавырсыннар алып, авылның бар бала-чагасы каенлыкка йөри идек. Каен суыннан авыз итә алмый калган яз әрәм узган яз кебек тоела иде.

Март, апрель айлары – каен суын җыяр өчен иң кулай вакыт. Әле бөреләр уянмаган, әмма кәүсәләргә яшәү суты инде күтәрелгән. Бөреләр ачыла башлагач, каен суын агызырга ярамый.

Диаметры 20 см булган агачта бер генә тишем ясарга рөхсәт ителә, 25 см диаметрлысына – 2, юанлыгы 35 см булган агачка 3 тишем ясарга була. Зур бер каеннан тәүлегенә 7 литр су агызырга ярый.

Каен суын көндез генә җыеп була, төнлә кәүсәдәге сут агышы туктала. Агачның төньякка караган ягында суты күбрәк була. Тишемне агач төбеннән ярты метр биеклектә ясасаң яхшы.

Суы күбрәк аксын дип, кәүсәне тирән тишмәскә кирәк. Беренчедән, бу агачка зыян китерә, икенчедән, тереклек суты агучы каналлар кайры белән үзагач арасында гына урнашкан.

Каен суын алып бетергәч, кәүсәдәге җәрәхәтне томалап кую мәҗбүри. Югыйсә берничә елдан бу агач корыячак. Тишемне бакча җилеме (садовый вар), балавыз, кер сабыны белән томалыйлар. Ул булмаса, берәр ботак тыгып куярга мөмкин. Ботак, бүртеп, тишемне тулаем каплар.

Яз көне каенның суын гына түгел, бөресен дә җыялар. Каен бөресеннән ясаган төнәтмә бәвел кудыргыч, тирләткеч үзлеккә ия. Аны организмның язгы хәлсезлеген җиңү өчен дә кулланалар, хатын-кызларда күзәтелүче гормональ тайпылышларны дәвалыйлар.

Каен суы, каен бөресе һәм каен кәүсәсендә үсүче гөмбә (чага гөмбәсе) организмның яман шеш авыруына каршы торучанлыгын арттыра.

Каен суы өй шартларында озак сакланмый. Пыяла савытка салып, өч көн суыткычта сакларга була, аннары ул бозыла башлый. Әчү процессы башланган каен суыннан квас әзерлиләр.

Каен суыннан берничә эчемлек рецептын да тәкъдим итәбез.

Квас

Каен суын берничә кат марлядан сөзәләр дә, пыяла банкага салып, 5 литр каен суына 20-25 дәнә йөзем җимеше, 200 г шикәр комы өстәп, салкынча урында 3-4 көн әчетәләр. Аннары сөзеп, пыяла банкаларда суыткычта саклыйлар.

Лимонлы каен суы

Каен суын сөзеп, эмаль савытта кайнатырга куябыз. Өскә калыккан күбеген җыеп алабыз. 5 литр суга 200 грамм исәбеннән шикәр комы кушабыз. Кайнар пар өстендә стерильләштерелгән банка төбенә 4-5 телем лимон салып (лимон телемнәрен башта кайнар су белән пешекләргә кирәк), кайнап торган каен суын коябыз һәм калай капкач белән томалыйбыз.

ЫЛЫС ДӘВАЛЫЙ.

Ылыслы урманда йөргәнегез бармы сезнең? Андагы һаваның, сулышларны киңәйтеп, тын юлларына бәлзәмдәй ягылганын тоя идегезме? Ә бит, дөрестән дә, ылыс тын юлларына бер дигән дәва.

Тиздән чыршы ботакларында яшь бәбчекләр пәйда булачак. Җыегыз сез аларны. Бу яшь ылыстан бик шәп дәва ясыйлар.

Рецепты гади генә. Яшь ылысны юып, кайчы беләнваклыйбыз. Бер литрлы банкага вакланган ылысны шикәр комы белән аралаштырып, тыгызлап тутырабыз. Өч атна чамасы вакыт эчендә ылысның суты бүленеп чыга. Аны сөзеп, суыткычта саклыйбыз. Шушы сут беткәнче көнгә өч тапкыр 1 чәй кашыгы кабып куябыз. Кыш дәвамында үпкәгә җыелган какырыкны чыгарып бетерәчәк.



ТУННАР... СУЫТКЫЧТА САКЛАНА

Туннарны саклау

■ Коры һәм эссе һавада мехның сыйфаты югала. Мөмкинлеге булган кешегә туннарын җәйге якта саклау өчен махсус суыткычларга тапшырса яхшырак. Мондый хезмәтне зур шәһәрләрдәге химчисткалар тәкъдим итә.

■ Әгәр дә андый мөмкинлек булмаса, җәй көне затлы туннар өчен уңай шартларны үзебезгә тудырырга кала. Караңгы, әмма җиләс һәм иркен урын булырга тиеш ул. Кысан шкафка дыңгычлап тутырасыз икән, туныгыз, күп дигәндә, ике-өч ел гына куандырыр.

■ Шкафка тыгар алдыннан тунны җиләс һавада бик яхшылап җилләтергә кирәк. Әмма кояш нуры төшкән урында түгел, мех кояшны яратмый. Кояш нурлары аркасында тунның төсе тоныклана, мехы начарлана, төкләре сына торганга әйләнә.

■ Мех киемнәрне полиэтилен капчыкта сакларга ярамый. Чехол һава йөри торган тукымадан булырга тиеш.

■ Туныгызны элә торган иңсәнең размерына игътибар итегез. Ул җиң утырткан җөйне үтеп китмәслек булсын. Артык кечкенә иңсә дә ярамый, югыйсә тунның рәвеше бозылачак.

Мехны чистарту

Әлбәттә, кышкы киемнәрне химчисткага биреп чистартсаң – яхшы. Инде андый мөмкинлек булмаса, үзегез чистарта аласыз.

■ Моның өчен коры крахмал яки тальк кирәк. Кемдер коры манный ярмасы белән дә чистарта. Тунны идәнгә җәеп салыгыз да, мул итеп крахмал сибегез. Крахмалны щетка ярдәмендә җиңелчә генә мехка ышкыгыз. Аннары урамга алып чыгып, бик яхшылап селкегез.

■ Мехның төсе тоныкланса, бергә – бер нисбәтендә чиста су кушылган лимон суты да ярдәм итә ала. Йомшак губканы шушы суда чылатып, мехны акрын гына ышкып чистарталар.

■ Ак төсле тун саргаеп китсә, өч процентлы водород перекисен су белән сыеклап, мехка сиптерәләр. Кипкәч, сирәк тешле тарак белән тарыйлар.

■ Ак тунны аз гына синька салынган су белән дә агартырга була. Лычма юешләтеп түгел, әлбәттә.

Кайры тунны чистарту

■ Мех кебек, аны да коры манный ярмасы белән чистартырга мөмкин. Манный урынына крахмал да ярый.

■ Кайры тунның ялтырый башлаган урыннарын кипкән икмәк кисәге белән ышкып карагыз. Икмәк валчыкларын соңыннан йомшак щетка белән сыпырып төшерегез.

■ Ялтыраган урыннарны гап-гади бетергеч – ластик белән дә ышкып бетереп була.

■ Каешланган урыннарны элеккеге хәленә кайтарырга теш порошогы да булыша. Порошокны резин щетка ярдәмендә кесә кырыйларына, җиң читләренә, якага ышкыйлар. Аннары йомшак щетка белән сыпырып, порошогын коялар.

Җәй көне туннарга тагын бер куркыныч яный әле – көя күбәләге.

■ Көя күбәләге әрем, сабын, әфлисун исләрен яратмый. Аларны кечкенә янчыкларга салып, шкаф эченә элеп куярга мөмкин.
■ Лаванда мае да көядән сакланырга булыша. Мамыкка лаванда мае сеңдереп, шкафның идәненә, өске киштәсенә куегыз.
■ Көядән саклый торган «төймәләр»не тунның кесәләренә, җиң кайтармасына, капюшонына да салалар.
■ Табигый чараларның да, кибеттән алган төймә-пластинкаларның да тәэсире озакка бармый, аларны әледән-әле яңартып торырга кирәк.



PRESSA.RU

Җиң сызганып, бакча эшләренә керешер көннәргә дә күп калмады. Гадәти яшелчәләр белән беррәттән, бөтен кеше дә үстерми торган ятрак яшелчәләрне дә үстереп карамыйбызмы соң быел? Күп көч сорамый гына безнең бакчада да үсә алучы андый сирәк үсемлекләрнең шактый төре билгеле.




ДЕЛИКАТЕС ЯШЕЛЧӘЛӘР



Артишок

Җылы ярата торган күпьеллык үсемлек. Үзебезнең гап-гади «шайтан таягы»ның бер төре. Ризык буларак, яшь ботакларын һәм ачылып өлгермәгән чәчәк бөресен кулланалар. Вегетация чоры озын булганга, безнең якта артишокны яз башында уҗымга чәчеп, берьеллык культура итеп кенә үстерергә мөмкин. Сатуда төрле сортлары бар, безнең җирлек өчен тиз өлгерешле сортлары гына ярашлы.



Брокколи

Брокколи кәбестәсен бакчада үстерүнең бер кыенлыгы да юк. Суыкка да, кырауларга да чыдам. Чыдам гына түгел, ул хәтта суыкны ярата да.
Брокколины иртә язда турыдан-туры түтәлгә генә дә чәчәргә мөмкин. Тишелеп чыгып, бераз күтәрелгәнче, өстен каплап торасы була. Кояшның туры караганын яратмый, шуңа да аны башка яшелчәләр начар үсә торган – күләгәрәк урынга утыртыгыз.



Топинамбур

Халык телендә икенче исеме – җир грушасы. Шикәр чиреннән һәм югары кан басымыннан интегүчеләр өчен аеруча файдалы. Туфракка да, дымга да бик талымсыз.
Бүлбеләрдән дә, орлыктан да үстерәләр. Орлыктан үстергәндә, эре бүлбеләрен киләсе елга гына кулланып булачак.
Бәрәңге кебек үк, аны да 10-15 см тирәнлектә утырталар. Төбенә ике тапкыр өяргә кирәк.



Фенхель

Икенче төрле аны дарулык укроп дип тә атыйлар. Тынычландыру, ашкайнату системасын көйләү үзлегенә ия. Аның орлыкларын төнәтеп, сабый балаларның эчләре авыртканда эчерәләр. Яфраклары белән дә, хуш исе белән дә укропка охшаш ул. Әмма аннан аермалы буларак, сабак төбендә суганга охшаш йомры «шар» үстерә. Ризык буларак, әнә шул «шар» кулланыла.



Спаржа

Латинча атамасы – аспарагус. Салкынга чыдам, талымсыз.
Бер урында егерме ел үсә ала.
Ризык буларак, иртә язда тамырдагы бөреләрдән үсә башлаган яшь тармакларын кулланалар. Утырткannан соң, өченче елында гына уңыш бирә башлый.
Спаржаны орлыктан чәчеп тә, куакны бүлү юлы белән дә үстерәләр. Орлыклары озак тишелә, турыдан-туры түтәлгә генә чәчсәң, чүп үләннәре басып китә. Шуңа да аны яз башында уҗымга чәчсәң – яхшырак. Җәй башында араларын киң калдырып, яхшылап ашланган көпшәк туфракка тирән буразналар ясап, утыртып чыгалар. Үсемлек үсә барган саен, буразнаны туфрак белән күмдерәләр.

Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.
Фото: www.pixabay



Кучкар. Күпне эшләп, күпкә ирешергә өлгерерсез. Яңалыклар, мәгълүматлар берсе артыннан берсе килеп кенә торачак. Яңа танышыгыз барлыкка килер, белемегезне арттырырга тәкъдим итәрләр.



Үгезбозау. Иҗади сәләтегез ачылыр һәм үзегез дә көтмәгән уңышларга ирешерсез. Әмма бар да шома гына бармас, көч тә түгәргә туры килер. Ай башында танышкан кешегез киләчәктә якын дустыгызга әверелергә мөмкин.



Игезәкләр. Тормышыгызның истә калырлык чоры булыр. Ике юл чатында калгандай тоярсыз үзегезне: ияләшкән урында калыргамы, яңалыкка таба атларгамы? Яңалыкны сайласагыз, оттырмассыз.



Кысла. Хыялларыгызны тормышка ашыру форсаты чыгар. Башкалар фикеренә бәйле булган Кыслалар үз мөстәкыйльлекләренә үзләре үк аптырар. Хаталардан курыкмагыз, сезнең шундый чор – хәтта хаталар да сезнең файдага гына булыр.



Арыслан. Иң яхшы сыйфатларыгызны күрсәтә алырсыз. Амбицияләрегезне канәгатьләндерә алуыгыз бәхет тойгысын бирер. Артыгыздан иярту сәләте тагын да ныграк ачылыр. Иң кирәкле мизгелдә иң кирәкле кеше белән очрашырсыз.



Сөмбелә. Көндәшләрегезне дөрес бәяләп, дөрес адым ясарсыз. Моңарчы койрык булып сөйрәлеп килгән эшләрегездән җиңел генә котылу мөмкинлеге бар. Үз сүзегездә торырга тырышыгыз.



Бизмән. Тормышыгызның иң уңышлы чорына аяк бастыгыз. Дәрманыгыз көчле, сүзегез үтә торган вакыт. Тормышыгызга яңалык кертергә теләсәгез, аны хәзер хәл итәргә кирәк. Уңыш капкасы ачык, тәвәккәллек кенә җитеп бетми.



Чаян. Тормышыгыз кызыклы вакыйгаларга бай. Үз алдыгызга кыю максатлар куюдан курыкмагыз. Көттерсә дә, уңыш барыбер киләчәк. Ниндидер кызыклы тәкъдим алырсыз, финанс ягыгыз җайланыр.



Укчы. Көчегезнең артуын тоярсыз, үз-үзегезгә ышаныч барлыкка килер. Һөнәри өлкәдә яңа мөмкинлекләр ачылыр, зур җаваплылык йөкләрләр. Әмма моның шәхси тормышка йогынтысы да булмый калмас, күп игътибарыгызны эшкә бирергә туры килә бит.



Кәҗәмөгез. Карарларны тиз һәм дөрес кабул итә белүегезнең әҗерен күрерсез. Яңа эш башлау, яңа белем үзләштерү өчен бик яхшы вакыт. Күңелегезгә рәхәтлек бирә торган үзгәрешләр булыр.



Сукояр. Тормышыгызга җитди үзгәрешләр кертү теләге көчәя. Киләчәккә төзегән планнарыгыз дөрес, әмма аларны чын итү өчен түземлек кирәк. Уңыш үкчәгезгә бастырып килә, сез моны үзегез дә тоярсыз.



Балык. Эчке тоемыгыз искиткеч. Эшегез барып чыксын дисәгез, иң элек үзегезне тыңлагыз. Вак-төяккә игътибар итүдән тыелырга өйрәнсәгез, тормышыгыз шунда ук ямьләнеп китәчәк.

март та кабынган йолдызлар

Татарстан



Фәрдия Сәфәргалиева (10.03.1953) – **режиссер, сценарист, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.**

Арча районы Урта Бирәзә авылында туа. Казан дәүләт педагогика институтын тәмамлап, Ульяновск шәһәрендә математика фәнен укыта. Иҗатка тартылуы да шул еллардан башлана – татар бәйрәмнәренә сценарийлар яза, татар балалары өчен якшәмбе түгәрәкләре оештыра. 1992 елдан – Казанда. Казан сәнгать академиясендә «театральләштерелгән тамаша һәм бәйрәмнәр режиссеры» белгечлеген ала, 1998–2004 елларда Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә режиссер-куючы булып эшли. 2005–2011 елларда – Г. Кариев исемендәге яшь тамашачы театрында. 2010 елда «Елларымны югалтма» дигән шигырьләр китабы басылып чыга. 2012 елда «Габдулла Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры» дигән җыентык төзи.

Россия



Ирина Купченко (1.03.1948) – **Россиянең халык артисты, Россия Федерациясенең Дәүләт премиясе лауреаты, Почет ордены иясе**.

Австриянең Вена шәһәрендә, хәрби офицер гаиләсендә туа. Балачагы Киевта үтә. Актерлык белән балачактан шөгыльләнә. «Пионерлар йорты»ндагы бию, театр, кинооператорлар түгәрәкләренә йөри. Мәктәпне тәмамлап, Киев университетының чит телләр факультетына укырга керә. Кинога ул тәүге тапкыр 1969 елда төшә. «Дворянское гнездо» фильмында Лиза ролендә уйный. 1970 елда ул Б. Щукин исемендәге театр училищесын тәмамлый.

«Романс о влюбленных», «Чужие письма», «Странная женщина» фильмнарында башкарган рольләре аңа танылу китерә. Шулай да актрисаның чын таланты «Одинокая женщина желает познакомиться» мелодрамасында Клавдия роле аша ачыла.

Чит илләр



Холли Хантер (20.03.1958) – **актриса**.

1994 елда «Пианино» фильмында башкарган роле өчен «Оскар» премиясенә лаек булган әлеге актриса Коньерс шәһәрендә гап-гади гаиләдә туа. Карнеги-Меллон университетын тәмамлап, берара «City Theatre» театрында эшләп ала. Аннан Лос-Анджелес шәһәренә күченә. «Воспитывая Аризону» һәм «О где же ты, брат?» фильмнарындагы рольләрне бертуган Коэннар (Голливудның иң атаклы сценаристлары) махсус аңа атап яза.

Танылу бу актрисага «Телевизионные новости» комедиясен уйнаганнан соң килә. Алай да игътибарга иң лаеклы эшләре дип «Пианино» һәм «Фирма» фильмнарында башкарган рольләрен атап булыр иде.

Фото: www.lady.mail.ru. www.kackad.com

PRESSA.RU





НӘФИС СЫЗЫК ТЫЛСЫМЫ

Әлфия Гасанова эшләрен беренче күрүдә үк күзне нәфислек һәм грация иркәли. Нәкъ менә нечкә сызыклардагы грация күңел дөньясының табигать белән гармониясе турында сөйли. Ул эшләр белән танышкач, авторы, мөгаен, хатын-кызның кадере бар җирләрдә туып-үскәндер дип уйлап куйдым. Ялгышмаганмын.

Әлфия Гасанова Дагстанда яши, шунда иҗат итә. Билгеле булганча, Кавказда хатын-кызга аерым мөнәсәбәт. Кешегә туган җире, яшәү рәвеше, аралашу даирәсе зур йогынты ясый, диләр. Чынлап та, Әлфияне беренче күрүдә үк аның сыгылмалы хәрәкәтләрен, зифа буй-сынын күздән кичерәсең, һәм бу хатын-кызның гүзәллеге тәмам таң калдыра.

Татар кызы булса да, бабалары Ватанына кайтканы юк әле Әлфиянең. Ул Казанны күрергә, изге Болгар, Биләрләргә барырга хыяллана. Кайчандыр Казанда яшәгән әти-әниләре башта Кыргызстанга чыгып киткән, аннары Махачкалага китеп барганнар.

Әлфия Җамал исемендәге сәнгать училищесында һәм Дагстан дәүләт педагогика университетының художество графикасы бүлегендә белем алган.

«Иң беренче илһамландыручым әбием иде, – дип искә ала ул. – Бер утыруда гына ясаган рәсемнәремне и мактый, и үсендерә иде мине! Шуңа, кем булырга дигәндә, һич югалып калмадым. 22 ел инде яраткан эшемдә мин! Балаларым да минем юлдан китте».

Әлфиянең иҗаты фарфор бизәүдән башлана. Соңрак үзен җиһаз-декоратив фазада сынап карый. Күргәзмә, тантана залларын бизәү эшләрендә катнаша. Эшләре Махачкала һәм Дербент сынлы сәнгать музейларына куелган. Төркия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Европа һәм Азия күргәзмәләрендә дә иҗаты белән танышырга мөмкин.

Җиһазлар һәм агач паннолар, интерьерлар бизәү – аның иҗатында аерым урын алып тора. Бүген исә Әлфия Гасанова фарфорга һәм керамикага, панноларга, тәлинкәләргә, декоратив плитәләргә бизәк төшерү белән мавыга.

Глазурь өстеннән бизәк төшерү – фарфор һәм керамик эшләнмәләрне бизәү техникасы. Эшләнмәләр әүвәл мичтә яндырыла, аннан аларга глазурь йөгертелә. Шуннан соң эшләнмәне кабат яндыралар. Глазурь өстеннән төшерелгән бизәкләр төсләрнең җетелеге белән аерылып тора. Бу эшләр гаять четерекле, зур осталык сорый.

Әлфия күп эшләрендә итальян майоликасы стиленә өстенлек бирә. «Майолика минем өчен җылы матурлык ул. Ул стильдә ясалган әйберләрдән нәфислек бөркелә», – ди.

Рәссамның һәр эше үзенә бер шигъри образ кебек. Авторның фарфор һәм керамикага бизәкләр төшереп үз стилен булдыруы һәрчак иҗади эзләнүләр аша бара.

Әлфия дә, төрле алымнарны кулланып карап, бары тик аныкы гына булырдаен тапкан. «Кояшның турыдан төшкән нурларыннан сусаль алтын «янып китә» икән бит. Миңа ошады бу. Кайчак һич көтмәгәндә буяу һәм лакларны бергә кушып карау да матур нәтиҗәләр бирә», – дип аңлата ул.

Төрле вак детальләрнең һәркайсын җентекләп күздән кичереп, Әлфия Гасанова әсәрләре янында һәрчак озаклап туктап торалар: зәркән осталыгы белән төшерелгән бизәкләр рәссам тудырган тылсым дөньясына алып китә.

Рәмзия КАШАПОВА







ӘЛФИЯ ГАСАНОВА

PRESSA.RU

«Сөембикә» журналы – иң әйбәт бүләк



2018 елның икенче яртыеллыгына «Сөембикә» журналына язылу башланды

Язылу индексы:
РФ регионнарында – 73002,
Татарстан буенча – П2204

«Сөембикә» журналы
сайтта: www.syuyumbike.ru
ВКонтактеда: vk.com/suumbike
Фейсбукта: www.facebook.com/syuyumbike
Инстаграмда: www.instagram.com/suyumbike_journal



Альбина **ӘБСӘЛӘМОВА**, «Оренбург шәлләре» предприятиесе директоры, Оренбург татар хатын-кызларының «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы рәисе

Оренбург диюгә, мөгаен, һәркайсыгыз безнең челтәр шәлләрне, мамык шәлләрне күз алдына китерер, «Оренбур шәле» җыры җаннарыгызны иркәләп узгандай булыр. Шул шәлләргә күз нурлары, күңел җылысы кучкән бәйләүче уңган кызларыбыз исеменнән кадерле әбкәйләрне, әниләрне, апаларны – барлык хатын-кызларны үзебезнең бәйрәм белән котлыйм. «Безнең һәр шәлебез – бердәнбер!» – дияргә яратабыз без. Сатып алучыны гел гаҗәпләндереп торасыбыз килә. Ә бит, уйлап карасаң, сезнең һәркайсыгыз шулай ук – бердәнбер! Һәркайсыгыз гел гаҗәпләндереп тора! Һәркайсыгыз – чәчәк аткан гөл кебек: сөйкемле, серле, нәзберек!

Сәламәтлек, уңышлар, күтәренке кәеф, хатын-кыз бәхете телим сезгә!

